| | | среды в разных возрастных группах;<br>-Использование народных подвижных игр на праздниках и развлечениях в ДОУ;<br>-Развитие речи дошкольников в процессе повседневного общения;<br>-Использование УМК в режимных моментах;<br>-Үстерелешле тел мохите – тат.гр.;<br>-Развитие речи детей через музыкальные занятия;<br>-Татар телен МКТ кулланып өйрәнәбез – тат.гр;<br>-Реализация УМК «Говорим по-татарски» через взаимодействие с родителями;<br>-ЭРС в художественном эстетическом воспитании дошкольников;<br>-Содержание работы по нравственно-патриотическому воспитанию дошкольников в ДОУ;<br>-Патриотическое воспитание музыкой;<br>- Народные праздники и традиции –важный элемент приобщения дошкольников к культуре родного края;<br>- Речевое развитие старших дошкольников. | педагогов, укрепление взаимосвязи с воспитателем по обучению детей родному языку | |
| | 28.01.21<br>18.11.21 | **Педагогические советы**<br>•«Применение УМК по обучению детей двум государственным языкам РТ в ДОУ и взаимодействие с семьей в вопросах организации работы по обучению родному (татарскому) и татарскому языкам» | Просвещение педагогов, укрепление взаимосвязи с воспитателем по обучению детей родному языку | Педагоги ДОУ, 28 педагогов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | •«Организация работы по нравственно-патриотическому воспитанию детей дошкольного возраста в условиях ДОУ» | | |
| | 20.01.21-31.12.21 | **Организация и участие** в городских, республиканских и всероссийских семинарах | Распространение и обогащение опыта работы | Педагоги ДОУ, 28 педагогов |
| | 01.04.21-30.04.21 | **Фестиваль** народного танца | Распространение и обогащение опыта работы | Педагоги ДОУ, 10 педагогов |
| | 20.01.21-30.04.21 | **Смотр-конкурс** театрализованной сценки «Әй, замана баласы» | Развитие самодеятельного творчества, воспитание уважительного отношения к национальной культуре народов Татарстана и мира; выявление талантливых исполнителей и коллективов. | 7 педагогов |
| | 20.01.21-31.12.21 | **Публикации** в сборниках | Распространение и обогащение опыта работы | Педагоги ДОУ, 28 педагогов |
| | 10.01.21-31.01.21<br><br>11.10.21-22.10.21<br><br>01.12.20-31.12.20 | **Конкурсы для педагогов:**<br>«Лучший речевой центр»<br>«Лучшая речевая среда (тат.гр.)»<br>«Виммельбух «Быт народов Поволжья»<br>«Дидактическая игра по УМК»; | Распространение и обогащение опыта работы | Педагоги ДОУ, 28 педагогов |

**2.3..Приложение 2**

## Результативность педагогов за 2021 год:

| **Уровень** | **Наименование конкурса** | **Количество** | **Результат** |
|---|---|---|---|
| Всероссийский | Конкурс педагогического мастерства «Моя педагогическая инициатива» | 8 | Диплом 1,2 степени |
| | Конкурс методических разработок «Лэпбук как средство развития детей дошкольного возраста» | 1 | Участие |
| Региональный, республиканский | Конкурс авторских лэпбуков «Кызыклы китап» | 7 | Диплом 2,3 степени, участие |
| | Конкурс методических разработок «Играем, речь развиваем» | 8 | Диплом 1,2,3 степени |
| | Конкурс методических разработок, пособий, развивающих игр для педагогов ДОУ «Профессии знаем, язык закрепляем» Сетевая акция | 6 | Участие |
| Муниципальный | Конкурс методических разработок «Методическая копилка» | 3 | Диплом 1,2 степени |
| | Смотр-конкурс художественной самодеятельности «Таланты вокруг нас», посвящённому году родных языков и народного единства | 7 | Диплом 3 степени |
| | Литературный флешмоб в сети ВКонтакте #Челны читают Тукая#Чаллы Тукайны укый | 1 | Сертификат |

## 2.4.Приложение 3

## Результативность педагогов за 2021 год:

| **Уровень** | **Наименование** | **Количество педагогов** |
|---|---|---|
| Всероссийский | Участники мониторинга качества дошкольного образования детей от 3 до 7 лет в субъектах РФ в экспериментальном режиме (МКДО) | 29 |
| | Мастер-класс в научно-практической конференции «Диалог культур в контексте образовательной деятельности». | 3 |
| Региональный, республиканский | РИП: участники региональной инновационной площадки НГПУ «Психолого-педагогические условия реализации ФГОС ДО», наш сад является апробационной площадкой при РИП «Модель оценки компетенций наставника» (решение ученого совета от 31.01.2020 протокол №1приказ МО и Н РТ № под-1097/18 от 13.07.2018) по теме «Основные подходы к органи-зации речевого развития дошкольников в соответствии требованиями ФГОС ДО». | 22 |
| | Выступление в семинаре | 5 |
| | Мастер-класс в рамках семинара | 5 |
| | Показ ООД в рамках семинара | 4 |
| | Публикация в газете | 3 |
| | Публикация в сборнике теоретических и практических материалов | 1 |
| Муниципальный | Публикация в сборнике теоретических и практических материалов | 12 |
| | Выступление в семинаре | 6 |
| | Работа в комиссии | 2 |
| | Показ ООД в рамках семинара | 6 |
| | Мастер-класс в рамках семинара | 5 |

## 2.5.Приложение 4

## Результативность воспитанников за 2021 год:

| Уровень | Наименование конкурса | Количество воспитанников | Результат |
|---|---|---|---|
| Всероссийский | Конкурс проектов «Тропинки к успеху» | 1 | Диплом 2 степени |
| | Конкурс чтецов «Джалиловские чтения» | 1 | Диплом 3 место |
| | Конкурс по ранней профориентации дошкольников «BabySkills» в компетенции "Инспектор ГИБДД" | 1 | Номинация |
| | Конкурс музыкального творчества «Жар – птица 2021» | 9 | Диплом лауреата 1степени Ансамбль «Крутые девченки» |
| | Конкурс «Горизонты педагогики» | 9 | Диплом 3степени Ансамбль «Крутые девченки» |
| | Конкурс солистов и малых форм классического, народно- сценического, современного, эстрадного танца «Solo Danc Chelny – 2021@ | 9 | Диплом 1 степени Ансамбль «Непоседы» |
| Региональный, республиканский | Фестиваль-конкурс чтецов «Многоголосие Поволжья» | 7 | Диплом 1,2,3 степени |
| | Конкурс детского творчества «Читаем Тукая» | 3 | Диплом 1степени, участие |
| | Фестиваль хореографического искусства «Танцевальная карусель» | 9 | Диплом лауреата 1степени Ансамбль «Непоседы» |
| | Фестиваль-конкурс национального татарского искусства «Кызыл төлке» | 6 | Лауреат 2,3 степени, участие |
| | Конкурс чтецов «Шаян ТВ» | 1 | Диплом |
| | Фестиваль конкурс юных исполнителей «Первые шаги» | 13 | Диплом 1, 2, 3 степени |
| | Конкурс творческих семейных проектов «Семейный очаг» | 5 | Диплом 1,2,3 степени |
| | Конкурс детских рисунков и художественного чтения «Герои произведений Агнии Львовны Барто» к 115- | 1 | Лауреат 1 степени |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | летию со дня рождения детской писательницы | | |
| | Конкурс-выставка декоративно-прикладного творчества «Веселая карусель» | 8 | Диплом 3 место, участие |
| | Конкурс юных исполнителей «Мин яратам сине, Татарстан!» | 2 | Диплом 3 место |
| | Конкурс по ранней профориентации дошкольников «BabySkills» в компетенции "Инспектор ГИБДД" | 1 | Диплом 1 место |
| Муниципальный | Видеоконкурс чтецов «Поэтическая капель» | 1 | Диплом 1 место |
| | Видеоконкурс «Весенние лучики поэзии» | 5 | Диплом 2 место, участие |
| | Конкурс чтецов «Кызыл тау» | 1 | Лауреат 1 степени |
| | Интеллектуальный конкурс для дошкольников 6-7 лет татарской национальности «Зирэк ябалак» | 1 | Диплом 1 место |
| | Интеллектуальная викторина для дошкольников 5-6 лет «По страницам народных сказок» | 1 | Диплом 3 место |
| | Видеоконкурс чтецов А.Барто «Любимые стихи читаем вместе» | 4 | Участие |
| | Творческий конкурс «Ты в дальнюю дорогу бери с собой друзей» | 4 | Диплом, участие |
| | Конкурс по ранней профориентации дошкольников «BabySkills» в компетенции "Инспектор ГИБДД" | 1 | Диплом 1 место |

## 2.6.Акт
## оценки реализации гранта

| | |
|---|---|
| Наименование образовательной организаций | Муниципальное автономное дошкольное образовательное учреждение города Набережные Челны «Детский сад общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по познавательно-речевому направлению развития воспитанников №113 «Непоседы» |
| Название проекта | **«Без бергә - Мы вместе»** |
| Информация о реализации проекта | В ходе реализации проекта проведены:<br>- смотры-конкурсы с воспитанниками «Татар кызы. Татар малае», «Әкиятләр иләндә», «Народная игрушка – России подружка», «Туган телем – Тукай теле», «Юные таланты», «Свет мой, Родина моя!»;<br>• региональный семинар «Продуктивная деятельность как средство формирования у дошкольников универсальных предпосылок учебной деятельности» и мастер-классы по ознакомлению воспитанников с орнаментами народов Поволжья по теме: «Игровые технологии как средство речевого развития детей дошкольного возраста при использовании социокультурного подхода и регионального компонента»;<br>- выставки в рамках проекта: «Г.Тукай», «По рисункам народов Поволжья», «Национальная кукла» и др.;<br>- педагогические советы: «Применение УМК по обучению детей двум государственным языкам РТ в ДОУ и взаимодействие с семьей в вопросах организации работы по обучению родному (татарскому) и татарскому языкам», «Организация работы по нравственно-патриотическому воспитанию детей дошкольного возраста в условиях ДОУ»; проведены мастер-классы «УМК: формирование умения у дошкольников строить диалог», «Современные игровые технологии в развитии речи детей дошкольного возраста»;<br>- проведены консультации для педагогов, распространены памятки и буклеты.<br>Мероприятия освещены на сайте ДОУ (https://edu.tatar.ru/n_chelny/chelnydou_113), в Вконтакте (https://vk.com/public205852278).<br>МАДОУ №113 является апробационной площадкой при РИП по теме «Основные подходы к организации речевого развития дошкольников в соответствии требованиями ФГОС ДО»). |

| | |
|---|---|
| Соответствие произведенных затрат целям проекта | Произведенные затраты соответствуют цели проекта: создание образовательной среды в условиях дошкольного образовательного учреждения, способствующей сохранению и развитию культуры, родного языка, национальной и культурной идентичности.<br>Приобретены расходные материалы: грамоты - 300 шт.<br>Приобретены оборудование и предметы длительного пользования:<br>Настольная игра "Сабантуй" в картонной коробке-14 шт.;<br>Магнитный кукольный театр-14 шт.;<br>Магниты «Костюмы народов Поволжья» -14 шт.;<br>Комплект дидактических игр для детского сада «Родной край – Татарстан»-14 шт.;<br>Методическое пособие «Игры детей Поволжья в детском саду и дома» -14 шт.;<br>Книга «Сказки народов России» -14 шт.;<br>CD Аудио для детей 4-5, 5-6, 6-7 лет- по 14 шт.;<br>CD «Говорим на родном языке» для детей 2-3, 3-4, 4-5 лет- по 2 шт.;<br>Методическое пособие «Говорим на родном языке» для детей 5-7 лет-14 шт.;<br>Учебно-методический комплект «Родной край» Е.Н. Ахатовой-14 шт.;<br>Учебно-методический комплект Р.К. Шаеховой- 14 шт.;<br>Дидактические и демонстрационные материалы на татарском и русском языках для детей «Вкусные сказки» -13 шт.;<br>Хрестоматия для родителей и воспитателей детских садов, книга на татарском языке-5 шт.;<br>Куклы народов Поволжья-20 шт.;<br>Доска меловая магнитная, вращающаяся, напольная- 15 шт.;<br>МФУ лазерный -1 шт.;<br>Ламинатор - 2 шт.;<br>Переплетчик - 1 шт.;<br>Музыкальная системы -1 шт.;<br>Ноутбук - 4 шт.;<br>Бумага для ламинирования - 45 шт..<br>Все закупленные расходные материалы, оборудования и предметы длительного пользования используются для награждения победителей в конкурсах и эстафетах; для организации режимных моментов с детьми и ООД; для обучения детей татарскому языку и родному языку, |

| | |
|---|---|
| | приобщение к народным праздникам и к общечеловеческим ценностям, для знакомства детей с народными сказками; дают представление о национальном костюме и внешнем облике народов Поволжья; для организации театрализованной деятельности детей; для печатания, ламинирования, переплета и систематизации раздаточных, иллюстративных материалов, картотек, альбомов, настольно-печатных игр, наглядно-консультационного и информационного материала для детей, родителей и педагогов; при организации и проведении праздников и развлечений на улице и в помещении с воспитанниками ДОУ и родителями. |
| Эффект от реализации проекта | Благодаря реализации проекта оправданы ожидаемые результаты Проекта:<br>**Количественные результаты:**<br>• задействованы 28 педагогов, которые непосредственно работают по программе и успешно реализуют Проект (МАДОУ №113 является апробационной площадкой при РИП «Модель оценки компетенций наставника» (решение ученого совета от 31.01.20 протокол №1приказ МО и Н РТ № под-1097/18 от 13.07.2018) по теме «Основные подходы к организации речевого развития дошкольников в соответствии требованиями ФГОС ДО»);<br>• задействовано не менее 340 воспитанников ДОУ;<br>• задействовано более 500 родителей (законных представителей воспитанников) МАДОУ «Детский сад №113 «Непоседы»;<br>**Качественные результаты:**<br>1.Создана культурно-языковая среда, которая способствует приобщению детей к другой культуре с помощью этнорегиональной составляющей;<br>2. Реализованы различные формы, методы по сохранению, популяризации, развитию языка, культуры, традиций, обычаев и декоративно прикладного искусства;<br>3.Систематизирована работа по дальнейшему изучению русского и татарского языка в условиях билингвального детского сада;<br>4.Увеличено число заинтересованных родителей воспитанников в дальнейшем изучении двух государственных языков как в ДОУ, так и дома, а также их вовлеченность в образовательный процесс;<br>5.Обеспечен систематический контроль за реализацией проекта, в т.ч. учебно-методических комплектов;<br>6. Повысилась компетентность педагогов по вопросам |

| | |
|---|---|
| | билингвального образования;<br>7. Распространен опыт работы педагогов в мастер-классах, профессиональных творческих конкурсах по развитию двуязычия в ДОУ и национально-нравственному воспитанию дошкольников;<br>8. Участие в городском смотре-конкурсе художественной самодеятельности среди дошкольных образовательных учреждений г. Набережные Челны с номером по сохранению и популяризации татарского (родного) языка (Диплом 3 степени смотр-конкурса художественной самодеятельности среди работников дошкольных образовательных учреждений «Таланты вокруг нас», посвящённого Году родных языков и народного единства»).<br>Мероприятия, проводимые вне занятий в рамках Года родных языков, способствовали повышению интереса детей к изучению татарского языка и жизни народов Поволжья. |

*Оригинальность- 99,2%, ссылка https://text.ru/antiplagiat/*

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге**

**“Менә нинди кар бабай!”**

*Бахтиева Гүзәлия Ирек кызы, 1 кв.категория,*

*МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячесе,*

*Яр Чаллы шәһәре*

**Яшь үзенчәлеге буенча:** уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

**Максат:** картинаны игътибар белән карый белү, аның эчтәлеге турында фикер йөртә белү формалаштыру.

**Бурычлар:**

•**Белем бирү бурычы:** Балаларда сюжетлы картина буенча җөмләләр төзеп хикәя сөйләүне формалаштыру; исемнәрнең, сыйфатның, фигыльләрнең сүз запасын киңәйтү; картинаны игътибар белән карый белү, аның эчтәлеге турында фикер йөртә белүне формалаштыру.

•**Үстерү бурычы:** Бәйләнешле сөйләмне үстерүгә ярдәм итү; сорауларга тулы җавап бирә белү, аңлылыкны, игътибарлылыкны үстерү өчен шартлар тудыру; исемнәрнең ата-ана килеше формаларын дөрес итеп күрсәтү;

•**Тәрбия бурычлары:** Балаларда бер-берсенә карата дустанә мөнәсәбәт, күзәтүчәнлек тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗә:** Балалар схема аша картинага карап хикәя төзи беләләр; хикәяләр төзү буенча күнекмәләрен ныгыттылар.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** Оялчан балаларны активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү; авазларны дөрес әйтү өстендә эшләү.

**Сүзлек өстендә эш:** Күмерчек, юеш кар, кар бабай, йомшак.

**Алдан эшләнгән эш:** Урамда кар бабай ясау һәм нәрсәләрдән торганын карау; кыш көне, кышкы күренешләр, кышкы бәйрәмнәр, үсемлекләр, хайваннар һәм кешеләр тормышы турында балалар белән әңгәмәләр.

**Җиһазлау:** Кышкы зур агач, ак тукымалар (кар өемнәре ясау өчен), ноутбук.

**Материаллар һәм таратма әсбаплар:** “Менә нинди кар бабай!” сюжетлы картина, 4 өлештән торган балалар санынча пазл, 3 зур карлы шарлар, балалар саны буенча кечкенә шарчыклар.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Туганнан алып мәктәпкәчә программасы / Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясе, - 3 нче басма. – М.: Мозайка-Синтез, 2015.

2.Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ. Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү. Казан: Татар китап нәшрияты, 2012.

**Эшчәнлек барышы:**

**1. Оештыру өлеше.**

**Тәрбияче:** Ягез әле, балалар

Минем янга килегез,

Телик хәерле иртә
Матур үтсен көннәребез.

**Балалар:** Хәерле иртә миңа,
Хәерле иртә сиңа,
Хәерле иртә сезгә,
Хәерле иртә барчабызгада!

**Тәрбияче:** Карагыз әле өстәлдә пазл чәчелгән. Алар мөгаен сезнең жыюны көтәләрдер? Нәрсә яшерелгәнен табыйк бергәләп. *(Балалар өстәлләр янына басып пазл җыялар)*

**Тәрбияче:** Нәрсә яшерелгән булып чыкты? *(Балалар җавабы "Кар бабай")*

**Тәрбияче:** Чыннаң да Кар бабай бит бу.

**2. Төп өлеш.**

**Тәрбияче:** Кар бабайны кайсы ел фасылында ясап була? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Әйе, дөрес, кар бабайны кыш көне ясыйлар. Ә кар бабайны ясар өчен кар нинди булырга тиеш? *(Балалар җавап бирәләр)*

**Тәрбияче:** Әйе, йомшак һәм юеш кар кирәк. Кар бабай нәрсәләрдән ясалган, аның нинди өлешләре бар? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Дөрес, кар бабайны карлы шарчыклардан ясыйлар. Ә тагын нәрсәләр кирәк булды? *(Балаларның фикерләрен тыңлый)*

**Тәрбияче:** Игътибар итегез, миндә кар бабай сүрәтләнгән "Менә нинди кар бабай!" сюжетлы картина бар. *(Тәрбияче сюжетлы картина күрсәтә һәм балаларга сүрәт буенча сораулар бирелә, әңгәмә үткәрелә. Сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирү күнекмәләре ныгытыла, авазларны дөрес әйтү өстендә эш үткәрелә)*

**Тәрбияче:**Ул безнең кар бабайга охшаганмы? Тагын кемнәрне картинада күрәсез? Балаларга исем кушыйк *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Әйе, бу безнең кар бабай. Кар бабай тирәсендәниләр булуы турында сөйләгез әле? *(Балалар фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Аның янында балалар һәм тәрбияче апа бар. Балаларга *Алсу, Айгөл, Дамир* исемнәре кушыйк. Алар нишлиләр? *(Балалар фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Дөрес, балар кар бабай ясыйлар. Ә тәрбияче апа нәрсә эшли? **(***Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Тәрбияче апа балалргa булыша. Кар бабай нинди? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Кар бабай шат күңелле. Кар бабай зур, күңелле, башында чиләк, күзләре - күмерчек, борыны - кишер... Күзләре аның күмерчектән. Күмерчекләр агачларны учакта яккач барлыкка киләләр. Бергәләп әйтик. *(Балалар кабатлыйлар)*

**Тәрбияче:** Кардан без дә кар бабай ясарга барыйк. Нинди аваз чыга кардан барганда? *(Балалар төзелеп басалар һәм аваз чыгарып алдан әзерләнгән карлы аланлыктан "Шыр-шыр" дип баралар")*

**Тәрбияче:** Килеп җиттек. Әйдәгез, шарчыкларны алыйк. Зур кар бабайны бергәләп ясыйк. *(Музыка яңгырый, балалар шарчыкларны тәгәрәтәләр, тәрбияче зур шарчыклар чыгара бара, кар бабайны тезә)*

**Тәрбияче:** Кар бабайны ясадык, булдырдык. Тагын нәрсәләр җитми? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Афәрин. Күзләренә күмерчекләр, борынына кишер, авыз, башына кызыл чиләк һәм кызыл бантиклы себеркене кулына тоттырабыз. Хәзер кар бабабыз килеп чыкты. Ул чыннаң да рәсемнәң чыккан кебек, безгә кунакка килгән. Төркемебезгә кайтырга вакыт җитте инде. *(Балалалар тезелеп, шыр-шыр авазлары чыгарып, урындыкларга утыралар)*

**Тәрбияче:** Схемага карагыз *(Тәрбияче схема буенча хикәя сөйли)*

“Кыш җитте. Йомшак юеш кар яуды. Балалар җылы киемнәрен киеп урамга чыктылар. Алсу, Айгөл, Дамир зур, шат күңелле кар бабай ясадылар. Күзләре күмерчекләрдән, борыны кишердән, ә башында кызыл чиләк. Тәрбияче апа кар бабайга кызыл бантлы себерке тоттырды. Балалар кар бабайга сокланып: “Менә ичмасам кар бабай!”- диделәр”. *(2-3 бала чыгып схема буенча хикәя төзи, тәрбияче ярдәм итә)*

**3. Йомгаклау өлеше.**

**Тәрбияче:** Балалар, без сезнең белән бүген нинди сюжетлы картина карап үттек? Кар бабай нинди өлешләрдән торуны искә төшерик. *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче**: Без сезнең белән “Менә нинди кар бабай!” сюжетлы картина буенча хикәя сөйләргә өйрәндек, схема буенча ярдәм алып үзебез дә хикәя төзедек. Бергәләп кар бабайны ясап алдык. Мин сезгә “кар бабай” буягычлары бүләк итәм. Аларны сез буш вакытыгызга буярсыз һәм кар бабайны ничек ясавыбыз турында сөйләргә онытмагыз. Упамга чыгып кар бабайга күп итеп дуслар төзергә мөмкин.

*Оригинальность – 100 %, https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге:**

“Куркынычсызлык кагыйдәләре”

***Бахтиева Гузалия Ирековна, 1 кв.категория,***

*МАМББУ №113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячеләре, Яр Чаллы шәһәре Татарстан Республикасы*

**Яшь үзенчәлеге буенча:** уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

**Максат:** шәһәр урамнарында куркынычсызлык күнекмәләрен үстерү.

**Бурычлар:**

- Белем бирү бурычы: Балаларны җәяүле юлы, җәяүлеләр светофоры белән таныштыруны һәм юлда йөрү кагыйдәләрен өйрәтүне дәвам итү.
- Үстерү бурычы: Балаларның аңлылыкларын үстерү; балаларның светофорның эше турында белемнәрен ныгыту;
- Тәрбия бурычлары: Уен барышында дустанә мөнәсәбәт булдыру; балаларда урамда үз-үзеңне тоту культурасын тәрбияләү; җаваплылык хисе тәрбияләү.

**Фаразланган нәтиҗә:** Балалар җәяүлеләр юлыннан йөрергә кирәклеген ныгыттылар, җәяүлеләр светофорын автомобиль светофорыннан аера беләләр.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхсән эш:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Сүзлек өстендә эш:** Җәяүле юлы, җәяүлеләр светофоры, җәяүле, тротуар.

**Алдан эшләнгән эш:** Автомобиль юлы хакында сөйләшү.

**Җиһазлау:** Җәяүле билгеләре, ясалма юл, җәяүле светофоры, аудиоязмалар (кошлар тавышы, автомобиль тавышы), җәяүле юлы.

**Материаллар һәм таратма әсбаплар:** кошлар битлекләре, автомобильләр, таратма пазллар, буяугычлар.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Туганнан алып мәктәпкәчә программасы / Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясе, - 3 нче басма. – М.: Мозайка-Синтез, 2015.

2.Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ. Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү. Казан: Татар китап нәшрияты, 2012.

**Шөгыль барышы:**

**1.Оештыру өлеше.**

**Тәрбияче:** Балалар, әйдәгез әле бер беребезне сәламлик. Зур түгәрәк ясыйк.

**Тәрбияче:** Ниндидер тавыш килә ахрысы. Нинди тавыш микән бу? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Бу кошлар тавышы. Чынлап та, безгә бүген чыпчыклар килгән икән *(Тәрбияче балаларга чыпчык маскалары кияргә тәкъдим итә)*

**Тәрбияче:** Чыпчыкларга әйләндек һәм без оча башладык. *(Балалар чыпчыклар булып уен мәйданчыгында, юлда очалар)*

**Тәрбияче:** Тагын ниндидер тавыш килә. Нинди тавыш икән бу? *(Балаларның фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Автомобиль тиз килә. Сез автомобиль юлына чыгарсызмы? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Очыгыз урындыкларга. *(Балалар урындыкларга утыралар. Юл макетына автомобильләр куела)*

**2. Төп өлеш.**

**Тәрбияче:** Балалар, без сезнең белән дөрес җирдә уйнадыкмы? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Юк шул, автомобиль юлындща уйнарга ярамый. Бу юлдан нәрсәләргә генә йөрергә ярый соң? *(Балаларның фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Бик дөрес. Чыпчыклар безне тагын алып китмәс өчен, аларны өстәлгә алып куйабыз. Алар да безгә карап өйрәнсеннәр. *(Балалар маскаларны салып куялар)*

**Тәрбияче:** Балалар, кайда уйнарга ярый соң? *(Балаларның фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Әйе, тик уен мәйданчыгында гына уйнарга ярый, автомобиль юлы янында уйнарга ярамый. Юлны безгә аркылы чыгарга туры килсә, кайдан чыгарга була? *(Балалар әйтеп карый)*

**Тәрбияче:** Юлны безгә аркылы чыгарга туры килсә җәяүлеләр юлын табарга кирәк. Әйдәгез. бергә әйтеп карыйк. *(Тәрбияче артыннан кабатлыйлар)*

**Тәрбияче:** Җәяүлеләр юлын үткәндә уйнарга ярыймы? Кагыйдәләрне бозсаң, нәрсә килеп чыгарга мөмкин? *(Балаларның фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Җәяүле юлын чыгар алдыннан уңга, сулга карарга, транспортның туктаганын көтәргә кирәк, ә аннары олылар белән җитәкләшеп юлны чыгарга мөмкин. Әйдәгез әле, без дә икешәрләп басыйк. Ничек чыгабыз булды юлны? *(Балалар җаваплары тыңланыла)* Уңга-сулга карыйбыз һәм олыоларны җитәкләп чыгабыз. Кошларыбыз игътибар белән тыңлап торалар. *(Тәрбиче артыннан икешәрләп, кагыйдәне искә төшереп, җәяүлеләр юлыннаң чыгалар) (Җәяүлеләр светофоры куела)*

**Тәрбияче:** Балалар бу нәрсә? *(Балаларның фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Бу безнең җәяүлеләр светофоры. Бергә әйтик. *(Балалар тәрбияче артыннан кабатлыйлар)*

**Тәрбияче:** Җәяүлеләр юлыбыз җайга салынган юлга әйләнде.

**Тәрбияче:** Җәяүлеләр светофорының ничә сигналы бар? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Җәяүлеләр светофорының ике сигналы бар: кызыл һәм яшел.

**Тәрбияче:** Яшел сигнал янса - урыннарда атлыйк, кызыл сигнал янса - кул чабыйк.

**Уен: "Светофор ничек караса шулай эшлик"**

**Тәрбияче:** Афәрин. Хәзер җәяүлеләр светофорына карап юлны үтик. Кызыл янса - басып торабыз, яшел янса - юлны аркылы чыгабыз. Уңга-сулга карарга онытмагыз, транспортның туктаганың какрарга кирәк. *(Юлны аркылы чыгалар светофорга карап)*

**Дидактик уен "Светофор"** *(Балалар өстәлләрдә һәрберсе 2 сигналдан торган җәяүлеләр светофоры җыялар)*

**3. Йомгаклау өлеше.**

**Тәрбияче:** Уен мәйданчыгында түгәрәк ясыйк һәм кайда уйнарга кирәклеген искә төшерик. Юл аша чыгарга кирәк булса ничек чыгарбыз, нинди кагыйдәләр истә калдырдыгыз? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Уен мәйданчыгында гына уйнарга ярый. Юлны аркылы чыкканда уңга-сулга карарга, транспортның туктаганың какрарга һәм олыларны җитәкләп чыгарга кирәк.

**Тәрбияче:** Чыпчыкларыбыз бүтән автомобиль юлыннаң уйнамас дип ышанып калабыз инде. Алар безнең белән тагын уйныйсылары килә. Кайда очарбыз? *(Балалар җавап бирәләр)*

**Тәрбияче:** Дөрес, уен мәйданчыгында. *(Балалар кошлар битлекләрен киләр һәм мәйданчыкта очалар, музыка яңгырый)*

**Тәрбияче:** Афәрин. Безгә буяугычлар чыпчыклар алып килгән. Без аларны сезнең белән буярбыз.

*Оригинальность- 95,11%, ссылка https://text.ru/antiplagiat/*

# Оештырылган белем бирү эшчәнлеге
# “Йорт һәм кыргый хайваннар, аларның кышка әзерләнүе”

*Бахтиева Гүзәлия Ирек кызы, 1 кв.категория,*
*МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячесе,*
*Яр Чаллы шәһәре*

**Яшь үзенчәлеге буенча:** Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

**Максат:** Хайваннарның кышка әзерлек чорындагы тормышы турында күзаллауны формалаштыру.

**Бурычлар:**

•**Белем бирү бурычы:** Балаларда йорт һәм кыргый хайваннары, аларның үзенчәлекле яклары, кышка әзерлекләре турындагы белемнәрен камилләштерү.

•**Үстерү бурычы:** Кыска хикәя төзи белү күнекмәләрен формалаштыру; зиһенне, игътибарлыкны, фикерләүне, күзаллауны үстерү.

•**Тәрбия бурычлары:** Әйләнә-тирә дөньяга сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү; төркемдә, коллективта аралашу осталыкларын тәрбияләү; хайваннар турында кайгырту теләген формалаштыру.

**Көтелгән нәтиҗә:** Балаларның хайваннар турында белемнәре артты.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** Уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** Оялчан балаларны активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү; авазларны дөрес әйтү өстендә эшләү.

**Сүзлек өстендә эш:** Кыргый хайваннар, йорт хайваннары, җылы як хайваннары, куян, керпе, аю, тиен, фил, арыслан, жираф, азык туплау, җайлашу, йон.

**Алдан эшләнгән эш:** Көз үзенчәлекләре белән балаларны таныштыру, көз турында шигыр өйрәнү, балалар белән хайваннарны рәсемнәр буенча карау; хайваннар турында шигырьләр һәм табышмаклар уку, иллюстрацияләр карау, д/у «Кем, нәрсә ашый?».

**Җиһазлау:** хайван уенчыклары һәм рәсемнәре, аудиоязма, виммельбух “Кыргый хайваннар”; буягычлар, интерактив уен “Кем, кайда яши?”, көз турында иллюстрацияләр.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Туганнан алып мәктәпкәчә программасы / Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясе, - 3 нче басма. – М.: Мозайка-Синтез, 2015.

2.Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ. Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү. Казан: Татар китап нәшрияты, 2012.

**Эшчәнлек барышы:**

**1. Оештыру өлеше.**

**Тәрбияче:** Ягез әле, балалар
Урамга карыйк әле,
Урамдагы агачлар
Елмаерга кушалар.

Хәерле иртә миңа,
Хәерле иртә сиңа,
Хәерле иртә сезгә,
Хәерле иртә барчабызгада! *(Балалар тәрбияче белән бергә сөйлиләр)*

**Тәрбияче**: Нинди ел фасылы хәзер? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Дөрес, урамда көз. Нинди сыйфатлар буенча сез көз дип атыйсыз? (*Балаларның фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Көзен салкын, юеш, яңгыр ява, җил исә. Көз көне терек булмаган табигатьтә нинди үзгәрешләр була? Шигырьне искә төшерик *(Балалар хәрәкәтләр ясап, өйрәнелгән шигырьне сөйлиләр)*

Яфракларны күр әле *(Кулларны күтәрәләр)*
Алтын төскә кергәннәр. *(Кулларны әйләндерәләр)*
Бар дөньяны күмгәннәр. *(Куллар аска төшә)*
Җил чыкканда шаулашалар, *(Җил хәрәкәтләрен күрсәтәләр)*
Оча-оча уйнашалар, *(Куллар өстән аска төшеп меңәләр)*
Һавада әйләнәләр
Һәм җиргә сибеләләр. *(Кулларны төшерәләр)*

**2. Төп өлеш.**

**Тәрбияче:** Ягез әле, китапка карап алыйк. Нәрсәдер яшерелгән, ахры. Балалар, мин сезгә табышмаклар әйтәм, ә сез жавабын табыгыз.

Кишер белән кәбестәне
Ул бик нык ярата,
Озын колагын тырпайтып
Сикереп урманга кача. *(Балаларның җаваплары тыңланыла.)*

Бер нәрсә тегә белми,
Энәләр тагып йөри. *(Балалар җавап бирәләр)*

Җәен урманга патша,
Кышын кардан да аста. *(Балаларның фикерләре тыңланыла)*

Мамык тун киям
Куе урманда яшим,
Иске имән куышында
Чикләвекне мин кимерәм. *(Балаларның фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Әйе, балалар, куян, керпе, аю, тиен турында табышмакларына җавап таптык.

**Тәрбияче:** Бер сүз белән алар нинди хайваннар? *(Балалар җавап бирәләр)*

**Тәрбияче:** Кыргый хайваннар – бик дөрес! *(Балалар кабатлыйлар)*

**Тәрбияче:** Кыргый хайваннар кайда яши? *(Балаларның фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Алар урманда яшиләр. Тагын нинди кыргый хайваннарны беләсез? *(Балаларның җаваплары тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Фил, жираф, арыслан...алар кайда яшиләр? *(Балаларның фикерләре тыңланыла)*

**Тәрбияче:** Фил, жираф, арыслан - җылы як хайваннары. *(Балалар кабатлыйлар)*

**Тәрбияче:**Ни өчен кайбер хайваннар җылы якта яшиләр икән? *(Балалар җавап бирәләр)*

**Тәрбияче:** Дөрес, кайбер хайваннар шул якка җайлашып туганнар.

**Хәрәкәтле уен**

Ак куян утыра
Колакларын кыймылдата,
Куянга салкын утырырга
Аяк табаннарын җылытырга кирәк.
Куянга салкын басып торырга,
Сикереп алырга кирәк.
Кемдер куркытты куянны.
Куян сикереп качып китте. *(хәрәкәтләр белән уен)*

**Тәрбияче:** Кеше янында, йортта яшәүче хайваннар бар. Аларны ничек дип атыйлар? *(Балаларның фикерләрен тыңлый)*

**Тәрбияче:** Алар йорт хайваннары. Йорт хайваннарыннаң кемне атый аласыз? *(Балалар җавап бирәләр)*

**Тәрбияче:** Урамда көз фасылы. Ничек уйлыйсыз, йорт хайваннары кышка әзерләнәме? *(Балалар җавап бирәләр)*

**Тәрбияче:** Юк, йорт хайваннарын кышка кеше әзерли.

**Тәрбияче:** Кыргый хайваннар кышка ничек әзерләнә? *(Балаларның фикерләрен тыңлый)*

**Тәрбияче:** Көз көне куян, керпе, аю, тиен дә кышка әзерләнә. Куян һәм тиен үзенең туның алмаштыралар, көзен кышка һәрберсе азык өйләренә туплыйлар. Аю һәм керпе йокыга китә язга кадәр *(Рәсемнәр күрсәтелә)*.

**Тәрбияче:** Экранда кыргый хайваннарның яшәү урыннары күрсәтелгән. Балалар, сезгә хайваннарны дөрес итеп өйләренә урнаштырырга кирәк.

**Интерактив дидактик уен “Кем, кайда яши?”**

**3. Йомгаклау.**

**Тәрбияче:** Балалар, ә хәзер әйдәгез әле искә төшерик нәрсәләр эшләдек бүген? *(Балалар җавап бирәләр)*

**Тәрбияче:** Дөрес балалар, без бүген йорт һәм кыргый хайваннарны искә төшердек, аларның яшәү урыннарын эзләп таптык, кыргый хайваннарның кышка ничек итеп әзерләнүен уарап үттек.

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз! Рәхмәт сезгә! Мин сезгә хайваннар сүрәтләнгән буяуларны таратам, аларны үзегез теләгәнчә буярсыз.

*Оригинальность- 93,22%, ссылка https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге**

“Урманга сәяхәт”

*Булатова Ләйсән Наил кызы, 1 кв.категория,*
*МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячеләре,*
*Яр Чаллы шәһәре*

**Яшь төркеме:** Уртанчылар төркеме (4-5 яшь).

**Максат:** Балаларда кыргый җәнлекләр һәм кошларга карата экологик мөнәсәбәт формалаштыруны дәвам итү.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычлары:** Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү; сүзлек запасын баету һәм активлаштыру; балаларның бер-берсен тыңлый белү,игътибарлылыгын үстерү.

**Тәрбия бурычлары**: Кыргый җәнлекләргә, кошларга карата сак караш,эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту; табигатькә ихтирам булу тәрбияләү; балаларда бер-береңә карата дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү, башкаларга ярдәмгә килергә әзер булу.

**Белем бирү бурычлары**: балаларның сүз байлыгын активлаштыру; балаларда "транспорт" гомумиләштерелгән төшенчәсен формалаштыру; төрле транспорт төрләре турында күзаллауны беркетү; кыргый хайваннар турындагы белемнәрне беркетү, кыргый хайваннар эзләрен аера белү сәлатен беркетү.

**Фаразланган нәтиҗә:** Балалар алган белемнәрен мөстәкыйль уен эшчәнлегендә куллана беләләр; күчмә транспортның төрләрен аера белү белемен, кузаллауны ныгыттылар; әйләнә-тирә табигатькә, кыргый җәнлекләргә, кошларга карата сакчыл, ярдәмчелек, мәрхәмәтлелек, дуслык кебек мөнәсәбәтләрен тәрбияләделәр.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** оялчан балаларны активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек өстендә эш:**

**Актив сузлек:** кыргый җәнлекләр, транспорт, эзләр, йөк автомобиле, җиңел автомобиль, (автомобиль) автобус, вертолет, поезд, очкыч, кораб, эзләр, куян, тиен, аю, бүре, керпе, кабан, поши, тукран, саескан, сандугач, күке, песнәк, ябалак.

**Пассив сузлек:** серле сандык, ковер-самолет, табигать, буран, шаян, кар йомгагы.

**Алдан эшләнгән эш:** Әңгәмә, кышкы табигать турында сюжетлы картиналар карау, кар өстендәге эзләрне күзәтү; "Транспорт" һәм “Кыргый хайваннар” темасы буенча предметлы һәм сюжетлы рәсемнәрне карау; прогулкада күзәтүләр, әңгәмәләр, дидактик уеннар.

**Демонстрацион материаллар һәм җиһазлар**: Интерактив такта, ноутбук, “Кышкы урман”, “транспорт”, ”кыргый җәнлекләр”, “кошлар” рәсемнәре, “сүрәтләнгән җәнлекләр эзләре”(бирем белән), сандык, хат, куян баласы уенчыгы, ковер, кар йомгагы (синтепоннан ясалган).

**Таратма әсбаплар:** җәнлекләр битлекләре, кыргый җәнлекләр рәсеме һәм сүрәтләнгән җәнлекләр эзләре (д/у), буягычлар.

**Кулланган әдәбият:**

1.Туганнан алып мәктәпкәчә программасы/ Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясе, -3 нче басма.-М.:Мозайка-Синтез, 2015;

2. Занятия по развитию речи в старшей группе детского сада./Гербова В.В. М.:Просвещение, 2006.

**Эш барышы:**

**1. Кереш өлеше.**

Сүзле уен "Кәефләрегез ничек?" *(Эмоциональ халәт тудыру, кереш оештыру моменты. Балалар түгәрәк ясап басалар)*

**Тәрбияче.** Балалар,әйдәгез әле матур шигырь юллары белән кәефне тагын да күтәрик

- Кояш уянды да, ямьле елмайды (*кулларны өскә таба сузалар, елмаялар*)

- Кояшкай сиңа таба нурларын сузды. (*кулларны алга таба сузалар*)

-Сыйпый-сыйпый йомшак йөзеңне (*битне сыйпыйлар*)

-Хәерли иртәләр,үскәнем-дип теләде. (*бер-берсенә елмаялар*)

**Тәрбияче:** Балалар,мин сезгә хәзер бер табышмак әйтәм,тыңлагыз:

Үзе –шкаф,
Үзе- караватt,
Үзе-өстәл ,
Бар дөньясын
Йорт җылысын
Сыйдырган бирнә *(җиһазы -сандык)*

(*Тәрбияче балаларның җавапларын тыңлый*)

**Тәрбияче.** Әйе, дөрес җавап бирдегез, бу - сандык! Әби-бабаларыбызның иң күркәм, кадерле җиһазы.

**Тәрбияче.** Балалар,мин бүген эшкә килгәндә, ишек төбендә шул сихри сандыкны таптым. Әйдәгез әле, аны бергәләшеп ачып карыйк. (*Балалар белән ризалашып, сандыкны ачалар. Сандыкны ачканда,сихри моң уйный*).

**2. Төп өлеш.**

**Тәрбияче.** Балалар, бу гади сандык түгел икән, ә сихри. Карагыз әле, аның эчендә хат.

**Тәрбияче.** (*Хатны укый*)

"- Кадерле балалар, зинһар өчен, миңа ярдәм итегез! Миңа бик салкын, мин куркам*"(Тәрбияче хатны әйләндергәләп карый*).

**Тәрбияче.** Балалар, кем җибәрде икән безгә бу хатны? (*Балаларның фикерләрен тыңлый*)

**Тәрбияче.** Шулай..аңлап булмый... бәлки тиен, куян. Сезнең хат хуҗасына ярдәм итәсегез киләме? *(Тәрбияче балаларның фикерен тыңлый)*

**Тәрбияче.** Дөрес, балалар, әлбәттә ярдәм итәргә кирәк, булышыр өчен каядыр барырга кирәк. Әйтегез әле, ерак юлга нинди транспорт белән барып була? *(Тәрбияче балаларның җавабын тыңлый)*

**Тәрбияче.** Әлбәттә балалар, җиңел автомобиль, автобус, поезд, висәпит, очкыч, кораб белән барып була.

**Тәрбияче.** Бу әйберләрне ничек бер сүз белән атап була? (*Балаларның җавабын тыңлый)*

**Тәрбияче.**Әйе, балалар, бу атап үткән әйберләр – транспорт төрләре. *(Транспорт турында әңгәмә үткәрелә)*

**Тәрбияче.** «Транспорт» сүзе үзе күчеш дигәнне аңлата. Шуңа күрә транспорт дип, гадәттә, пространствода хәрәкәт итүче: йөри, оча, йөзә торган транспортлар карала. Һәм шул ук вакытта алар йөкләрне һәм кешеләрне ташый.

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле, сандыкта тагын нәрсәдер бар... *(Тәрбияче сандыктан ковер тартып чыгара)*

**Тәрбияче.** Балалар,бу бит тылсымлы ковер-самолет! *(Коверны бергәләшеп идәнгә җәяләр)*. Без шуңа утырып сәяхәт итәбез, хат язучы дустыбызгә ярдәмгә очабыз.

**Физкультминутка.**

Кулларны бөтенебез үрелешкә куябыз, (*кулларны як якка тарталар* )

Самолет килеп чыкты.

Тегендә-монда селкетәбез канатны (*куллар белән өскә-аска селкетәләр*)

Бер эшлә,ике эшлә.

Бер,ике,бер,ике!

Кулларны өскә күтәрик (*кулларны өскә тарталар*)

Бер-беребезгә карашыйк.

Бер, ике, бер, ике...

Кулларны аска төшерик(*кулларны аска төшерәләр*)

Урынга тизрәк утрыйк! (*Балалар утыралар ковер-самолетка, күзне йомалар,уйный сихри моң).*

**Тәрбияче.** Балалар без кая килеп җиттек? (*Экранда кышкы урман рәсеме. Тәрбияче балалар җавабын тыңлый*)

**Тәрбияче.** Балалар, урманда нинди ел фасылы сүрәтләнгән? Нинди агачлар үсә? *(Тәрбияче балаларның җавабын тыңлый)*

**Тәрбияче.** Әйе,урманда кыш фасылы. Урманда чыршы, нарат, каен, имән агачлары үсә.

**Тәрбияче.** Урманда нинди җәнлекләр, кошлар яши?(*Тәрбияче балаларның җавабын тыңлый)*

**Тәрбияче.** Әлбәттә, дөрес, балалар, урманда куян, тиен, бүре, аю, керпе, кабан, поши кебек җәнлекләр яши.Тукран, саескан, сандугач, күке, песнәк, ябалак кошлары яши.

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле кем безнең каршыбызга килеп чыкты? *(Аудиотавыш...куян килеп чыга)*

**Тәрбияче.** Куянкай безгә хат язган икән, ярдәм сорап! Балалар, куянга безнең ярдәм кирәк.Урманда берничә көн буран дуылдаган. Бөтен җәнлекләрне качырган. Безнең дустыбыз адашкан, аяклары бик туңган, дусларын таба алмый. Әйдәгез, балалар, куянга булышыйк, аның белән уйнап алыйк, аякларын җылытыйк, дусларын табырга булышыйк.

**Уен** *(Балалар түгәрәккә баса, башларына җәнлек битлекләре кигерелә)*

Бар матур урман (*түгәрәктә йөриләр*)

Анда җәнлекләр яши

Менә шундый зур аю

Менә шундый кечкенә (*хәрәкәт белән күрсәтәләр*)

Аю аю кил әле, *(аю битлеген кигән бала уртагачыга,бии)*

Биеп кит әле.

Әллә-лә,әллә-лә

Биеп биеп кит әле. *(шулай бер-ничә тапкыр түгәрәк буйлап йөриләр, уртага чыга төрле битлек кигән бала, алышынып).*

**Тәрбияче.** Яхшы балалар, булдырдыгыз! Куянкайның аяклары җылынды.

**Тәрбияче.** Балалар,карагыз әле кар өстендә ниндидер кыргый-җәнлекнең эзләре калган. Кемнең эзләре икән бу?

**Тәрбияче.** Балалар, кар өстендә куян, тиен, бүре, аю эзләре төшеп калган. Ләкин аларны кар каплап калдырган, куян шуңа дусларын таба алмый икән бит.

**Дидактик уен "Эзләр"** *(Балалар 3 командага бүленәләр. Өстәлдә һәрбер командага эзләрнең хуҗасын табырга тәкъдим ителә)*

**Тәрбияче.** Балалар без сезнең белән куянга булыштык,сәяхәтебез шуның белән тамам, безгә кире балалар бакчасына кайтырга кирәк. (*Куян балалар белән саубуллашып чыгып китә).* Әйдәгез ковер-самолетка утырабыз, күзләрне йомабыз.*(Аудиотавыш яңгырый)*

Кулларны бөтенебез үрелешкә куябыз, *(кулларны як якка тарталар)*

Самолет килеп чыкты.

Тегендә-монда селкетәбез канатны *(куллар белән өскә-аска селкетәләр)*

Бер эшлә,ике эшлә.

Бер,ике,бер,ике!

Кулларны өскә күтәрик *(кулларны өскә тарталар)*

Бер-беребезгә карашыйк.

Бер, ике, бер, ике...

Кулларны аска төшерик *(кулларны аска төшерәләр)*

Урынга тизрәк утрыйк! *(Балалар утыралар ковер-самолетка, күзне йомалар,уйный сихри моң).*

*(Кайтып җиткәч,сандыктан моң ишетелә.Ачып карыйлар*).

**Тәрбияче.** Карагыз,балалар, шаян куяныбыз безнең сандыкка кар йомгагын салып җибәргән. Аның эчендә нәрсәдер бар бугай. *(Тәрбияче бабаларга буягычлар күрсәтә)*

**3.Йомгаклау өлеше.**

**Тәрбияче.** Балалар, без сезнең белән кемгә булыштык? Нинди җәнлекләрнең эзләрен табарга булыштык? Сезнең исегездә күбрәк нинди уеннар калды? *(Тәрбияче балаларның фикерләрен тыңлый).*

**Тәрбияче.** Әйе, балалар, без бүген күңелле сәяхәттә йөрдек, ковер-самолет белән очтык. Кышкы урманда җәнлекләрне, кошларны күрдек. Иң мөһиме, куян дустыбызга ярдәм иттек, аның белән бергә күңеле уен уйнадык. Куянкай

да безне кўчтәнәче белән шатландырды. Сез бүген барыгыз да булдырбыгыз! Әфәрин!

*Оригинальность- 78.02%, ссылка https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге**
**“Кошлар илендә сәяхәт”**

*Булатова Ләйсән Наил кызы, 1 кв.категория,*
*МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячеләре,*
*Яр Чаллы шәһәре*

**Яшь төркеме:** зурлар төркеме (5-6 яшь).

**Максат:** Балаларның күчмә һәм кышлаучы кошлар турында кузаллауларын формалаштыру.

**Бурычлар:**

-**Белем бирү бурычлары:** Кышлаучы һәм күчмә кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү; кошларның яшәү рәвеше, ел фасылларына ничек җайлашуы турындагы белемнәрен арттыру.

-**Үстерү бурычлары:** хәтер һәм фикер йөртү сәләтен үстерү, сүз байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен камилләштерү, эзлекле һәм мөстәкыйль фикерләүне, күзәтүчәнлекне үстерү.

-**Тәрбия бурычлары:** Балаларда кошлар тормышы турында кызыксыну уяту; авыр, салкын кышкы шартларда, кошларга карата ярдәм хисен, мәрхәмәтлелек, сакчыл караш тәрбияләү.

**Фаразланган нәтиҗә:** Балалар алган белемнәрен мөстәкыйль уен эшчәнлегендә куллана беләләр; кышлаучы, күчмә кошлар төрләрен аера белү белемен, кузаллауны ныгыттылар; әйләнә-тирә табигатькә, кошларга карата сакчыл, ярдәмчелек, мәрхәмәтлелек, дуслык кебек мөнәсәбәтләрен тәрбияләделәр.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** оялчан балаларны активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү; тулы, дөрес җөмләләр төзергә ярдәм итү, игътибарларын тупларга булышу.

**Сүзлек эше:**

**Актив сүзлек:** кошлар, күгәрчен, песнәк, карга, тукран, саескан, чыпчык, кызылтүш, канатлар, муен, баш, гәүдә, койрык, сәяхәт, ил, күк, кыш, ел, фасыл.

**Пассив сүзлек:** күгелҗем, җимлек, кырау, кырпак, ак-ак, кып-кызыл, могҗизалар, тылсымлы, шар, каурыйлы.

**Алдан эшләнгән эш:** кошлар турында әңгәмәләр; кош сүрәтләрен карау һәм ясау, эчтәлеге буенча хикәя төзеп сөйләү; ата-аналар белән бергә җимлекләр ясау , җимлеккә килүче кошларны ашату, күзәтү; кошлар турында шигырьләр, хикәяләр уку.

**Демонстрацион материаллар һәм җиһазлау:** Кошлар, кыш рәсемнәре, дидактик уенга материаллар: кош, җим фотолары, тартма; биремле конвертлар, хат, шар, экран, проектор, аудиотавышлар; чыршы, кошлар макетлары; җимлек, сюрприз буяучыклар.

**Таратма әсбаплар:** кошлар рәсеме, җим, кошлар һәм төрле җим фотолары (д/у).

**Кулланган әдәбият:**

1.Туганнан алып мәктәпкәчә программасы/ Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясе, -3 нче басма.-М.:Мозайка-Синтез, 2015;

2. Занятия по ознакомление с предметным и социальным окружением в старшей группе детского сада./Дыбина О.В. М.:Просвещение, 2006.

3.Ознакомление с природой в детском саду./Соломенникова .

**Эш барышы:**

**1.Кереш өлеше.**

(*Балалар түгәрәк ясап басалар*).

**Тәрбияче.** Хәерле иртә! Хәерле иртәләр, балалар!

**Тәрбияче.** Балалар, әйдәгез әле яхшы кәеф бер-березгә бүләк итик:

-Исәнме,нурлы кояшкай! (*Кулларны өскә таба күтәрәләр*)

-Исәнме,аяз кук! (*Кулларны өстән җанатар итеп төшерәләр* )

-Исәнме,ямьле дөнья! (*Кулларны алга таба сузалар,елмаялар*)

-Барыбызга да имин-шатлыклы иртәләр! (*Бер-берсе белән кулга-кул тотынышып елмаялар*)

**Тәрбияче**. Балалар, мин сезне бүген сәяхәткә чакырам. Кая барабыз икәнен сез уйлагыз. Нинди тавышлар ишетелә? (*Янгырый төрле кошлар тавышы, аудиотавыш) (Балаларның җавабын тыңлый)*

**Тәрбияче.** Дөрес, балалар, бу кошлар тавышы. Димәк, без кошлар иленә сәяхәткә барабыз.

**"Кош буласым килә"**

-Мин урамда уйнадым
-Төрле кошлар санадым
-Бер, ике, өч, дүрт, биш
-Бишкә кадәр санадым
-Карадым өскә күккә
-Аннары сулга,уңга
-Чыпчык буласым килде
-Кулларны як-якка сузып
- Селкетә мин башладым
-Кулларны өскә, аска
-Сикердемдә, җиргә килеп утырдым.

(*Каршыларына шар очып керә, җептә хат бәйләнгән. Тәрбияче гаҗәпләнгән йөз белән балаларның игътибарын шарга таба юнәлтә. Хатны алып укый)*.

**2.Төп өлеш**

**Тәрбияче.** "Исәнмесез,балалар! Безгә сезнең ярдәм кирәк. Без бик туңдык, безнең ашыйсы килә, безне тизрәк табыр өчен биремнәрне үтәргә кирәк".

**Тәрбияче**. Балалар, бу хатны кем язган икән?! Алларга бездән ярдәм кирәк. *(Балалар фикерен тыңлый*)

**Тәрбияче** .Әйе, бу хатны безгә кошлар язган, әйдәгез аларга ярдәм итик. Безне бүген бик кызыклы эшләр көтә. Беренче хатны ачабыз.

**Тәрбияче**. Балалар хәзер нинди ел фасылы? (*Балалар фикерен тыңлый Тәрбияче тулы җөмләләр белән җавап бирергә кирәк булуын искә төшерә*)

**Тәрбияче**. Хәзер урамда кыш фасылы. Бездә нинди кошлар кышлый? Аларны ничек дип атыйлар? (*Балалар фикерен тыңлый*)

**Тәрбияче.** Бездә күгәрчен, карга, чыпчык, саескан, песнәк, кызылтүш(карабүрек), тукран кошлары кышлый. Аларны кышлаучы кошлар дип атыйлар.

**Тәрбияче**. Балалар, ә тагын нинди кошлар бар? Алар турында әйтеп китегез. *(Балалар җавабын тыңлый*)

**Тәрбияче.** Әлбәттә, карлыгач, кара карга, аккош, сандугач, ләкләк. Бу кошларны күчмә кошлар дип атыйлар. Балалар хәзер без сезнең белән уен уйнап алабыз. Мин сезгә кошлар турында укыйм, ә сез аларны дөсер итеп белеп, хәрәкәт ясарсыз.

**Уен** “**Кышлаучы һәм күчмә кошлар**” **(***Кышлаучы кошларга-чүгәләп утыралар, ә күчмә кошларга-кулларны ике якка сузып селкетәләр өскә-аска)*

**Тәрбияче**.*(Тәрбияче икенче биремне укый, экранда кошлар рәсеме чыга).* Кошлар бер-берсенә нәрсә белән охшаш? (*Балалар җавабын тыңлый*)

**Тәрбияче**. Кошлар гәүдә, муен, баш, канатлар, койрык, аяклар белән охшаш, башта күзләр-томшык, гәүдәдә түш бар. Бөтен гәүдәсе каурыйлы. Кошлар нәрсә белән бер-берсеннән аерыла? (*Балалар фикерен тыңлый)*

**Тәрбияче.** Дөрес, песнәкнең түше сары, ә карабүрекнең кызыл түше. Тукраның башы кып-кызыл, томшыгы озын, саесканың гәүдә крыйлары ак. Карга - зур канатлары кап кара**,** чыпчык - кечкенә**.** Менә ничек күп аермаларын беләсез, әфәрин. (*Тәрбияче өченче биремне укый*)

**Тәрбияче.** Кошларның тавышын тыңлап-танып дөрес җавап әйтеп крагыз! (*Аудиотавыш тыңлыйлар*)

**Уен** ”**Кем нинди тавыш бирә**” (*дөрес җавапка экранда кошнын сүрәте чыга*) Балалар тавыш ияру фигылен сүрәтли:

-Чыпчык-чыркылдый

-Күгәрчен-гөрли

-Тукран-тукылдый

-Саескан-чаркылдый

-Песнәк-четерек

(*Каршыда чыршы агачы макеты тора, аның куаклрында кошлар кунган. Тәрбияче балаларның игътибарын чыршыга юнәлтә ,дүртенче биремне укый*)

**Тәрбияче.** Балалар, менә кая икән безнең кошлар утыра, алар бик туңганнар аларны җылытырга кирәк.

**Сулыш гимнастикасы “Чыпчыкны җылыт”**

**Тәрбияче.** Балалар чыршыда күпме кошлар күләгәләре, мин сезгә хәзер табышмак әйтәм, ә сез нинди кош икәнен уйлап, дөрес җавабып әйтеп, кошны күләгәсе белән тоташтырырсыз.

- Соры канатлы кош,

Ярата ул көнбагыш
Тәрәз төбендә гөрләп утыра (*Күгәрчен*)
- Агачта мин шакылдыйм
Корты табасым килә
Кабык астында качсаң да,
Барыбер минеке буласың(*Тукран)*
- Юлдан сикереп йөри,
Песидән курыкмаган кебек
Ипи ватыкларын җыя,
Аннан соң ботакка сикереп,
Чыркылдый: "чик-чирик" (*Чыпчык*)
- Матурлана куакта
Сары тушле кош. (*Песнәк)*
- Башында кара бүрек, түшендә кызыл җилет. (*Кызылтүш*).

(*Тәрбияче балаларның җавабын тыңлый, балаларның эшләүнең дөреслеген күзәтә*)

**Тәрбияче.** Әфәрин! Әлбәттә, бу кызылтүш, күгәрчен, тукран, чыпчык, песнәк. Кошларның гүзәллегенә сокланып, моңлы сайлауларын ишетеп, йөрәк шатлана. Кошлар безнең кечкенә каурыйлы табиблар. Алар агачларны, үсемлекләрне зарарлы бөҗәкләрдән чистарталар. Балалар, уйлап карагыз әле! Кошларга кыш көне нәрсә куркынычрак: кышкы салкынмы, әллә ачлыкмы? *(Балалар җавабын тыңлый)*

**Тәрбияче.** Кыш көне кошлар кырыс салкынга караганда, күбрәк ачлыктан куркалар. Чөнки кош озак вакыт ашамаса, ул үләчәк. Шуңа күрә кошлар ашап җылыналар.

**Тәрбияче**. Балалар, кышлаучы кошлар кыш көне нәрсә ашыйлар? (*Тәрбияче балалар фикерен тыңлый*)

**Тәрбияче**. Кошлар көздән калган агачта җиләк-җимешләр белән, ә аларны ашап бетергәч, кешеләр янына очып киләләр. Кешеләр кошларга ясалган җимлекләргә җим салалар, ярдәм итәләр. Без кошларны нәрсәләр белән сыйлый алабыз? (*Балалар җавабын тыңлый*)

**Тәрбияче**. Без төрле ярмалар, каткан ипи валчыклары, ит мае җимлеккә салабыз. Төрле орлыклар, көнбагыш, карбыз, кабак төшләре сибәбез.

**Дидактик уен "Кем, нәрсә ярата**?"(*Балалар парлашып эшлиләр, кошны ризыгы белән тоташтырып, җимлеккә ләктереп баралар)*

**Тәрбияче.** Дөрес, сыерчык ит мае ярата. Карабүрек миләш, балан ашый. Каргалар, чыпчыклар, күгәрченнәр ипи валчыклары, ярмалар яраталар.

**Тәрбияче**. Менә ничек әйбәт кошларгада ярдәм иттек бүген!

**3. Йомгаклау өлеше:**

**Тәрбияче.** Балалар, бүгенге дәрестә без нинди яңа һәм кызыклы әйберләр белдек? Нинди кошлар белән таныштык? Нинди каршылыклар үтәргә туры килде? Сезгә бүгенге дәрестә нәрсә күбрәк ошады? *(Балалар җавабын тыңлый, тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү)*

**Тәрбияче.** Балалар, сез мине бүгенге дәрестә бик шатландырдыгыз. Без кышлаучы һәм күчмә кошлар турында сөйләштек, алар турында бик күп белдек. Кыш көне аларны тагын да күбрәк кайгыртырга, игътибарлы булырга кирәк икәнен аңладык. Иң мөхиме – без туңган кошларны табып, аларны ашаттыкһәм аларны үлемнәңмкоткра алдык. Биремнәрне тиз үтәдек, бердәм булдык.

*Оригинальлек- 93.75%;https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге конспекты**

**“Чыршы агачында Петрушка”**

***Гарипова Гузель Котдусовна -1 кв.категория,***

***Тимерханова Алия Разяповна - 1 кв.категория,***

*МАМББУ №113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячесе*

*Яр Чаллы шәһәре*

**Төркемнең яше**: зурлар төркеме (5-6 яшь)

**Максат:** Балаларны кәгазьдан сурәтләр ясауда осталыкларын ныгыту.

**Бурычлар:**

**Үстерүче:**

- Төсләрне дөрес аера белүне ныгыту;
- Төрле төсләрне ябештереп кеше кыяфәтендәге шаян Петрушка сурәтен чагылдырырга өйрәнү;

**Тәрбияви:**

- Бирелгән биремне пөхтә итеп эшләүне тәрбияләү;
- Төркемдә эшләргә өйрәтү;
- Үзара дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү;
- Башланган эшне азагына кадәр башкарып чыгуга ирешү;

**Белем бирүче:**

- Балаларның овал һәм түгәрәк формадагы өлешләрне, квадраттан 2 өчпочмак кисәргә өйрәнүне дәвам итү;
- Кәгазьдән симметрияле өлешләрен дөрес итеп кисүне булдыру (җиң, Петрушканың чалбар балагы);
- Киселгән өлешләрне пөхтә итеп ябештерергә өйрәнүне дәвам итү;
- Кайчы белән дөрес кулланууны булдыру.

**Фаразланган нәтиҗә:** Балалар төрле геометрик фигуралардан сүрәт җыя беләләр; алган белемнәрен ирекле эшчәнлектә куллана беләләр.

**Балалар эшчәнлегенең төрләре**: уен, коммуникатив, рәсем ясау, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** турыпочмактан овал, квадраттан түгәрәк кисәргә авырсынган балаларга ярдәм итү; сорауларга җавапны тулы итеп әйтергә өйрәтү; кайчыны дөрес тотуны булдыру.

**Сүзлек эш:** актив: клоун, кызыклы (забавный), шаян (озорной), кызыклы (смешной), Петрушка; пассив: овал, түгәрәк, форма, квадрат, өчпочмак.

**Алдан эшләнелгән эш:** кайчы белән дөрес куллануны искә төшерү; күрсәтмә, иллюстратив, тарату материалларын әзерләү.

**Демонстрацион материаллар һәм җиһазлар:** Шаян һәм моңсу Петрушка сурәте, Петрушка үрнәге, ватманда алдан ясалган чыршы агачы

**Тарату материаллары:** һәрбер балага А5 форматта кәгазь, пумала, җилем, тастымал, клеенка, төрле размердагы эш өчен кисәкләр, үрнәк, һәрбер балага фломастер, пумаланы куярга аслык, кәгазь кисәкчәләренә савыт.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Интернет – ресурсы MAAM.RU

2. Гербова В.В. развитие речи старшая группа М.:МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2014-90 С.

3. Комарова Т.С. изобразительная деятельность в детском саду старшая группа М.:МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2015-107 с.

4. Р. М. Зиннәтова, СУРӘТЛӘҮ ҺӘМ КОРУ ЭШЧӘНЛЕГЕ (зурлар төркеме) Казан, 2014

**Эш барышы:**

**1. Кереш өлеш**

Оештыру моменты

- **Тәрбияче:** Балалар мин хәзер сезгә түгәрәккә басырга тәкъдим итәм. *(балалар түгәрәккә басалар)*, ә хәзер әйдәгез бер-берегезгә карап елмаеп, хәерле көн телик.
- **Балалар:** Хәерле көн.
- **Тәрбияче:** Балалар әйдәгез әле барыбызга да хәерле көн теләп, хәлләр сорашып бер уен уйнап алабыз, ул "Ничек хәлләр" дип атала

**Азхәрәкәтле уен "Ничек хәлләр"**

- Ничек хәлләр?
- Менә шулай!
- Ничек йөзәсең?
- Менә шулай!
- Еракка карыйсың?
- Менә шулай!
- Ничек ашыйсың?
- Менә шулай!
- Саубуллашасың?
- Менә шулай!
- Йоклыйсың?
- Менә шулай!
- Ничек шаярасың?
- Менә шулай!

**2. Төп өлеш.**

- **Тәрбияче:** Балалар, сез әкиятләр яратасызмы? *(Әйе)*
- **Тәрбияче:** Алайса минем янгарак килеп җайлап басыгыз һәм игътибар белән тыңлагыз. Яшәгән ди әкиятләр илендә шаян гына бер кеше, аның исеме Петрушка булган *(Тәрбияче "Петрушка"сурәтен күрсәтә).* Без бу рәсемгә карап, петрушка турында нәрсә әйтә алабыз, ул нинди? *(Балаларның фикерләрен тыңлый)*

- **Тәрбияче:** Әйе, балалар, Петрушка шаян, бәхетле, шат күңелле.

- **Тәрбияче:** Петрушка иртәдән кичкә кадәр фокуслар күрсәткән, йөгергән, сикергән, мәтәлчек аткан. Һәм шулай бер көн шаярган, икенче көн шаярган, ә өченче көнне аңа күңелсез булган, ул урындыкка утырган да елап җибәргән *(Тәрбияче күңелсез "Петрушка" сурәтен күрсәтә).* Балалар бу рәсемдә Петрушка нинди? *(Балаларның фикерләрен тыңлый)*

- **Тәрбияче:** Әйе, балалар, дөрес бу рәсемдә Петрушка күңелсез, сагышлы, моңсу, ялгыз.

- **Тәрбияче:** Балалар нишләргә соң безгә? Ничек Петрушкага ярдәм итеп була икән бәлки әйтерсез сез. *(Балаларның фикерләрен тыңлый)*

- **Тәрбияче:** Петрушкага күңелсез булмасын өчен дуслар ясарга була. Алар бер-берсе белән дуслашырлар дип уйлыйм. Дуслар күп булганда күңелсезләнеп утырырга вакыт та юк булмас. Әйе, дөрес, балалар, мин сезнең белән килешәм, дуслар күп булганда вакыт та тиз үтә, дуслар сезгә авыр булганда ярдәм итәләр, сезгә күңелсез булганда күңелегезне күтәрәләр. Эш алдыннан дөрес кайчы тотарга, җилемне ничек дөрес сыларга икәнен искә төшереп китәбез. *(Балаларның фикерләрен тыңлый)*

- **Тәрбияче:**

- Кайчы белән уйнарга ярамый ул уенчык түгел;
- Кайчы тотып йөгерергә, ыргытырга, йөрергә ярамый;
- Кайчы белән өстәл артында утырып кына эшләргә кирәк;
- Эш беткәннән соң кайчыны үз урынына куярга кирәк;
- Җилемне күп алмыйча гына сылыйбыз;
- Пумаланы тиешле урынга куябыз.

-**Тәрбияче**: Балалар әйдәгез карап китик. Безнең петрушка нинди өлешләрдән тора *(Тәрбияче үрнәк күрсәтә)*

- **Тәрбияче:** Әйе, балалар, дөрес аягы һәм гәүдәсе - овал; аяк, кул чуклары - өчпочмак; башы - түгәрәк; гәүдә төсе - сары, куллары - кызыл, аяклары – зәңгәр; аяк, кул чуклары - яшел, башы - ак, баш киеме – кызыл.

- **Тәрбияче:** Эш башлар алдыннан, бераз кулларны җылытып алыйк.

**Бармак гимнастикасы "Кар әвәләү"** *(Хәрәкәтләрне сүзләр буенча кабатлап барабыз)*

Бер, ике, өч, дүрт, биш, *(Бармакларны саныйбыз)*
Без кар әвәлибез ич. *(Учлар белән әвәлибез)*
Түгәрәк ул, шома ул, *(Бармак белән түгәрәк ясыйбыз)*
Ашарга ярамый шул. *(Янау хәрәкәте)*
"Бер" дигәндә атабыз, *(Ату хәрәкәте ясыйбыз)*
"Ике" дигәч тотабыз, *(Учларны тоташтырабыз)*
"Өч" дигәч төшеп китә, *(Учларны ачабыз)*
Ватыла, эреп бетә. *(Аяклар белән таптыйбыз)*

**Тәрбияче:** Хәзер урыннарыгызга утырыгыз да, эшкә керешик. Эш беткәннән сон чыршы агачына Петрушкаларны тезәбез. *(Балалар петрушка сүрәтен ясыйлар, тәрбияче эш барышының үтәлешен күзәтә)*

**3. Йомгаклау өлеше.**

- **Тәрбияче:** Балалар бүген без сезнең беләнниләр эшләдек? *(Балаларның фикерләрен тыңлый)*

- **Тәрбияче:** Әйе, балалар, без бүген уеннар уйнадык, Петрушкага дуслар ясадык. Менә ничек күңелле хәзер безнең Петрушкага, сезнең ярдәм белән аның бик күп дуслары барлыкка килде, ул беркайчан да күңелсезләнмиячәк инде хәзер, гел шаярып, көлеп кенә йөриячәк, шулай бит балалар. *(Тәрбияче балаларның коллектив эшләренә – чыршыдагы "петрушка"ларга игътибар итә)*

- **Тәрбияче:** Әфәрин, балалар. Саубулашырга вакыт инде хәзер. Сау булыгыз *(Расскраска "Петрушка" таратыла)*

*Оригинальность 95,22 %, https://text.ru/antiplagiat*

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге**

**"Күрше чуаш халкы"**

***Закирова Зөлфия Илфак кызы,***

*МАМББУ "№113 нче "Тиктормаслар" балалар бакчасы тәрбиячеләре, Яр Чаллы шәһәре*

**Яшь үзенчәлеге:** Зурлар төркеме (5-6 яшь)

**Максат:** Төрле милләт кешеләренә хөрмәт тәрбияләү.

**Бурычлар:**

**Үстерешле:** Бәйләнешле сөйләмне, иҗади фикерләүне күнекмәләрен үстерү; социаль күнекмәләрне үстерү; төркемдә эшли белү.

**Тәрбияви:** Чуаш халкы белән дус-тату яшәү теләге уяту; чуаш халкының милли киемнәренә һәм уеннарына соклану хисе тәрбияләү;

**Белем бирү:** Чувашия республикасы, аның башкаласы, символикасы белән таныштыру, чуаш халкының традицияләре һәм милли киемнәре белән таныштыру.

**Фаразланган нәтиҗә:** баларар алган белемнәрен ирекле эшчәнлектә куллана beləләр; чуаш халкының милли киемнәрен аера беләләр; Чувашия республикасының башкаласын, символикасын атый алалар.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** Уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** пассив балаларны әңгәмә барышында активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек эше:** Халык, милли киемнәр, әләм, герб, энә, төен.

**Җиһазлау:** интерактив такта, ноутбук, символикасы (герб һәм әләм),Чабаксар шәһәре турында слайдлар яки картиналар, милли киемле курчак, чуаш халкының гербы белән әләме сүрәте.

чуаш халкының баш киеме ясалган альбом битләре, төсле карандашлар.

**Таратма материал:** Чуаш халкының әләме һәм гербы тасвирланган пазллар.

**Алдан эшләнгән эш:** Чуаш халык бию хәрәкәтләрен өйрәнү, җырларын тыңлау, альбом карау.

**Кулланылган әдәбият:**

**1.** Н.Г. Гарипова, Р.С. Әхмәтова, Ф.М. Хәсәнова “Әйләнә-тирә дөнья белән танышу” мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен методик кулланма, Казан Татарстан китап нәшрияты, 2016.

2. Интернет ресурслар https://www.maam.ru/detskijsad/konspekt-od-po-obrazovatelnoi-oblasti-poznanie-dlja-detei-5-6-let-chuvashija-moi-krai-rodnoi.html

**Эш барышы:**

**1. Кереш өлеше..**

*Барлык балалар да түгәрәккә җыелды.*

**Тәрбияче:**

Мин синең дус, һәм син минем дустым.
Кулга нык тотынабыз,
бер-беребезгә елмаябыз.

*(Балалар тиешле хәрәкәтләр һәм биремнәр башкара.)*

**Тәрбияче:** Рәссәйдә күп халыклар яши. Һәр халыкның үз теле, үз мәдәнияте, үз дине, үз милли традицияләре һәм гореф-гадәтләре бар.

*(Балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар. Чуаш милли киеменнән киенгән курчак күрсәтелә)*

**Тәрбияче:** *(курчакны күрсәтеп)* Балалар, бүген безгә кунак килде. Бу матур кыз Салампи исемле. Ул безгә Чабаксар шәһәреннән килгән.

**Салампи:** Исәнмесез, балалар!

**Тәрбияче:** Әйдәгез, Салампи белән исәнләшик әле: Исәнме Салампи! Ә хәзер чуаш телендә исәнләшик инде. Салампи бит чуаш телендә сөйләшә.

**Тәрбияче, балалар:** Авап, Салампи!

**Салампи:** Авап, ачасем!

*(Тәрбияче курчакның өс-киеменә игътибар итә. Салампины балалар янына утырта)*

**2. Төп өлеш.**

**Тәрбияче:** Балалар сез нинди кеше иллəтләре белән таныш? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Безнең илебез күпмилләтле. Анда татарлар, мордвалар, руслар, марилар, чуашлар һәм башка бик күп халыклар яши. Бүген без чуаш халкы белән танышырбыз. Чуаш халкы, нигездә, Чувашия Республикасында яши. Аның башкаласы – Чабаксар шәһәре. Чуаш халкы – бик тырыш, уңган, кунакчыл халык. Бераз соңрак без сезнең белән Чабаксар шәһәренә сәяхәткә барып кайтырбыз.

*(Тәрбияче балаларга республиканың флагын һәм гербын күрсәтә. Алар турында кыскача мәгълүмат бирә)*

**Тәрбияче:** Балалар, игътибар белән экранга күз салыйк әле. Анда безнең чуаш халкының әләме белән гербы тасвирланган. Аларның әләме сары һәм куе кызыл төстә. Болар – чуаш халкының милли, яраткан төсләре. Сары төс яктылыкны аңлата, куе кызыл төс (пурпур) күренекле, көчле, бөеклекне күрсәтә.

**Дидактик күнегү “Әләм һәм гербны җый”**

**Тәрбияче:** Балалар, сезгә ике командага бүленергә кирәк булыр. Һәр команданың алдында пазллар бар һәм сезгә шуларны җыярга кирәк була. Җыелган пазлдан чуаш халкының гербы белән әләме килеп чыгарга тиеш. *(Экранда чуаш халкының гербы белән әләме күрсәтелә. Тәрбияче балаларның эшләүнең дөреслеген күзәтә. Индивидуаль эш, сүзлек эш башкарыла)*

**Тәрбияче:** Безгә Салампи чуаш халкының милли биюен әзерләп килгән. Әйдәгез әле, балалар, Салампиның биюен карап китик. Ләкин игътибар белән карап утырыгыз, хәрәкәтләрен истә калдырырга тырышыгыз. Яңадан чуаш халкының милли җырлары астында биеп карарбыз.

*(Балалар, тәрбияче артыннан кабатлап, чуаш бию хәрәкәтләре ясыйлар)*

**Тәрбияче:** Балалар, чуаш халык биюе бик матур икән. Ә сезгә аларның киемнәре ошыймы? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Әйдәгез әле, Салампиныың киемнәрен карыйк. Аның киме нинди өлешләрдән тора? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Менә аның күлмәге (рубахасы), ул “кепе” дип атала. Бик матур, шулай бит. Алъяпкычы чуаш халкының милли бизәкләре белән бизәлгән. Ә баш киеме аның “тухья”, “масмак” дип атала. Ул да тәңкәләр һәм кашлар белән бизәлгән. *(Индивидуаль эш, сүзлек эш башкарыла)*

**Тәрбияче:** Балалар, игътибар белән карагыз әле, безгә кунакка килгән Салампиның киемнәре экрандагы чуаш кызының киемнәре белән туры киләме? *(Балаларның җаваплары тыңлана.)*

**Чуаш халкының милли уены: “Энә, җеп, төен”.**

**Тәрбияче:** Салампи безгә үзенең яратып уйный торган уенын өйрәтер, ул “Энә, җеп, төен” дип атала. Безгә өч уенчы кирәк була. Түгәрәк ясап басыйк әле, мин сезгә табышмаклар әйтәм. Дөрес җавап биргән балалар уенчы була.

1. Озынча, түтәлдә үсә, яшел төстә, эчендә бик күп орлыклары бар *(Кыяр)*
2. Җәен соры, кышын ак,
   Аңа шулай яхшырак. *(Куян)*
3. Утыра бер ак чүлмәк,
   Өстенә кигән йөз күлмәк. *(Кәбестә)*
4. Энәсе бар, тегә алмый. (Керпе)
5. Тураганда елата. Нәрсә ул? *(Суган)*
6. Сорыдыр төсе,
   Үткердер теше,
   Урманда йөри,
   Бозаулар эзли. *(Бүре)*

*(Өч уенчы – “энә”, “җеп” һәм “төен” – түгәрәк уртасына басалар. “Энә” түгәрәк буенча әле бер якка, әле икенче якка йөгерә, “җеп” белән “төен” нәкъ шул тәртиптә йөгерәләр. “Җеп” ялгышса яки “төен” “җеп”не тотса, уен яңадан башлана)*

**Тәрбияче:** Балалар, ә хәзер Салампи безне Чабаксар шәһәренә сәяхәткә чакыра. Әйдәгез, әлеге шәһәр белән якыннанрак танышыйк.

*(Чабаксар шәһәре турында слайд яки картиналар карау. Тәрбияче шәһәр турында кыскача мәгълүмат бирә)*

**Тәрбияче:** Бүген Чабаксар шәһәре-Чувашия республикасының башкаласы, ул шулай ук республиканың төп сәнәгать (промышленность) үзәге булып тора.

Чабаксар шәһәре бик күп чиркәүләр белән билгеле. Чабаксар шәһәренең бик зур тарихы бар, ул аның музейларында җыелган. Әлбәттә, әлеге тарихлар сакланган урын – төп музей булып тора. Шулай ук трактор тарихы музее белән дә танылган Чабаксар шәһәре. Ул үз эченә төрле елларда эшләнгән зур тракторлар коллекциясен туплаган.

Чебоксар үз символына ия. Аларга шуларның берсе Монумент – Ана Покровительница. Ул милли киемдәге хатын-кыз образыннан гыйбарәт.

**Тәрбияче:** Менә без бүген күршеләребез чуаш халкы турында бик күп мәгълүмат белдек. Чуаш халкы күңелле, эш сөючән халык икән. Ә хәзер Салампи сезнең белән саубуллашырга тели, әйдәгез, аңа рәхмәт әйтик.

**Тәрбияче:** Рәхмәт сиңа, Салампи! Безгә тагын кунакка кил.

**Салампи:** Сываюлар, ачасем! Сау булыгыз, балалар! *(Курчак китә)*

**3. Йомгаклау.**

**Тәрбияче:** Без сезнең белән нәрсә белдек? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Чувашлар хезмәт сөючән халык, кызыклы тарихлы. Чуашларның үз милли киемнәре бар. Балалар без сезнең белән искиткеч урында яшибез. Без кече Ватаныбызны яратырга һәм сакларга тиеш, башка халык милләтләренә хөрмәт белән какрарга кирәк.

*(Тәрбияче бүгенге шөгыль турында сораулар бирә,соңыннан нәтиҗә ясый, балаларга рәхмәт әйтә)*

*Оригинальность- 92% ссылка* *https://antiplagiatio.ru*

## Оештырылган белем бирү эшчәнлеге
## “Һөнәрләр иленә сәяхәт”

***Муслахова Гульнара Раязовна-1 кв.категория,***
***Фарваева Альбина Михайловна - 1 кв.категория,***
*МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячеләре,*
*Яр Чаллы шәһәре*

**Яшь төркеме:** Уртанчылар төркеме (4-5 яшь).

**Максат:** Балаларның һөнәрләр турындагы белемнәрен ныгыту.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы**:

•Балаларнын акыл, хәтер логик фикер йөртү сәләтен, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү; сүзлек запасын баету һәм активлаштыру.

**Тәрбия бурычы:**

•Балаларда бер-береңә карата дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү, башкаларга ярдәмгә килергә әзер булу, өлкәннәргә карата хөрмәт һәм төрле һөнәр ияләренә уңай караш тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:**

•Балаларның һөнәрләр турында белемнәрен гомумиләштерү, тәрбияченең сорауларына җавап бирә белүен камилләштерү.

**Фаразланган нәтиҗә:** Балалар алган белемнәрен мөстәкыйль уен эшчәнлегендә куллана беләләр; сүз байлыкларын, табиб, пешекче, чәчтарашчы һөнәрләре турында белемнәрен тулыландырдылар. Балалар әлеге һөнәргә ихтирам белән карыйлар.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** оялчан балаларны активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек өстендә эш:**

**Актив сузлек:** табиб, пешекче, пилот-очучы, чәчтарашчы.

**Пассив сузлек:** һөнәр ияләре, эш кораллары.

**Алдан эшләнгән эш:** һөнәрләр турында әңгәмә, шигырьләр уку, һөнәр ияләре турында рәсемнәр карау, дидактик уен: “Һөнәрләр илендә”, “Эш коралы кемнеке?”.

**Демонстрацион материаллар һәм җиһазлар:** һөнәр ияләренең рәсемнәре, табиб киеме, пешекче киеме, дид.уеннар, уенчык “куян”, кызыл һәм зәңгәр кыршау .

**Таратма әсбаплар:** яшелчә һәм җиләк-җимеш медальоннары.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Туганнан алып мәктәпкәчә программасы/ Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясе, -3 нче басма.-М.:Мозайка-Синтез, 2015.

2.Закирова К.В. Балачак аланы. Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия.- Казан.РИЦ нәшрияты, 2011.

3.Закирова К.В. “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе:методик кулланма. – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

**Эш барышы:**

**1.Кереш өлеше.**

**Тәрбияче:** Балалар, бүген бездә кунаклар бар. Алар безнең балалар бакчасында тәрбияче булып эшлиләр. Тәрбиячеләр балаларны тәрбиялиләр. Сез безнең тәрбияче апаларыбызны беләсез, шулай бит. Әйдәгез әле, тәрбияче апалар белән исәнләшеп китик. *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Балалар, ә без хәзерге вакытта кайда, әти-әниләрегез сезне кайда калдырып китте? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Әйе, сез - балалар бакчасында. Әниләрегез, әтиләрегез ни өчен сезне бакчада калдырды, алар үзләре кайда? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Әйе, безнең әниләребез, әтиләребез эшкә киттеләр, аларның һәрберсенең һөнәрләре бар. Бездә бүген сезнең белән һөнәрләр турында сөйләшербез.

**2. Төп өлеш.**

**Тәрбияче:** Балалар, сез әти-әнинең кем булып эшләгәннәрен беләсезме? *(Балалар җавабы. Балалар белән шәхси әңгәмә оештырыла. Балалар әйткән эш һөнәрләренә тәрбияче рәсем күрсәтә, һөнәр белән таныштырып үтә)*

**Тәрбияче:** Сез дә үскәч, үзегезнең яраткан һөнәрләрегезне сайларсыз.

**Тәрбияче:** Балалар, ә сезнең самолетта очасыгыз киләме? Ә самолетны пилот-очучы идарә итә (*Тәрбияче рәсем күрсәтә*). Әйдәгез, бездә очучылар булыйк, самолетларыбызга утырып, һөнәрләр иленә кунакка барып кайтыйк. Сез әзерме? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:**

Кулларны як-якка җәеп,
Алга таба карыйбыз.
Уңга, сулга бөгелеп
Самолетта очабыз.
Бер, ике, өч , дүрт
Алга таба очабыз.

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз! Балалар,без беренче һөнәр иленә килеп җиттек. Ләкин, бу илдә нәрсәдәр булган, эш кораллары буталып, теләсә кайда чәчелгән. Сезнең аларны рәтләп куясыгыз килмиме, атамаларын әйтеп үтсәгез, алар үз урыннарына кайтырлар. *(Эш коралларының атамаларын әйтеп, уенчыкларны урыннарына кую).*

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз! Инде, әйтегез, бу һөнәр илендә кемнәр эшли? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Әйе, бу һөнәр илендә **“**врачлар-табиблар” эшли.

*(Тәрбияче тартмага күз сала. Тартма белән эш)*

**Тәрбияче:** Чү, балалар, бу тартма эчендә ниндидер тавыш ишетелә, ачып карыйбызмы соң? *(Тартмадан елап куян чыга)*

**Тәрбияче:** Куянкай, ни булды, ник елыйсың?

**Куян***:* Исәнмесез, балалар, мин еламас идем дә минем бик нык аякларым авырта, әниемнең сүзләрен тыңламыйча итекләремне салып ыргыттым, ап-ак кар өстеннән ялан аяк йөрдем, итегемне кимәдем.

**Тәрбияче:** И, куянкай, шулай ярыймы, балалар, куян дөрес эшләгәнме? Ни өчен аяклары шешкән? *(Балалар җавабы. Балалрга табиблар булып куянның аягын бинт белән урарга тәкъдим ителә)*

**Физминутка:**

Хәзер бераз ял итик.
Тәнебезгә көч кертик
Биюче кебек йөрик .
Аяк очына басып,
Гәүдәбезне төз тотыйк.
Пешекче апа кебек
Бергәләп камыр басыйк.
Менә шулай, менә шулай.
Тәмле пироглар ясыйк.
Оста гимнастлар кебек
Матур күнегү ясыйк
Бер уңга, бер сулга
Аякларны күтәрик

Житез спортсменнардай
Бергәләшеп йөгерик.

**Тәрбияче:** Булды, инде самолетларыбызга утырып яңадан юлга кузгалыйк.

**Тәрбияче:**
Кулларны як-якка җәеп,
Алга таба карыйбыз.
Уңга, сулга бөгелеп
Самолетта очабыз.
Бер, ике, өч , дүрт
Алга таба очабыз.

**Тәрбияче:** Ооо, бу илдә безне тәмле ризыклар көтә икән. Ә сез бу ризыкларның исемнәрен беләсезме? *(Балалар ризыкларның исемнәрен санап китәләр)*

**Тәрбияче:** Бу тәмле ризыкларны кем пешерә, алар кем дип атала? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Әйе, тәмле ризыкларны повар-пешекчеләр пешерә.

**Тәрбияче:** Алар кайда эшлиләр? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Повар-пешекчеләр кафеда, ашханәдә хезмәт итәләр.

**"Пешекче" уены**

**Тәрбияче:** Хәзер без сезнең белән «Пешекче» уены уйныйбыз. Мин пешекче булам, ә сез үз өстегезгә яшелчә һәм җиләк-җимеш ролен алырсыз. *(Балалар яшелчә һәм җиләк-җимеш медальоннары сайлыйлар).*

Уен кагыйдәсе бик гади: музыка уйнаганда сез төрле юнәлештә йөрисез. Музыка тәмамлангач, барлык яшелчә (суган, кәбестә, бәрәңге, чөгендер) һәм җиләк-җимешләр( чия, карлыган, алма, груша) үзләренең кыршауларына йөгерә: кызыл төстәге кыршауда - борщ, зәңгәр төстәге кыршауда -кайнатма әзерләнә. (*Балалар тиз һәм дөрес үз урыннарын табырга тиеш*).

**Тәрбияче:** Инде юлыбызны дәвам итик .

**Тәрбияче:**
Кулларны як-якка җәеп,
Алга таба карыйбыз.
Уңга, сулга бөгелеп
Самолетта очабыз.
Бер, ике, өч , дүрт
Алга таба очабыз.

**Тәрбияче:** Бу ил балалар "Чәчтараш" дип атала. Чәчтараштта парикмахер - чәчтарашчы эшли. Алар безнең чәчләребезне матур итеп кисәләр, фен белән киптерәләр. Әйтегез әле, чәчтарашчыга нинди эш кораллары кирәк. *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Эйе, чәчтарашчыга эш өчен тарак, фен, кайчы, укладка ясау өчен төрле җайланмалар кирәк.

**3.Йомгаклау өлеше.**

**Тәрбияче** :Әфәрин, балалар, инде хәзер кире бакчабызга кайтыйк.

**Тәрбияче:**

Кулларны як-якка җәеп,

Алга таба карыйбыз.

Уңга, сулга бөгелеп

Самолетта очабыз.

**Тәрбияче:** Әйтегез эле, без кайсы һөнәр ияләрендә кунакта булдык, нәрсәләр өйрәндек? Сезгә аеруча нинди уеннар ошады? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Әйе, без сезнең белән бүген табиб, пешекче, чәчтарашчы һөнәр ияләрендә кунакта булдык. Куянга ярдәм иттек, аның аягын дәваладык. “Пешекче” уены уйнадык. Балалар, сез бик актив булдыгыз, рәхмәт сезгә!

*Оригинальность – 95.92%* , https://text.ru/antiplagiat/unauthorized

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге: “Аю малае һәм явыз болыт”**

***Сагитова Гөлия Рәүф кызы - 1 кв.категория,***

***Салихова Гөлгенә Фәнил кызы,***

*МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячеләре,*

*Яр Чаллы шәһәре Татарстан Республикасы*

**Яшь төркеме:**Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

**Максат:**балаларда дуслык хисләре тәрбияләү.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы:** балаларның игътибарын, кабул итүләрен, күзәтүчәнлекләрен, сөйләмнәрен үстерү;

**Тәрбия бурычы:** дуслыкның кешеләр арасында иң мөһим сыйфат булуына ышаныч формалаштыру; балаларны дус, тату яшәргә өйрәтү; дусларына һәрвакыт булышырга, ярдәмгә килергә кирәклеген төшендерү; балаларның әхлакый сыйфатларын тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:** «Дуслык» темасы буенча балаларның белемнәрен гомумиләштерү; шәхси характеристикаларны белдерә торган сүзләрне сөйләмдә куллануны беркетү.

**Фаразланган нәтиҗә:** балалар дуслык төшенчәсен тулысынча аңладылар; бер-берсенә ярдәмләшеп, дус-тату,ягымлы аралашырга сүз бирделәр.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхсән эш:** пассив балаларны әңгәмә барышында активлаштыру, авырсынган балаларга ярдәм итү; сорауларга җавапны тулы итеп әйтергә өйрәтү.

**Сүзлек өстендә эш: актив сүзләр** кояш, болыт; **пассив сүзләр** дуслык, явыз, ягымлы, ярдәмчел, назлы.

**Алдан эшләнелгән эш:** матур әдәбият уку, дуслык турында мәкальләр белән танышу, шигырьләр ятлау.

**Техник чаралар:** проектор, экран, ноутбук, музыкаль колонка.

**Демонстрацион әсбап:** презентация

**Таратма әсбап:** пиктограмма, өлешләргә бүленгән зур кояш рәсеме (кояш, кояшның нурлары).

**Кулланылган әдәбият:**

1. “Азрак ял итеп алыйк”: Муяссарова И.Х. Физкультминуткалар, сүзле-хәрәкәтле уеннар. – Казан, 2016 ел;

2. Закирова К.В. “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе:методик кулланма/ К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, Г.М.Сафиуллина – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013. – 424 б;

3. Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы «Туганнан алып мәктәпкәчә», Мозаика – Синтез/ Москва, 2015/ХӘТЕР Казан, 2016.

**Эшчәнлек барышы.**

**1. Кереш өлеш**

**Тәрбияче:** Хәерле иртә, балалар! Бер-беребезгә хәерле иртәләр теләп исәнләшеп алыйк әле.

Бергәләп басыйк әле,
Түгәрәк ясыйк әле.
Син - минем дус, мин – синең дус,
Елмаеп алыйк әле.

**Тәрбияче:** Келәмдә уңайлы урыннар алырга тәкъдим итәм. Барыгыз да елмаясыз бүген, кәефегез яхшы икәнен күрәм. Әйдәгез, искә төшерик әле, сездә тагын шундый шатлыклы кәеф кайчан булган иде? Ә киресенчә, начар кәефле чакларыгыз кайчан булды? *(балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Аю малае турында бер әкият тыңлыйсыгыз киләме? Ул соңгы вакытта бик тә ачулы һәм сугыша торган икән.

*(Аю малае турында әкият укыла)*

**Тәрбияче:** Аю малае урманда яши. Ул бик яхшы, искиткеч тәртипле, һәрвакыт ярдәм итүчән, барысы белән дә дус булган.

Менә бер көнне, ул кышын урамда йөрергә булган. Кинәт кенә аның юлына бер зур һәм куркыныч Явыз болыт чыккан, аны бөтереп еракка алып киткән. Ул болыт безнең аю малаен сихерләп усалланырга, сугышырга, кычкырырга өйрәткән. *(Явыз болыт рәсеме экранда күрсәтелә)*

**2. Төп өлеш**

**Тәрбияче:** Менә шундый кыска гына әкият. Балалар, күрсәтегез әле миңа, әкият башында аю малаеның кәефе нинди иде? Ахырда, болыт сихерләгәч, ниндигә әйләнде соң?

*(Пиктограмма белән уен)*

**Тәрбияче:** Балалар, өстәлдә төрле кәефләр белән рәсемнәр таратылган, без хәзер шушы аю малаена туры килә торган рәсемнәрне (*кәефләрне*) күрсәтеп алыйк. (*Балалар җавабы, эшчәнлеге*)

**Тәрбияче:** Әйе, аю малае кәефсез, чөнки син усал рәсемен алдың, тагын елый торган рәсемне сайлап алгансыз.

**Тәрбияче:** Димәк, балалар, без сезнең белән нинди нәтиҗә ясыйбыз? Аю малае дөрес эшләгәнме? (*Балалар җавабы*)

**Тәрбияче:** Телисезме аю малаена янә игелекле булырга ярдәм итәргә? Моның өчен безгә бераз уйнап алырга кирәк

**Бармак уены**

Бер- кулларны алга сузабыз.
Ике- кулларны күтәрәбез.
Өч-кулларны як-якка сузабыз.
Дүрт-кулларны төшерәбез.
Бер, ике, өч-бездә дуслык, бездә көч.

**Тәрбияче:** Балалар, без бу уенны юктан гына ясап үтмәдек. Явыз болытны аю малае яныннан куар өчен, безгә бердәм һәм дус булырга кирәк. Шулай иткән очракта гына, без бергәләп аю малаена элекеге яхшы сыйфатларын кайтара алабыз.

**Тәрбияче:** Аю малае яныннан Явыз болытны куар өчен, бергәләп аяклар ярдәмендә тыпырдап алыйк *(Балалар тыпырдыйлар, экранда ачуы әзрәк кимегән болыт күрсәтелә)*

**Тәрбияче:** Балалар, без тагын ничек бу Явыз болытны куа алабыз икән? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Дөрес, балалар, без болытны өреп куып җибәрә алабыз, җилләтеп алыйк. (*Сулыш гимнастикаы үткәрелә)*

**Тәрбияче:** Афәрин, булдырдыгыз. Карагыз, без бердәм, дус булгач ничек курыкты Явыз болыт! Аннан бары тик үтә күренмәле эзләр генә калды. Ә менә аю малаен янәдән тәртипле, һәрвакыт ярдәм итүчән, барысы белән дә дус итәр өчен безгә әле тырышырга кирәк.

**Туп белән дидактик уен "Капма-каршысын әйт"** *(Мәсәлән, явыз-әйбәт, тырыш-ялкау, матур-ямьсез, саран-юмарт)*

**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле, бу уенны уйнагач безнең аю малае элекеге кебек ягымлы, назлы һәм көләч йөзле булды! *(Экран да аю малае күрсәтелә)*

**Тәрбияче:** Әйдәгез әле, ул гел шундый булып калсын өчен, без аңа "Тылсымлы урындык" уенын уйнап күрсәтик.

**Хәрәкәтле уен "Тылсымлы урындык"**

Бер бала үзәккә "тылсымлы урындыкка" утыра, калганнары аның турында яхшы, ягымлы сүзләр, комплиментлар әйтә. Утыручыны кочакларга була.

**Тәрбияче:** Сезгә ошадымы "Тылсымлы урындык" уенын уйнау? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Явыз болыт безгә килмәсен өчен, бергәләп кояшны ясыйк.

**Дидактик уен "Кояшны өлешләрдән җый"** *(Зур, кисәкләргә бүленгән, кояш рәсеме бирелә. Балалар аны келәмдә җыя. Җыеп бетергәч экранда зур кояш рәсеме күрсәтелә)*

**3. Йомгаклау өлеше**

**Тәрбияче:** Нинди матур, зур, ягымлы кояш чыкты безнең бүлмәдә. Хәзер берниди Явыз болыт та безгә куркыныч түгел! (*Тәрбияче белән балалар кояш тирәли музыка астында әйлән-бәйлән уйнап алалар*)

**Тәрбияче:** Балалар, бүгенге дуслыкка багышланган шөгылебез сезгә ошадымы? Кайсы биремнәр сезгә авыррак тоелды? Ә кайсы җиңел булды? Ә сез аңладыгызмы, явыз болытлар килмәсен өчен безгә нәрсә эшләргә кирәк икәнен? *(Балалар җавабы).*

**Тәрбияче:** Безгә һәрвакыт дус, бердәм, ярдәмчел, назлы булырга кирәк. Без дус булганда гына бернинди кыенлыклар да авыр тоелмас.

**Тәрбияче:** Шуның белән шөгылебез тәмам. Аю малаена күрсәткән ярдәмегез өчен зур рәхмәт.

*Оригинальность – 76.29 % , https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге: "Шаян песи"**

***Сагитова Гөлия Рәуф кызы-1 кв.категория,***
***Салихова Гөлгенә Фәнил кызы,***
*МАМББУ "№113 нче "Тиктормаслар" балалар бакчасы тәрбиячеләре,*
*Яр Чаллы шәһәре Татарстан Республикасы*

**Яшь төркеме:** уртанчылар төркеме (4-5 яшь).

**Максат:** балаларны берничә өлештән торган предметларны әвәләргә өйрәтүне дәвам итү.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы:** балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, күзәтүчәнлекләрен, хәрәкәт координациясен, кул чукларының хәрәкәтчәнлеген һәм сөйләмнәрен үстерү.

**Тәрбия бурычы:** балаларда табигатькә, тереклек ияләренә карата сак караш, шәфкатьлелек, миһербанлык хисләре тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:** балаларны пластилин белән таныштыруны дәвам итү, аның үзлекләрен ачыклау, әвәләү күнекмәләрен ныгыту, уч төбендә түгәрәк әвәләү ысулларын камилләштерү, бер-берсен тоташтыру күнекмәсен ныгыту; таныш булган әвәләү алымнарын файдалану күнекмәләрен ныгыту; тәннең пропорциональ нисбәтен ясарга өйрәтүне дәвам итү; әхлакый күзаллауны ныгыту.

**Фаразланган нәтиҗә:** балалар пластилинны тиешле урында куллана беләләр; формаларын аералар(түгәрәк,овал); хайваннарның тән өлешләрен атый беләләр.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү, рәсем ясау, хәрәкәтләнү.

**Шәхсән эш:** пассив балаларны әңгәмә барышында активлаштыру, авырсынган балаларга ярдәм итү.

**Сүзлек өстендә эш: актив сүзләр** песи, күзләр, колак, мыек, баш, гәүдә, койрык, борын; **пассив сүзләр** овал, төсле йомгаклар, йорт хайваны, карабодай бөртеге.

**Алдан эшләнелгән эш:** йорт хайваннары турында әкиятләр, шигырьләр уку, пластилинның үзлекләрен өйрәнү, песи рәсемнәре карау, дидактик уеннар уйнау: "Кем кайда яши?", "Әнисен тап".

**Җиһазлау:**

**Демонстрацион әсбап:** төрле төсле йомгаклар, музыка.

**Таратма әсбап:** пластилин, әвәләү өчен такта, махсус таякчыклар (стека), песи мыеклары ясарга нечкә чыбыклар ,салфеткалар.

**Техник чаралар:** интерактив такта.

**Кулланылган әдәбият:**

2. Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы «Туганнан алып мәктәпкәчә», Мозаика – Синтез/ Москва, 2015/ХӘТЕР Казан, 2016;

2. Г.Ә.Нәбиуллина, Л.Г.Гыйләҗева, В.М.Камалова “Татар телендә сөйләм үстерү”.

**Эшчәнлек барышы.**

**1. Кереш өлеше**

**Тәрбияче:** Хәерле көн, балалар! Ничек сезнең хәлләрегез, кәефләрегез? *(Балалар җавабы)* Бергәләп, кулга-кул тотынышып, түгәрәп ясап басыйк әле. Барыбызның да кәефләре күтәрелсен өчен бер-беребезне сәламләп үтик. *(Түгәрәк ясап басалар)*

Бергәләшеп без басыйк,
Бик зур түгәрәк ясыйк.
Кояшның җылы нурыннан
Йөрәкләргә көч алыйк.
Татулашыйк, дуслашыйк,
Шөгылебезне башлыйк.

**Тәрбияче:**Балалар, карагыз әле безнең өстәлгә. Нәрсәләр бар монда? *(Өстәлдә төрле төсле йомгаклар ята)*

**Тәрбияче:**Йомгакларның төсләренә һәм формаларына игътибар итегез әле. Алар нинди төстә, нинди формада? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Әйе, безнең өстәлдә түгәрәк формадагы сары, яшел, кызыл йомгаклар бар.

**Тәрбияче:**Сез ничек уйлыйсыз, кайсы йорт хайваны йомгаклар белән уйнарга ярата икән? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:**Матур-матур йомгакларыбыз күп, ә алар белән уйнар өчен песиебез юк бит. Сез ничек уйлыйсыз, без нәрсә эшли алабыз икән? *(Балалар җавабы)*

**2. Төп өлеш**

**Тәрбияче:** Мин сезгә бүген, йомгаклар белән уйнатыр өчен, шаян песиләр әвәләргә тәкъдим итәм. Песиләрне ясый башлаганчы, бармакларыбызны уйнатып алыйк.

**Бармак уены “Песи балалары”** ***(Уен барышы:*** *ике кулның да бармакларын күрсәтәбез, кул бармакларын парлап суккалыйбыз)*

Безнең песи балалары
Унау булган – карагыз!
Ике таза,
Ике өлгер,
Ике шаян,
Ике шук,
Ә икесе бәләкәй,
Тик үзләре бик тәтәй. *(Музыка яңгырый)*

**Тәрбияче:** Әйдәгез, хәзер урыннарыбызга утырыйк *(Балалар өстәл артына утыралар).* Аркаларыбызны төз тотабыз, кузләр миңа карыйлар, колаклар мине игътибар белән тыңлыйлар.

**Тәрбияче:** Хәзер без сезнең белән бергәләп песи ясый башлыйбыз, игътибар белән тыңлыйбыз. *(Һәрбер аңлату хәрәкәтләр белән күрсәтелеп бара)*

**Тәрбияче:** Беренче булып, зур пластилин кисәге алабыз. Кечерәк кисәкне өзеп алабыз - бу безнең песинең башы булыр (*Балалар тәрбияче белән бергәләп башкаралар*).

**Тәрбияче:** Зуррак кисәктән кечерәк кисәкне өзеп алабыз - бу безнең песинең койрыгы булыр. Ә калган пластилин кисәгеннән песинең гәүдәсен ясыйбыз (*Балалар тәрбияче белән бергәләп башкаралар*).

**Тәрбияче:** Пластилин кисәгеннән овал формасы чыгарабыз. Аны аскы ягыннан махсус таякчык (стека) ярдәмендә кисәбез һәм песинең тәпиләрен ясыйбыз (*Балалар тәрбияче белән бергәләп башкаралар*).

**Тәрбияче:** Хәзер калган пластилинның зуррак өлешен алабыз - бу безнең мәчебезнең башы булачак. Уч төбенә куеп, яки өстәл һәм уч төбе ярдәмендә түгәрәкләп тәгәрәтергә була (*Балалар тәрбияче белән бергәләп башкаралар*).

**Тәрбияче:** Килеп чыккан шарның колак өлешен билгелибез һәм ике бармак белән чеметеп песиебезгә колаклар ясыйбыз (*Тәрбияче белән бергәләп*).

**Хәрәкәтле уен**

Песи килгән авылдан,
Ерак диеп тормаган.
Уйный балалар белән,
Колакларын селкетә,
Сикергәләп тә китә,
Сикерәләр балалар,
Аннары кул чабалар.
Уйный балалар белән,
Тәпиләрен күтәрә,
Аннан кире төшерә.
Урында биеп ала.
Койрыгын да боргалый,
Әйләнгәләп тә карый.
Сөенәләр балалар,
Бергәләп кул чабалар.

**Тәрбияче:** Карабодай бөртекләрен алабыз һәм күзләр ясыйбыз, бик кечкенә кара пластилин кисәген алабыз, бармаклар арасында кечкенә тупны әвәлибез - бу мәче борыны булачак (*Балалар тәрбияче белән бергәләп башкаралар*).

**Тәрбияче:** Нечкә чыбык кисәкләрен алып, ике ягына мыеклар ясыйбыз (*Балалар тәрбияче белән бергәләп башкаралар*).

**Тәрбияче:** Башны тәнгә беркетәбез. Безнең кечкенә пластилин кисәге калды, аннан без кечкенә нечкә таякчык әвәлибез - бу мәче койрыгы булыр. Аны тәнгә беркетәбез *(Тәрбияче балаларны пластилин белән эшләүнең дөреслеген күзәтә. Индивидуаль эш һәм форма белән төс турында сүзлек эш башкарыла).*

**Тәрбияче:** Карагыз әле, безнең нинди матур, шаян песиләр килеп чыкты.

**3. Йомгаклау өлеше.**

**Тәрбияче:**

Мияу, мияу, пескәем,
Бигрәк матур төскәең!
Кил әле, кил яныма,
Сөт салам савытыңа.

(*Песиләр күргәзмә почмагына урнаштырыла)*

**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле безнең йомгаклар белән уйнар өчен күпме песи җыелган.

**Тәрбияче:** Песинең кайсы өлешен ясау сезгә авыррак тоелды?

*(Тәрбияче аеруча да матур чыккан эшләрне билгеләп үтә).*

**Тәрбияче:** Без бүген берничә аерым өлешләрдән торган песи сурәтен ясадык. Нинди матур шаян песиләр килеп чыкты безнең! Әфәрин, барыбыз да бик тырышып эшләде. Уңган-булган малайлар һәм кызлар җыелган безгә! Рәхмәт барыгызга да, балалар.

*Оригинальность – 100 %*, https://text.ru/antiplagiat/unauthorized

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге:**

**“Көз”**

***Сагитова Гөлия Рәүф кызы - 1 кв.категория,***
***Салихова Гөлгенә Фәнил кызы,***
*МАМББУ №113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячеләре,*
*Яр Чаллы шәһәре Татарстан Республикасы*

**Яшь төркеме:** уртанчылар төркеме (4-5 яшь).

**Максат:** көз көне табигатьтә булган үзгәрешләр турында белемнәрен арттыру.

**Бурычлар:**

**Белем бирү бурычлары:** көзге табигать турында сөйләргә өйрәтү; кыргый хайваннарның кышка әзерлекләре белән таныштыру; картиналар буенча хикәя

төзергә өйрәтү; “ф” һәм “с” тартык авазларының дөрес әйтелешен ныгыту; исемнәрне кушымчалар ярдәмендә ягымлы итеп әйтергә өйрәтү.

**Үстерү бурычлары:** сәнгатьле сөйләм нигезләрен формалаштыру; бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү; балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, күзәтүчәнлекләрен, сөйләмнәрен үстерү.

**Тәрбия бурычлары:** балаларда табигатькә карата сак караш, шәфкатьлелек хисләре тәрбияләү; сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирүләрен ныгыту.

**Фаразланган нәтиҗә:** балалар көз билгеләрен беләләр, картиналар буенча хикәя тозиләр, “ф” һәм “с” авазларын дөрес әйтәләр, исемнәрне кушымчалар ярдәмендә ягымлы итеп үзгәртә беләләр, табигатьне саклыйлар .

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү, танып белү-тикшеренү.

**Шәхсән эш:** оялчан балаларны активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек өстендә эш:**

**Актив сүзләр:** көз, куян, аю, керпе, төлке, бүре, тиен.

**Пассив сүзләр:** көн кыскара, төн озыная, саргая, коела, кибә, яңгыр, көчле җил, өн.

**Алдан эшләнелгән эш:** көз билгеләре турында әңгәмә алып бару, саф һавада табигать үзгәрешләрен күзәтү, көз турында матур әдәбият уку.

**Җиһазлау:** интерактив такта, магнитофон.

**Демонстрацион әсбап:** куян уенчыгы, көз рәсеме, ак кәгазь бите, соры һәм ак куян рәсемнәре, елаган тавыш, урман шаулаган көй, көз турында картина-схемалар.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Развитие речи в детском саду: уртанчылар төркеме/ Гербова В. В.. — М.: МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2016,- 144с.

2. Занятия по развитию речи для детей 3-5 лет/ О.С.Ушакова М.: ТЦ, «Сфера» 2010.

## Эшчәнлек барышы:

**1. Кереш өлеше**

**Тәрбияче:** Хәерле көн, балалар! Бүген минем кәефем бик яхшы. Минем сезнең белән дә яхшы кәефемне бүлешәсем килә. Әйдәгез, бергәләп түгәрәк ясап җитәкләшик. *(Балалар түгәрәк ясыйлар)* Бер-беребезгә елмаеп, күңелле, уңышлы көннәр теләп, күршеләребез белән кочаклашыйк. *(Балалар кочаклаша)*

**Тәрбияче:** Балалар, минем белән көзге урманга экскурсияга барырга телисезме? *(Балалар җавабы)*

*(Урман шаулаган көй яңгырый. Балалар экран каршына утыралар. Экранда көзге урман рәсеме куела)*

**Тәрбияче:** Балалар, урманга багышлап, бер шигырь бүләк итик әле.

**Хәрәкәтле уен** (*Тәрбияче шигырь укый, шигырь сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр күрсәтә, балалар кабатлый)*

Куе урман шаулап тора,
Агачлары баш ия.
Ботакларын алга сузып
Кунакка ул чакыра.
Исәнме, исәнме, урман,
Әкияти һәм сихри!
Беркемне кыерсытмабыз,
Яратырбыз, уйнарбыз.

**2. Төп өлеш**

*(Елаган тавыш ишетелә)*

**Тәрбияче:** Ишетәсезме? Кемдер елый ахрысы. Карап килим әле *(Куян уенчыгы алып керә)*

**Тәрбияче:** Кем икән бу? *(Балалар җавабы)* Бу бит куян баласы. Ә нишләп елый икән ул? Әйдәгез бергәләп сорыйк әле *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Безнең кечкенә куяныбыз урман аланына уйнарга килгән, тик бер дустын да тапмаган. Урман аланын да танымаган. “Бәлки, мин адашканмындыр. Кайда яшел үлән, кайда яшел яфраклар?” - дип уйлаган.

**Тәрбияче:** Балалар, куянга дусларының кая киткәнен белергә ярдәм итәбезме? *(Балалар җавабы)* Әйдәгез бергәләп аңа нәрсә булганын һәм нигә ул үзенең урман аланын танымаганын сөйләп китик *(Көзге урман рәсеме буенча сөйләү)*

**Тәрбияче:** Көз җитте...

*(Балалар үзләренә таныш булган көз билгеләре турында сөйлиләр. Авырсынган вакытта, тәрбияче сораулар белән ярдәм итә. Тулы җөмләләр белән җавап бирергә кирәклеген искә төшерә)*

**Тәрбияче:** Көз җиткәч агачларның яфраклары саргая һәм коела башлый. Үләннәр, чәчәкләр кибә. Кояшның яктыртуы һәм җылытуы кими.  Көн кыскара, ә төн озыная. Яңгырлар еш ява башлый. Көн салкыная. Көчле җил исә...

**Сулыш алу гимнастикасы  “Җил”** *(2-3 тапкыр кабатлана)*

**Тәрбияче:** Куянга көчле җилнең ничек яфракларны коеп төшерүен күрсәтик әле: ф-ф-ф-ф-ф-ф *(Балалар кабатлый)*

**Тәрбияче:** Ә хәзер салмак, тыныч җилнең коелган яфраклар белән уйнаганын күрсәтик: с-с-с-с-с-с *(Балалар кабатлый)*

**Тәрбияче:** Тагын көчле җил исә. *(Балалар “ф” авазын кабатлый)* Җил тына, салмак кына исә *(Балалар “с” авазын кабатлый)*

**Тәрбияче:** Әфәрин, балалар. *(Куянны күрсәтә)* Карагыз әле куяныбызга, җил тавышын ишеткәч, аңа салкын һәм ямансу булып китте. Ничек ярдәм итик икән аңа? *(Балалар җавабы)* Аны үзебез белән уйнарга чакырыйк.

**“Ягымлы сузләр” уены.**

**Тәрбияче:** Мин сезгә сүзләр әйтәм, ә сез ул сүзләрне ягымлы итеп әйтергә тырышып карагыз. Мәсәлән: кояш – кояшкай. *(Тәкъдим ителгән сүзләр: урман, яфрак, дус, чәчәк, җил, болыт, агач)*

**Тәрбияче:** Нинди ягымлы балалар икәнсез! Һәм тагын бер соңгы сүз: куян. *(Балалар җавабы)* Карагыз әле, “куянкай” дип эндәшкәч куяныбызның

кәефләре күтәрелеп китте бит! Гел шулай бер-беребезгә ягымлы сүзләр белән генә эндәшеп торыйк, балалар, ярыймы? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Безнең куянкаебыз урманда көз җиткәнен аңлады, ә менә үзенең дуслары кая киткәнен һич кенә дә аңлый алмый. Ә сез ничек уйлыйсыз, балалар? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Көз җиткәч, куянның кайбер дуслары, мәсәлән керпе һәм аю, үзләре ясаган җылы өйләрендә йокларга җыеналар. Кем хәтерли, аюның өе ничек атала? *(Балалар җавабы)* Аның өен аю өне дип атыйлар. Җәнлекләр үзләренең өннәрендә кыш буе йоклыйлар, ә яз җиткәч уяналар.

**Тәрбияче:** Калган җәнлекләр дә көз көне кышка әзерләнәләр. Мәсәлән, тиен, салкын кышны үткәреп җибәрер өчен, үзенә азык әзерли. Чыршы күркәләре, чикләвекләр җыеп куя. Бүре һәм төлке юка туннарын калынракка алыштыра. Син дә, куянкай, озакламый үзеңнең җәйге соры туныңны кышкы акка алыштырырсың. Шулай бит, балалар? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Ә кем белә, нигә куянның кышкы туны ак төстә? *(Балалар җавабы)* Әйдәгез әле сезнең җавапларны тикшереп карыйк!

**Тәҗрибә.** *(Балалар өстәл янына җыела. Тәрбияче ак кәгазь битенә соры куян рәсеме куя)*

**Тәрбияче:** Ак карда хәйләкәр төлке тиз таба алыр микән куянны? Ә усал бүре? *(Балалар җавабы)* Әйе, соры тун белән куян ак карда бик яхшы күренә. *(Тәрбияче соры куянны ак куянга алыштыра)* Әгәр куян тунын акка алыштырса, ул карда яхшы күренәме икән? *(Балалар җавабы)*Дөрес, тунын акка алыштырган вакытта куянны эзләп табарга бик авыр.

**Тәрбияче:** Балалар, безнең кечкенә куян боларның берсен дә белмәгән икән ич! Ул безгә яхшы киңәшләребез өчен рәхмәт әйтә. Аның белгәннәре турында тизрәк әнисенә кайтып сөйлисе килә. *(Куянга эндәшә)* Куянкай, син ашыкма! Өеңә кайтып җиткәнче барсын да онытмас өчен, балалар сиңа тагын бер кат табигатьтәге үзгәрешләр турында сөйләп күрсәтерләр.

**Тәрбияче:** Балалар, бу рәсемнәргә карап куянга тагын бер кат аңлатып китик әле көзнең нинди булганын. *(Картина-схемалар буенча табигатьтәге көз үзгәрешләре турында сөйләү)*

**Тәрбияче:** Көз көне салкын була, агачларның яфраклары саргая, кошлар җылы якка китә, салкын җил исә, яңгырлар ява, кешеләр калынрак киенеп йөри башлый.

**3. Йомгаклау өлеше**

**Тәрбияче:** Куянкай, барсын да исеңдә калдырдыңмы инде? Хәзер синең белән саубуллашсак та була. Сау бул, куян! *(Балалар саубуллашалар)* Ә безгә кире бакчабызга кайтырга вакыт. *(Урман шаулаган көйгә балалар тәрбияче белән келәмгә барып утыралар)*

**Тәрбияче:** Без бүген кайда булдык сезнең белән? Кемне очраттык? Ә кем нинди яңалык белде бүген үзе өчен? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Без көзге урманга экскурсияга бардык, анда югалган куянны очраттык. Көз көне табигатьтә нинди үзгәрешләр булуын искә төшердек. Нинди киңәшләр бирдек куянга? *(Балалар җавабы)* Кыш көне куянга erтkыч

җәнлекләрдән качарга җиңелрәк булсын өчен, тунын акка алыштырырга киңәш иттек.

*Оригинальность – 94.81%*, *https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге:**
**“Куян белән керпе бездә кунакта”**

***Салихова Гөлгенә Фәнил кызы,***
***Сагитова Гөлия Рәүф кызы - 1 кв.категория,***
*МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячеләре,*
*Яр Чаллы шәһәре Татарстан Республикасы*

**Яшь төркеме:** уртанчылар төркеме (4-5 яшь).

**Максат:** уен барышында элементар математик күзаллауларын киңәйтү.

**Бурычлар:**

**Белем бирү бурычлар:** “озын”, “кыска” төшенчәләре белән танышу; “ничә?” “ничәнче?” дигән сорауларга дөрес җавап бирүләренә ирешү; 5 кә кадәр санауны дәвам итү; төсләрне ныгыту.

**Үстерү бурычлары:** балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, күзәтүчәнлекләрен, сөйләмнәрен, күзаллауны үстерү.

**Тәрбия бурычлары:** балаларда тереклек ияләренә карата сак караш, шәфкатьлелек, миһербанлык хисләре тәрбияләү, бер-береңне бүлдермичә тыңларга өйрәнүне дәвам итү; төркемдә, коллективта аралашу осталыкларын тәрбияләү.

**Фаразланган нәтиҗә:** балалар предметларның сыйфатын «озын-кыска» сүзләре белән дөрес итеп билгели алалар; “ничә?” “ничәнче?” дигән сорауларга дөрес җавап бирәләр.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхсән эш:** оялчан балаларны активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек өстендә эш:**

**Актив сүзләр**: куян, керпе; кишер, гөмбә, алма, кишер,кәбестә,кыяр.

**Пассив сүзләр:** озын, кыска, беренче, икенче, өченче, дүртенче, бишенче.

**Алдан эшләнелгән эш:** 5 кә кадәр санау, йорт һәм кыргый хайваннар турында матур әдәбият уку, хәрәкәтле уен сүзләрен ятлау.

**Җиһазлау:**

**Демонстрацион әсбап:** тартма, куян һәм керпе уенчыклары; электрон тактада яки чыгартылган вариантта янәшә 2 кыз рәсеме (озын, кыска чәчле кызлар, озын һәм кыска күлмәкле кызлар - күлмәкләре төрле төстә); берничә кишер, гөмбә, алма, кәбестә,кыяр рәсемнәре.

**Таратма әсбап:** буягычлар.

**Методик алымнар һәм чаралар:** сөенеч мизгеле, сорауларга җавап, әңгәмә, хәрәкәтле уен, дидактик уен, мактау.

**Техник чаралар:** интерактив такта.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы «Туганнан алып мәктәпкәчә», Мозаика – Синтез/ Москва, 2015/ХӘТЕР Казан, 2016;

2. Помораева И.А., Позина В.А. “Формирование элементарных математических представлений” уртанчылар төркеме- МОЗАИКА –СИНТЕЗ, 2016,-

**Эшчәнлек барышы.**

1**. Кереш өлеше**

**Тәрбияче :** Балалар, матур итеп басып, бер-беребезне сәламләп үтик әле.

Хәерле иртә сиңа!

Хәерле иртә миңа!

Хәерле иртә сезгә!

Хәерле иртә һәммәбезгә дә!

**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле, бүген мин төркемнең ишек төбендә кемне очраттым? Таныдыгызмы бу хайваннарны? Әйдәгез алар белән исәнләшик *(балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Әйе, бик дөрес бу керпе һәм куян. Куян белән керпе – йорт хайванымы, әллә кыргый хайваннармы? Безнең аларга мөнәсәбәтебез нинди булырга тиеш? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Дөрес әйтәсез, аларны кыерсытырга, рәнҗетергә ярамый. Без аларга һәрвакыт ярдәм итәргә тиеш. Ә ничек ярдәм итә алабыз соң? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче:** Куян белән керпе буш кул белән килмәгәннәр, алар безгә ниндидер сюрприз әзерләгәннәр *(тартма күрсәтә)*, тик болай гына, җиңел генә бирәселәре килми. Моның өчен безгә алар алып килгән биремнәрне үтәргә кирәк. Сез әзерме биремнәрне үтәргә? *(Балалар җавабы)*

Тартманы ачып, биремнәрне алганчы, аларның сөйләшүләрен тыңлап китик әле.

Керпе әйтә куянга:

-И, куян! Нинди озы-ы-ы-н синең колакларын! Аякларың да озын, ә койрыгың кыска.

Куян аңа әйтә:

- Ә синең, керпе, кыска колакларың, кыска аякларың, ә борын өлешең озын. Монда бер кызык та юк. Бар әйбер дә җир йөзендә озын да, кыска да була ала.

Ә сез, балалар, куянның җавабы белән килешәсезме? *(Балалар җавабы)*

2. **Төп өлеш**

**Тәрбияче :** Хәзер, тартманы ачып, биремнәргә күчсәк тә була *(“Озын”, “кыска” төшенчәләрен ныгыту. Электрон тактада яки чыгартылган вариантта янәшә 2 кыз рәсеме күрсәтелә (озын, кыска чәчле кызлар, күлмәкләре төрле төстә).*

Әлеге рәсемнәрдә кыска чәчле кызның күлмәге нинди төстә?

Ә озын чәчле кызның күлмәге нинди төстә?

Кыска күлмәкле кызның күлмәге нинди төстә?

Озын күлмәкле кызның күлмәге нинди төстә? (*Балалар җавабы. Тулы җөмләләр белән җавап бирергә кирәк икәнен искә төшерү)*

**Тәрбияче:** Балалар, бик дөрес рәсемнәрдә кызларның күлмәкләре төрле төстә.

**Тәрбияче:** Озын һәм кыска төшенчәләренең нинди икәнен белдек, тартманы ачып, икенче биремне карыйбызмы? *(Балалар җавабы)*

**Тәрбияче :** Икенче биремдә керпе белән куян безгә "Киресен әйт" уенын уйнап алырга тәкъдим итәләр. Мин сезгә сүзтезмәләр укыйм, ә сез аның киресен әйтергә тиеш. Мәсәлән: мин әйтәм "озын чәч", ә сез миңа "кыска чәч" дип җавап бирергә тиеш буласыз *(юл, елан, әкият, койма, җыр, бау, коридор).*

**Тәрбияче:** Балалар, без ничәгә кадәр саный беләбез әле ул? Әйдәгез, бергәләп саннарны 5 кә кадәр алдан артка һәм кирегә таба санап алыйк *(Балалар алдан артка һәм кирегә саныйлар)*

**Хәрәкәтле уен.**

Куян килгән урманнан,
Ерак диеп тормаган.
Уйный балалар белән,
Колакларын селкетә,
Сикергәләп тә китә,
Койрыгын да боргалый,
Әйләнгәләп тә карый.
Сөенәләр балалар,
Бергәләп кул чабалар.
Керпе килгән урманнан,
Ерак диеп тормаган.
Уйный балалар белән,
Тәпиләрен күтәрә,
Аннан кире төшерә.
Урында биеп ала,
Ә балалар кул чаба.

*(Балалар утырышалар, тәрбияче тартманы ачуны дәвам итә, берничә кишер, гөмбә, алма, кәбестә,кыяр рәсемнәре магнит тактага элена)*

**Тәрбияче:** Керпе белән куян безгә күчтәнәчләр алып килгәннәр. Карагыз әле, нәрсәләр бар монда? *(Балалар җавабы)* Ничә кишер, ничә гөмбә һ.б бар монда? *(Балалар саныйлар. Тулы җөмләләр белән җавап бирергә кирәк икәнен искә төшерү)*

*(Берешәр кишер, гөмбә, алма, кәбестә,кыяр рәсемнәре бер рәткә элена)*

**Тәрбияче:** Гөмбә безнең ничәнче? Алма ничәнче? Һ.б. *("Ничәнче" сорованы җаваплар)*

**Дидактик уен "Нәрсә юк"**

*(Тәрбияче күчтәнәчләрдән берәр рәсемне алып куя. Балалар җитмәгән предметны атарга тиешләр. Уен яңадан кабатлана)*

**3. Йомгаклау өлеше.**

**Тәрбияче:** Тартмада биремнәр бетеп тә киткән *(Буш савыт күрсәтелә)*. Ничек тиз үтәдек без аларны! Биремнәрне тиз һәм төгәл үтәгән өчен куян белән керпе безгә менә шушындый урман күренешләре ясалган матур буягычлар алып килгәннәр.

**Тәрбияче :** Балалар, бүгенге шөгылебез сезгә ошадымы? Кайсы биремнәр сезгә күбрәк ошады? Кайсылары авыррак тоелды? (*Балалар җавабы*)

**Тәрбияче :** Шуның белән безнең шөгылебез тәмам. Актив катнашканыгыз өчен рәхмәт. Сау булыгыз.

*Оригинальность – 92,58 % , https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

## *Музыкаль чара* “Робот “Сеня” һәм убырлы карчык”

***Самигуллина Фирюза Фирдависовна- югары кв.категория, МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы музыка җитәкчесе, Яр Чаллы шәһәре***

**Яшь төркеме:** Зурлар төркеме (5-6 яшь).

**Максат:** Балалар өчен күңелле, бәйрәм атмосферасы тудыру.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы**:

•Җырны һәм көйне башкарганда музыкаль һәм иҗади сәләтне үстерү; эмоциональ ярдәмчеллекне үстерү; иҗади, музыкаль, коммуникативлыкны үстерү; балаларның уен сәләтен үстерү; сүзлек запасын баету һәм активлаштыру.

**Тәрбия бурычы:**

•Балаларның музыкаль кичерешләрен баету, ата – аналарны педагогик процеска җәләп итү; бер-берсе, өлкәннәр, персонажлар белән аралаша белүне тәрбияләү; балаларга шатлык хисләренең ирекле эмоциональ чагылышына ярдәм итү; кызларга карата ихтирамлы мөнәсәбәт, әнигә мәхәббәт тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:**

•Балаларга 8 март бәйрәме турында гомүми мәгълүмәт бирү; балаларны игътибар белән тыңларга һәм күзәтергә өйрәтү; таныш музыкаль материалны, балаларның җыр, бию һәм уен күнекмәләрен бәйрәм шартларында ныгыту.

**Фаразланган нәтиҗә:** Балалар 8 март бәйрәме турында белемнәрен баеттылар.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** Уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү, музыкаль, сәнгать әдәбиятын һәм фольклорын кабул итү.

**Шәхси эш:** Оялчан балаларны активлаштыру, җырлаганда хаталарны төзәтү, сорауларга җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек өстендә эш:**

**Актив сузлек:** Исәнмесез, 8 март, рәхмәт, саубулыгыз.

**Пассив сүзлек:** Робот, убырлы карчык, хатын-кыз.

**Алдан эшләнгән эш:** Кынгырауларда уйнау, биюләр өйрәнү, шигырьләр, җыралар ятлау; музыкаль репертуар сайлау; кирәкле атрибутларны туплау; залны бизәү.

**Ата-аналар белән эш:** Шигырьләр өйрәнү, костмюмнары әзерләү, бию ятлау, ата-аналар белән шәхси эш.

**Демонстрацион материаллар һәм җиһазлар:** Убырлы карчык өйе, чәчәк;

**Таратма әсбаплар:** Кынгыраулар.

**Катнашалар:** Алып баручы, Робот "Сеня", убырлы карчык.

**Кулланылган әдәбият:**

1."Җырлыйк, уйныйе, нәниләр!" (сборние песен, игр для детей от 2 до 9 лет) Сабирова С.М. – Чаллы шәһәре, 1994.

2. "Ясыйк матур түгәрәк" – методик кулланма "Балалар бакчасында музыка" сериясе, өченче китап – Казан "Халкыбыз мирасы" нәшрияты

3. "Ритмик мозаика" – А.И. Буренина, Санкт – Петербург, 2000

**Эш барышы:**

***Балалар музыка астында залга керәләр.***

**Алып баручы.** Бүген күңелле, шатлыклы язгы бәйрәм. Безнең матур залга килгән кунакларны күрергә без бик шат! Бу язгы бәйрәмдә барлык хатын – кызларга чәчәк бүләк итәләр. Ә безнең чәчәкләр – ул балалар! Карагыз әле, алар нинди матурлар!

**1 бала.** Бәйрәм бүген. Бәйрәм бүген!
Балалар бакчасында.
Әниләрне, әбиләрне,
Бакчадагы апаларны
Чакырдык барчасын да.

**2 бала.**"Әни" сүзе иң бөек сүз,
Юк аңа һичбер алмаш.
Иң-иң әйбәт кешеләр дә
Әни кебек булаламас.

**3 бала.** Иң кадерле, иң хөрмәтле
Булсын җирдә әниләр.
Әниләрне кадерләсәк,
Тыныч булыр ил-көннәр.

**4 бала.** Сез бәйрәмнең иң түрендә
Сөекле хатын-кызлар.
Бары тик сезнең хөрмәткә
Бүген безнең чыгышлар.

***Җыр "Әниләр бәйрәме", Г. Гәрәева***

**Алып баручы.** Балалар, әниләрегез моңсуланып утыра кебек. Аларның кәефен ничек күтәрик микән? Бәлки аларга ярдәм кирәктер? Эй, әниләрнең ярдәмчеләре, чыгыгыз, сөйләгез безгә, ниләр эшли беләсез?

***Шигырьләр «Мамины помощники» (малайлар чыга)***

**1 малай.** Дома очень много дел.
Маме я помочь хотел,
Вымыл пол окрошкой,
И подмел немножко.

Спрятал под диван игрушки,
Вынул перья из подушки,
**2 малай.**_ Куклу кашей накормил,
Молоком цветы полил,
Постирал носки в кефире,
И развесил по квартире
**3 малай.**Я заштопал скотчем платье,
Пыль я выбил из кровати,
Разложил в тарелках мед…
Пусть мамуля отдохнет!
**4 малай.**_Мама ставила пирог.
Я, конечно, ей помог!
В тесто бросил горсть корицы,
Вылил баночку горчицы,
Я пирог испек на славу!...
А вот есть его не мог.

**Алып баручы.** Менә шундый ярдәмчеләр үсә безнең балалар бакчасында. Балалар , бүген үзенчәлекле көн? (*Балалар җавабы)*

**Алып баручы.** Бик дөрес! Бер кагыйдә бар: Әгәр музыка яңгыраса, өйгә әкият килә. Сез безнең бәйрәмгә берәр әкият килүен телисезме? ***(**Балалар җавабы)*

**Алып баручы**. Сез берни дә ишетмисезмени? Тыңлагыз әле... *(Ишек артыннаң кемдер кычкыра, елый)*

**Убырлы.** Ай-яй ватылды, ватылды кадерлекәем. Нишләргә инде миңа картлачка? (*Музыка янгырый, залга Убырлы карчык керә)*

**Алып баручы.** Балалар, ничек уйлысыз, бу кем? (*Балалар җавабы)*

**Убырлы.** Исәнмесез, балалар, малайлар, кызлар! Исәнмесез, кунаклар. Нәрсә эшлисез монда? *(Балалар җавабы)*

**Алып баручы.** Убырлы карчык, безнң бүген бәйрәм бит. Хатын-кызлар бәйрәме – 8 март!

**Убырлы.** Ярар, әйдә бәйрәм итегез, күңел ачыгыз, минем вакытым юк. Балалар, сез белмисезме, якын тирәдә көнкүреш техникасы сата торган кибет бар микән? *(Балалар җавабы)*

**Убырлы.** Бик борчылдым әле, кайгым зур. Миңа Шүрәле менә шундый *(Күрсәтә)* робот бүләк иткән иде 8 март белән котлап. Үзе акыллы, әйбәт, миңа йорт эшләрендә ярдәм итәргә дип - идән, кер, савыт- саба юарга, мине сакларга. Ничек кулланырга кирәклеген өйрәткән язуы да бар иде, мин бит укый белмим, берәр җиренә дөрес басмаганмындыр инде. Ватылды роботым…ватылды бит.

**Убырлы.** Балалар, нишлийбез? Убырлы карчыкка ярдәм итәбезме? *(Балалар җавабы).* Син, убырлы карчык, кайгырма. Роботны балаларга күрсәт, кирәкле кәгазьләрен дә бир.

**Убырлы.** Әлбәттә, күрсәтәм. Зинһар ярдәм генә итегез, кайда соң әле ул? (*Кесәдән эзләп, пульт чыгара*). Сеня, кадерлем, кил минем янга! (*Пульт кнопкасын баса, музыка яңгырый, робот керә*)

**Алып баручы.** Балалар , бу уенчык робот түгелме соң? *(Балалар җавабы)*

**Убырлы.** Юк, уенчык түгел. Әйдә әле, Сеня, урманга артың белән, миңа алдың белән борыл (*Робот борыла*). Ә, хәзер урманга алдың белән, балаларга йөзең белән борыл .(*Робот әйләнә*). Ә, хәзер чүгәлә!

**Робот:** Ууу (*Утырмый*)

**Убырлы**. Нигә чүгәләмисең?!

**Робот.** Аптыраттың инде! (*Җәфалады)*

**Убырлы.** Менә, күрәсезме?

**Алып баручы.** Убырлы, безгә инструкция кәгазен бир әле.

**Убырлы.** Ярар, кайда әле ул минем? *(Эзли дә, алып баручыга бирә)*

**Алып баручы.** (*Балалар белән бергә укый)* Робот “Сеня” - уникаль, универсал йортта ярдәмче. Ул идән юа, кер юа, савыт – саба юа, хәтта ашарга да пешерә ала.

**Убырлы.** Менә, менә, ә кайда ул вәгъдә? *(Алып баручы укуны дәвәм итә)*

**Алып баручы.** Үзеңә йомшак, назлы итеп дәшкәнне таләп итә, ачу белән дәшсән тыңламаска мөмкин.

**Убырлы.** Ой!!!

**Алып баручы.**Убырлы карчык, нишләттен син аны?

**Убырлы.** Соң, нишләттең дип? Мин аңа: әй, консерва банкасы, миңа су китер! Ә ул каткан кадак кебек басып тора, күзләрен челт – челт йомып. Мин тагын дәшәм, нәрсә, ишитмисең мени?

**Робот.** Әйе, башка себеркесе белән бәрде.

**Убырлы**. Ул бит...тимердән, ни булсын аңа дип уйлаган идем. Ә, ул тотынды чабарга, миннәң качып китте. Көч-хәл белән тоттым.

**Алып баручы.** Балалар, беркем белән дә алай сөйләшергә ярамый бит? *(Балалар Убырлыга матур, йомшак итеп сөйләшергә кирәклеген аңлаталар)*

**Убырлы**. Сез миңе гафу итегез инде, балалар, син дә, Сеня, гафу ит. Телисеңме мин сиңа яңа батареялар алам? (*Роботны сыйпап*). Гафу итәсеңме?

**Робот.** Гафу итәм. Ләкин син минем хәтеремне бетердең. Мин нишләргә кирәклеген белмим инде хәзер.

**Убырлы.** Ой, ой. Балалар өйрәтегез зинһар роботны. Бәлки, аны көчле һәм батыр булырга өйрәтә алырсыз. *(Балалар җавабы)*

**Алып баручы.** Әлбәттә, өйрәтәбез. Безнең малайлар барысы да бик батыр. Алар хәрби уеннар уйныйлар.

***Уен “ Без-Солдатлар”, И. Холодная***

**Робот**. Мин аңладым нинди булырга кирәклеген. Рәхмәт! Мин барсын да истә калдырдым.

**Убырлы.** Бу бик җиңел йөкләмә. Ә, кем миңа кер юып күрсәтә? Кемнәрнең кызлары өлгер икән...яулыкларны бауга эләргә?

***Уен “Кер элү”***

**Убырлы**. Афәрин, бик өлгер икәнсез. Ә, минем Робот сездән дә өлгер.

**Алып баручы.** Балалар, без бит бәйрәм турында онытып җибәргәнбез! Әйдәгез әле әниләр, әбиләр өчен дәртле, күңелле бию биеп алыйк.

***Полька - Болгарская, плясовая мелодия “Кремена”***

*(Убырлы елый башлый)*

**Алып баручы.** Убырлы карчык, сиңа ни булды, ник елыйсың? Без шундый дәртле бию биеп алдык, сиңа ошамады әллә?

**Убырлы**. Бәйрәм белән кызларны да, әниләр белән әбиләрне дә котладылар, ә мине, убырлыкайны Шүрәледән башка искә алучы да юк...

**Робот**. Мин сине котлыйм *(Чәчәк бүләк итә)*

**Алып баручы.** Безнең балалар да сиңа бүләк әзерләделәр.

***Җыр "Чибиләр", А. Евдотьева***

**Алып баручы.** Балалар, табышмак тыңлагыз һәм җавап табыгыз.

Тәгә, чигә, пешерә,
Көен – көйләп йоклата
Ул була безнең *(Әби)*

**Алып баручы.** Котлыйбыз әбиләрне җыр һәм шигырләр белән.

**1 бала.** Ближе бабушки чудесной
Нет подружки у меня.
Мне с бабулей интересно,
Не прожить нам врозь ни дня!

**2 бала.** Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә,
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул!

***Җыр "Кунак әби", Г.Гараева***

**Убырлы.** Рәхмәт, сезгә, барыгызга да. Балалар, сез роботны кер юарга, өй җыештырырга, мине сакларга гына өйрәтмәдегез. Әдәпле, игелекле, ярдәмчел булырга да өйрәттегез! Ах, нишләттегез сез мине? Миңа күрсәткән ярдәмегез өчен сезгә биисем килеп китте. Ә, сез миңа ярдәм итегез.

***Убырлы белән бию,***

***Песня - Бабка ёжка выгляни в окошко, Т. Морозова***

**Убырлы.** Сезне шаккатырырга вакыт житте, балалар. Бер, ике, өч, тавык аяклы өем, безнең янга чык! *(Балалар кабатлый. Тавык аяклы өй керә)*

**Убырлы**. Менә, минем кадерлем, шәп итеп йөгерә ул. Борыл урманга артың белән, балаларга алдың белән. Сез, балалар, матур сүзләр беләсезме *(Балалар матур, игелекле, юмарт сүзләр әйтәлер)*

**Убырлы.** Менә бит, булдырдыгыз, балалар. Балаларга бүләкләр бир!

**Алып баручы.** Зур рәхмәт, убырлы карчык!

**Убырлы**. Сезнең белән бик күңелле булса да, миңа урманга очарга вакыт, бәлки миңа шүрәле кунакка килеп китәр.

**Алып баручы.** Бүгенге әниләребезгә, әбиләребезгә, барлык хатын-кызларыбызга багышланган бәйрәм кичәбез үтеп тә китте! Барыгызга да исәнлек һәм иминлек теләп, сезнең белән саубуллашабыз һәм үзебезнең матур җырыбызны бүләк итәбез!

***Уртак бию уздырыла.***

*Оригинальность – **88,63 %** , https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

# Музыкаль чара «Чыршы янында»

***Самигуллина Фирюза Фирдависовна – югары кв.категория,***
*МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы музыка җитәкчесе, Яр Чаллы шәһәре*

**Яшь төркеме:** Икенче кечкенәләр төркеме (3-4 яшь).

**Максат**: Балаларны әкияти театральләштерелгән тамашага кертү юлы белән Яңа ел бәйрәменең тылсымлы атмосферасын булдыру.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы**:

•Хәрәкәт тәҗрибәсе үстерү, сүзлек запасын баету һәм активлаштыру; балаларның актерлык сәләтен үстерү,

**Тәрбия бурычы:**

•Балаларда бер-берeңә карата дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү, балаларны таныш геройлар белән очрашудан алган хис- тойгылары белән баету, ата–аналарны педагогик процеска җәләп итү; балаларга шатлык хисләренең ирекле эмоциональ чагылышына ярдәм итү.

**Белем бирү бурычы:**

•Балаларга Яңа ел бәйрәме турында гомүми мәгълүмәт бирү; балаларны игътибар белән тыңларга һәм күзәтергә өйрәтү; таныш музыкаль материалны, балаларның җыр, бию һәм уен күнекмәләрен кышкы әкият шартларында ныгыту.

**Фаразланган нәтиҗә:** балалар Яңа ел бәйрәме турында белемнәрен баеттылар.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү, музыкаль, сәнгать әдәбиятын һәм фольклорын кабул итү.

**Шәхси эш:** оялчан балаларны активлаштыру, җырлаганда хаталарны төзәтү, сорауларга җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек өстендә эш:**

**Актив сузлек:** исәнмесез, яңа ел, рәхмәт, саубулыгыз.

**Пассив сүзлек:** кыш бабай, кар кызы, кар бабай, чыршы.

**Алдан эшләнгән эш:** яңы ел турында рәсемнәр карау; шигырьләр, җыралар ятлау; шалтыравыклар белән уйнау, кар бөртекләре белән бию өйрәнү; музыкаль репертуар сайлау; фонарьлар ясау; кирәкле атрибутларны туплау.

**Ата-аналар белән эш:** шигырьләр өйрәнү, яңа ел костмюмнары әзерләү, бию ятлау, ата-аналар белән шәхси эш.

**Демонстрацион материаллар һәм җиһазлар:** бизәлгән чана, 4 бизәлгән тартма.

**Таратма әсбаплар:** шалтыравыклар, кар бөртекләре, кәгазьдән ясалган фонарьлар.

**Катнашучылар:** Алып баручы, Кыш бабай, Кар кызы, Кар бабай.

**Кулланылган әдәбият:**

1.”Җырлыйк, уйныйе, нәниләр!” (сборние песен, игр для детей от 2 до 9 лет) Сабирова С.М. – Чаллы шәһәре, 1994.

2. “Ясыйк матур түгәрәк” – методик кулланма “Балалар бакчасында музыка” сериясе, өченче китап – Казан “Халкыбыз мирасы” нәшрияты

3. “Ритмик мозаика” – А.И. Буренина, Санкт – Петербург, 2000

**Эш барышы:**

*Балалар музыка астында залга керәләр. Чыршы янында калалар.*

**Алып баручы.** Балалар, безгә кыш матур бәйрәм алып килде. Залыбызның уртасында чыршы агачы тора. Карагыз әле, аны төрле уенчыклар, шарлар белән бизәгәннәр. Чыршы матурмы, озынмы? Сезгә ошыймы? *(Балалар җавабы. Балалар чыршыны карыйлар)*

**1.Бала.** Мин беренче тапкыр күрәм,
Шундый матур чыршыны.
Уенчыклар, төрле шарлар
Бизәп торалар аны.

**2.Бала.** Әтидән дә биек,
Әнидән дә биек.
Ай-яй-яй бигрәк озын
Тора түшәмгә тиеп.

**3. Бала.** Без чыршыны мактыйбыз.
Мактый-мактый җырлыйбыз.

***Кыш бабай җыры, С.Сабирова***

**Алып баручы.** Балалар, чыршыдагы утлар яңарга тиеш, мөгаен. Ул вакытта безнең чыршы тагын да матуррак булыр иде. Әйдәгез чыршыга өреп карыйбыз. *( Балалар өрәләр,чыршыдагы утлар кабынмый)*

**Алып баручы.** Кул чабып карыйк, тыпырдыйбыз...һаман да янмыйлар. Белдем, белдем, аңа тылсымлы сүзләр әйтергә кирәк. Тылсымлы сүзләрне мин үзем әйтәм, ә сез, бер ике, өч диярсез.

**Алып баручы.** Чыршы, чыршы, кабын син, утларыңны балкыт син! Бергә кабатлыйбыз : бер, ике, өч!!! *(Балалар кабатлый. Чыршыдагы утлар кабына)*

**Алып баручы.** Афәрин, балалар! Урындыкларга утырыгыз, кунакларны каршы алабыз!

**Алып баручы.** Ишетәсезме балалар, матур җыр ишетелә, безгә кунак килә. *(Җыр җырлап, кар кызы керә*)

**Кар кызы.** Исәнмесез, балалар! Мин - кар кызы, сезне Яңа ел бәйрәме белән котлыйм. Мин килдем сезгә бәйрәмгә, бергәләшеп җырларга, шатланышырга, уйнарга , биергә!

***Бию “Разноцветная игра”, Б. Савельева***

**Алып баручы.** Кар кызы, син безгә үзең генә килдеңме?

**Кар кызы.** Кыш бабай юлда тоткарланды. Мин сезгә аның тылсымлы чанасын алып килдем, әйдәгез, карыйк әле, Кыш бабай нинди бүләклер әзерләген икән?

**Кар кызы.**
Беренче тартманы ачабыз
Ниләр бар икән анда? (*ача*)
Тартмада- кар бөртекләре!
Кар кызы белән бергәләп
Биибез дип яталар.
Йөгерегез тизрәк,
Сезне Кар бөртекләре көтә.

***Бию "Кар бөртекләре" – Р.Гатина***

*(Кар кызы икенче тартманы ача, анда табышмак)*

**Кар кызы.** Үзебез ясыйбыз аны,
Тик өйгә булмый кертеп.
Тора бәйрәмнәң чыкканың
Ишек төбендә көтеп. *(Шаян музыка астына егереп Кар бабай керә)*

**Кар бабай**: Исенмесез дусларым, мин сезне күрергә бик шат. Сез уйнарга яратасызмы?

***Кар бабай белән уен.***

**Кар кызы.** Өченче тартманы ачабыз,
Шалтыравыклар белән күңел ачарбыз.
Сез аларны алыгыз, биергә чыгыгыз.

**Кар бабай.** Мин дә биергә яратам, сезнең белән биергә ярыймы?

***Шалтыравыклар белән бию, татар халык көе.***

**Кар кызы.** Ничек матур биеделәр, балалар!

**Кар бабай:** Киттем, балалар, Кыш бабайны ашыктырып карыйм. *(Кар бабай китә)*

**Кар кызы.** Минем тагын бер тартмам бар иде... Кая соң әле ул, югалттым микәнни? (*Өзләп йөри. Кыш бабай тавышы ишетелә*).

**Кыш бабай**. Нинди тартма ята, кем югалтты икән? *(Музыка астына Кыш бабай керә, кулында тартма тоткан)*

**Кыш бабай.** Исәнмесез, балалар! Мин сезгә ашыгып килдем, юлда бу тартманы таптым.

**Кар кызы.** Бу бит минем тартма. Рәхмәт, бабай!

**Кыш бабай.** Кызым**,** миңа тартманы ачарга рөхсәт бирәсеңме?

**Кар кызы**. Карыйк әле, күрик әле, нәрсә ята тартмада?

**Кыш бабай.** Әәә, монда фонарьлар ята.
Алар әйтә-
Тартмада ятасы килми, чыгарыгыз тизрәк,
Балалар белән биибез, җырлыйбыз бергәләп.

***Фонарьлар белән бию, Ф. Шәймәрданова***

*(Кыш бабай, Кар кызы балалар белән кушылып бииләр)*

**Кыш бабай.** Уф, арыдым, бераз утырыйм әле. Сез миңа шигырьләр әзерләдегезме?

**Алып баручы.** Балалар бик тырышып әзерләделәр, бабай!

***Яңа ел турында шигырләр***

**1 бала.** Яшел чыршы шундый матур,
Үзе биек, үзе зур.
Бик күп, бик күп уенчыклар,
Очында йолдыз да бар.
**2 бала.** Бик күңелле, рәхәт безгә,
Чыршы, синең янында.
Елмай әле, елмай шулай,
Тагын, тагын, тагын да.
**3 бала.** Наша елка велика,
Наша елка высока.
Выше папы, выше мамы,
Достает до потолка.
**4 бала.** Ёлка новогодняя,
Добрая красавица,
До чего же наша ёлка,
Всем ребятам нравится.
**5 бала.** Как блестит её наряд,
Как фонарики горят.
Наша ёлка с Новым годом,
Поздравляет всех ребят!

**Кар кызы.** Кыш бабай, балалар безгә күңелле бәйрәм күрсәттеләр, алар яңа ел бүләгенә лаек.

**Кыш бабай.** Мин балаларны бик яратам, бүләкләрем дә бар. Кая әле минем тылсымлы капчыгым? *(Кечкенә капчык ала)*

**Кар кызы.** Бабай, бу капчык түгел, монда барлык балаларга да бүләк сыймый бит!

**Кыш бабай.** Кызым, мин бит тылсымчы!
Син капчык үс әйдә,
Күчтәнәч белән тул әйдә!

*(Ут сүнә, тылсымлы утлар балкый һәм яңгырый. Чыршы астыннаң зур капчык барлыкка килә, ут кабызыла, балаларга бүләкләр таратыла)*

**Кыш бабай.** Җырладыгыз да, биидегез дә, уйнадыгыз да. Ә әти-әниләрегез, кунаклар - биимичә калдылар! Чыгыгыз, бергәләп күңел ачыгыз!

***Флешмоб***

**Кар кызы:**Чыршы әйләнәсендә
Җырлап биедек бергә,
Яңа елны каршылау
Күңелле булды безгә!
**Кыш бабай:** Безгә вакыт китәргә,
Кирәк барып җитәргә.
Башка балалар көтә,
Бәхетләр телим сезгә!
Саубулыгыз!!!
*(Кыш бабай белән Кар кызы чыгып китәләр)*

*Оригинальность – 88,41 % , https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

## Музыкаль чара “12 айда кунакта”

***Самигуллина Фирюза Фирдависовна – югары кв.категория, МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы музыка җитәкчесе, Яр Чаллы шәһәре***

**Яшь төркеме:** Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь).

**Максат:** Балаларны әкияти театральләштерелгән тамашага кертү юлы белән Яңа ел бәйрәменең тылсымлы атмосферасын булдыру.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы**:

•Балаларның актерлык сәләтен үстерү, үзенең әкияти персонажның артистларча хис – тойгылану рәвешендә күрсәтә белү; Хәрәкәт тәҗрибәсе үстерү, сүзлек запасын баету һәм активлаштыру; балаларның актерлык сәләтен үстерү.

**Тәрбия бурычы:**

• Балаларда бер-береңә карата дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү, балаларны таныш геройлар белән очрашудан алган хис- тойгылары белән баету, ата–аналарны педагогик процеска җәләп итү; балаларга шатлык хисләренең ирекле эмоциональ чагылышына ярдәм итү.

**Белем бирү бурычы:**

•Яңа ел әкиятенең уңай һәм тискәре персоналаҗлары турында балаларда күзәллау формалаштыру Балаларга Яңа ел бәйрәме турында гомүми мәгълүмәт бирү; балаларны игътибар белән тыңларга һәм күзәтергә өйрәтү; таныш музыкаль материалны, балаларның җыр, бию һәм уен күнекмәләрен кышкы әкият шартларында ныгыту.

**Фаразланган нәтиҗә:** балалар Яңа ел бәйрәме турында белемнәрен баеттылар.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү, музыкаль, сәнгать әдәбиятын һәм фольклорын кабул итү.

**Шәхси эш:** оялчан балаларны активлаштыру, җырлаганда хаталарны төзәтү, сорауларга җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек өстендә эш:**

**Актив сузлек:** исәнмесез, яңа ел, бәйрәм, рәхмәт, саубулыгыз.

**Пассив сүзлек:** Кыш бабай, 12 ай, кар кызы, үги ана, үги кыз.

**Алдан эшләнгән эш:** шигырьләр, җыралар ятлау, шөлдерле барабан белән уйнау, биюләр өйрәнү.

**Ата-аналар белән эш:** яңы ел турында рәсемнәр карау; шигырьләр, җыралар ятлау; бию өйрәнү; музыкаль репертуар сайлау; кирәкле атрибутларны туплау.

**Демонстрацион материаллар һәм җиһазлар:**,

**Таратма әсбаплар:** шөлдерле барабаннар, учак, умырзая чәчәге, персонажлар өчен костюмлар.

**Катнашучылар:** Алып баручы, Кыш бабай, Кар Кызы, Үги ана, кыз, Үги кыз, 12 ай, скоморохлар, әкиятче, принцесса, профессор, белдерүче.

**Кулланылган әдәбият:**


1.”Җырлыйк, уйныйе, нәниләр!” (сборние песен, игр для детей от 2 до 9 лет) Сабирова С.М. – Чаллы шәһәре, 1994.

2. “Ясыйк матур түгәрәк” – методик кулланма “Балалар бакчасында музыка” сериясе, өченче китап – Казан “Халкыбыз мирасы” нәшрияты

3. “Ритмик мозаика” – А.И. Буренина, Санкт – Петербург, 2000

4. “Үз җырыбыз булсын әле” – Г.Гәрәева - 1993


**Эш барышы:**

*Балалар музыка астында залга керәләр. Чыршы янында калалар.*

**1 бала.** Нинди күркәм матур чыршы
Безгә кунакка килгән.
Төрле уенчыклар элгән,
Энҗе карларын сипкән.

**2 бала.** Бәйрәмебезнең бизәге,
Яшел чыршы янында.
Яңа елны каршыларга
Килдек менә тагын да.

**3 бала.** Уен-көлке яңгырап торсын,
Балалар тавышыннан.
Бәхет нурлары сибелсен
Яңа ел чыршысыннан.

**4 бала.** Засверкай, огнями елка,
Нас на праздник позови!
Все желания исполни,
Все мечты осуществи!

**5 бала.** Ёлка наша вся в игрушках,
И шары на ней блестят.
Наша ёлка с Новым годом
Поздравляет всех ребят.

**6 бала.** На свете так бывает
Что только раз в году
На елке зажигают
Прекрасную звезду.
Звезда горит, не тает,
Блестит прекрасный лёд.
И сразу наступает
Счастливый Новый год!

***Җыр “Яңа ел” (С.Сабирова)***

**7 бала.** Вакыт җитте, сәгать сукты.
Әкиятне башларга.
Ягез, җайлап утырыгыз,
Әзер булып тыңларга.

*(Әкиятче музыка астына керә,исәнләшә)*

**Әкиятче.** Бар җихан акка торенгән

Җем-җем килеп кар көлә

Торле могҗизалар алып

Кышкы әкият килә!

Тамашалар көтә безне

Бүген бәйрәм кичендә.

Чү, музыка ишетелә

Кемдер кунакка килә.

*(Музыка астына 2 скоморох керә)*

**1 Скоморох:** Елда унике ай, аны балалар белә.

Ләкин айлар беркайчан да берсен берсе күрмиләр.

**2 Скоморох:** Әмма кешеләр сөйли, бер кыз бу 12 туганны учак янында күргән имеш.

**Әкиятче:** Бу болай булган… *(Музыка астына, залга принцесса һәм профессор керәләр)*

**Принцесса:** Кояш ялт иткән

Үлән яшәрә.

**Профессор:** Яз исен сизеп,

Карлыгач килгән!

**Принцесса:** (*тәрәзәгә карый)*

Туйдым мин бу бураннаң,

Тизрәк апрель килсен иде!

**Профессор:** Табигать законың үзгәртергә мөмкин түгел!

**Принцесса:** Мин умырзая чәчәген яратам. *(Аяк белән тыпылдый)* Кем дә кем таң атканчы умырзая чәчәкләре китерә, шуңа бер кәрҗин алтын биреләчәк. Чәчәк китермичә Яна ел булмаячак!!!

*(Ике белдерүче (глашатай) чыга)*

**1 Белдерүче**:

Под праздник новогодний издали мы приказ

Пускай цветут сегодня подснежники у нас.

Бегут ручьи в долину, пришел зиме конец.

Подснежников корзину несите во дворец.

**2 Белдерүче**

Нарвите до рассвета подснежников простых

И вам дадут за это корзину золотых.

*(Залга Үги ана, һәм кызы керәләр)*

**Кызы.** Әнием, минем бәйрәмгә барасы килә!!! Урманга барам, умырзаяларны табам, патша бәйрәменә элгәм..

**Үги ана**. Анда салкын, кызым, тунарсын!

**Кызы**. Алайса сенлем урманнаң кайткач, җибәр шуны.

*(Үги кыз керә)*

**Үги кыз.** Ай, салкын урамда.

**Үги ана**. Ашыкма чишенергә, тагын урманга барырсын, умырзаая җыярга кирәк.

**Үги кыз.** Нинди умырзая, декабрь аенда, урманда кар!

**Кызы.** Кар астыннан җыярсын!

**Әкиятче.** Үги кыз елый – елый, ертык шәлен бәйләп, урманга китте.

Кыз урманга чыгып киткән, салкын икән, буран икән, кар бөртекләре бөтереләрләр икән...

***“Кар бөртекләре” жыры***

**Әкиятче.** Бара,бара...якында гына, кызыл булып дөрләп, янган учак кургән, учак төбенә 12 бертуган жыелган икән...

***“12 ай бию”***

**Декабрь.**

Мин декабрь булам.
Төн яктан динезләрдән,
Көмештәй ишекләрдән,
Бар дөньяга чакырам
Давыл, суык хәм буран!

**Январь.**

Мин суык кыш ае!
Өшетәм бит-кулларны,
Туздырам карларны,
Каплыйм бөтен юлларны!

**Февраль.**

Нәрсә кирәк, чибәр кыз?
Кәрзин тотып, әллә нарат гөмбәсенә килдең?

**Үги кыз.** Ююк...

**Сентябрь.** Бәлки, гөмбә җыярга килгәнсендер?

**Үги кыз.** Ююк...мина умырзая чәчәкләре кирәк!

**Июнь.** Алайса, бу синең кунагын, Апрель!

**Апрель.** Алайса, январь туган, бер генэ сәгатькә үз урыныңны биреп тор әле миңа.

**Январь.** Мин бирер идем дә, февраль-март ни дияр?

**Февраль.** Мин риза!

**Март.** Мин дә урынымны бирәм!

**Апрель.**

Йөгерсен гөрләвекләр,
Җәелсен күлдәвекләр.
Кышкы озын йокыдан
Торып чыксын бөжәкләр.
Аю да чыга уянып,
Кошлар сайрый куанып.
Кар катламы астыннаң
Умырзая чыга калкып!

***“Умырзая бию”***

*(Кыз кәрзингә умырзаялар тотып кала)*

**Үги кыз.** Рәхмәт!

Бәлагә ярдәм иттегез.

Чөнки сезнең катнашыгыздан башка,

Беркайда да чәчәкләр тапмас идем.

**Принцесса.** Яңа ел булмаячак! Минем боерыкны оннытыгыз ахрысы!? Умырзыясыз январь ае булмаячак!

**Профессор.** *(чыга)* О принцесса хәбәр килде, китерәләр!

**Принцесса.** Димәк! Яңа елны каршы алырга вакыт!

Кыш бабай белән Кар Кызы белән монда!

*(Фанфаралар яңгырый. Музыкага Кыш бабай, Кар кызы керә)*

**Кыш бабай.** Исәнмесез, балаларым,
Минем алсу алмаларым.
Зур кызларым, зур улларым,
Минем газиз күз нурларым.
Исәнмесез, кунаклар
Бәйрәм белән туганнар.
Бәхет белән, шатлык белән
Килсен сезгә Яңа еллар.

**Кар кызы.** Мин дә сезне барыгызны
Котлыйм Яңа ел белән!
Яңа ел сезгә китерсен
Зур бәхетләр, шатлыклар.
Әйдәгез, чыршы янына
Җырлыйбыз матур җырлар!

***“Кыш бабай жыры”***

**Бала:** Һәр ел саен Яңа елны
Зарыгып көтеп алабыз.
Чыршы янында бергәләп
Биеп күңел ачабыз!

***Кумәк бию. Уен***

*Утыралар.*

**Алып баручы.** Кыш бабай, бераз ял итеп, шигырьләр тыңлап ал.

***Шигырьләр.***

**Кыш бабай:** Уйнадык та, биедек тә,
Шигырьләр дә тыңладым.
Инде хәзер бәйрәм бетте,
Җитте хушлашу сәгате!

**Алып баручы.**Кыш бабай, син тагын иң күңелле мизгелне оныттын бит...

**Кыш бабай.** Бик куңелле булды бит инде, тагын нәрсә кирәк?!

**Алып баручы.** Балалар, нәрсә кирәк әле сезгә?

**Балалар.** Буләкләр!!!

**Кыш бабай.** Әй, тишек башым, оныта язганмын бит...

*Сюрприз моменты. Алып баручыларның тәбрикләү сүзләре.*

*Оригинальность- 93,53%, ссылка https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге: “Урманга кунакка бару”**

***Шакирова Айзилә Георгий кызы, 1 кв.категория,***
МАМББУ “№113 нче “Тиктормаслар” балалар бакчасы тәрбиячесе,
Яр Чаллы шәһәре Татарстан Республикасы

**Яшь үзенчәлекләре:** 5-6 яшьлекләр, зурлар төркеме

**Максат:** әвәләп ясау ярдәмендә балалар иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы:**

●иҗади эшчәнлек нигезе буларак баланың күзаллау сәләтен үстерү;

●бәйләнешле сөйләм телен үстерү;

●коммуникатив сыйфатларын үстерү.

**Тәрбия бурычы:**

●бирелгән биремне пөхтә итеп эшләүне тәрбияләү;

●төркемдә эшләргә өйрәтү;

●үзара дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү;

●башланган эшне азагына кадәр башкарып чыгуга ирешү**;**

●урман җәнлекләренә мәхәббәт һәм сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:**

●гәүдә өслеге фактурасын сыгылмалы таякчык кулланып, җәнлекләрне катнаш ысул белән әвәләп ясауга өйрәтүне дәвам итү;

●таныш булган әвәләү алымнарын файдалану күнекмәләрен ныгыту;

●гадәти хәрәкәтләрне күрсәтә торган әвәләү күнекмәләрен –шомарту ысулын ныгытуны дәвам итү;

● тәннең пропорциональ нисбәтен ясарга өйрәтүне дәвам итү;

●әхлакый күзаллауны ныгыту.

**Көтелгән нәтиҗәләр:** алган белемнәрне балалар мөстәкыйль уен эшчәнлегендә куллана беләләр; атна көннәрен дөрес итеп атыйлар; безнең урманнарда тереклек итүче хайваннар турында күзаллауларга ия; хайваннарны әвәләү ысулларын беләләр; хайваннарны әвәләп ясый беләләр.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, рәсем ясау, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** пассив балаларны әңгәмә барышында активлаштыру, авырсынган балаларга ярдәм итү; сорауларга җавапны тулы итеп әйтергә өйрәтү.

**Сүзлек өстендә эш:**

**Актив сүзлек:** аю, куян, төлке, тиен, шар, баш, койрык, колак, күзләр, тәпиләр.

**Пассив сүзлек:** урманчы, җәнлекләр, йомарлау, кисәк, ылыслы, яфраклы, юан, нечкә, шомарту.

**Алдан эшләнелгән эш:** урман җәнлекләре турында әңгәмә, әвәләп ясау ысуллары белән таныштыру; дидактик уеннар “Тән өлешләре”, “Кыргый һәм йорт хайваннары”.

**Күрсәтмә материал:** урманчы, җәйге урман рәсеме;

**Тарату материалы:** аю, бүре, куян, төлке, тиен рәсемнәре; пластилин, әвәләп ясау такталары, сыгылмалы таякчыклар, салфеткалар.

**Техник чаралары:** интерактив такта, мольберт, магнитлар.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы “Туганнан алып мәктәпкәчә”, Мозаика – Синтез/Москва, 2015/ ХӘТЕР Казан, 2016;

2.Р.М.Зиннәтова “Сурәтләү һәм кору эшчәнлеге”.

**Эшчәнлек барышы**

**1.Кереш өлеше**

**Тәрбияче:** Хәерле көн! Исәнмесез балалар. Хәлләрегез, кәефләрегез ничек бүген?

**Балалар:** Исәнмесез.

**Тәрбияче:** Әйдәгез әле, кәефләребезне тагын да күтәреп, бер-беребезне сөендереп алыйк. Балалар килегез, түгәрәккә басыгыз.

Барлык балалар да түгәрәккә җыелды
Мин синең дус һәм син минем дустым
Кулга –кул тотынышыйк
Һәм бер-беребезгә елмаешып алыйк.

Көнебезне башлап җибәрәбез. Көнегез күңелле үтсен! *(Балалар берсен берсе сәламли һәм теләкләрен әйтәләр)*

**2.Төп өлеш**

**Тәрбияче:** Балалар, бүген иртән безнең төркемгә хат килгән. Кем җибәргән икән ул хатны?*(Тәрбиче хатны күрсәтә, укый)*

Безгә бу хатны урманнан урманчы җибәргән, ул безне кунакка чакыра.

**Тәрбияче:** Балалар, мин сезне урманга кунакка барырга чакырам. Телисезме? Нинди транспорт белән барабыз икән? *(Тәрбияче автобус макетына күрсәтә. Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әлбәттә, автобус белән барабыз. Әйдәгез, автобустагы урыннарны алыгыз. (*Балалар тезелеп куелган урындыкларга утыралар. Җыр көе куела яңгырый)*

Автобуска утырдык
Кунакка җыендык.
Бип-бип-бип, бип-бип-бип
Кунакка җыендык.
Барабыз урман аша,
Безгә кояш елмая.

Бип-бип-бип, бип-бип-бип

Безгә кояш елмая. *(Бергәләп җырлыйлар)*

**Тәрбияче:** Сезнең белән килеп тә җиттек. Кайда килдек без балалар? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Дөрес, урманга килдек. Нинди матур безнең урман! Ылыслы һәм яфраклы агачлар үсә. Балалар, әйтегез әле, урманда нинди ел фасылы икән? *(Тәрбияче рәсемнәр күрсәтә. Сорауларга җавапны тулы итеп әйтү күнекмәләре ныгытыла)*

**Тәрбияче:** Дөрес, урманда җәй фасылы. Сез җәйнең нинди айларын беләсез? Санап китегез? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әфәрин, бик дөрес әйттегез. Июнь, июль, август - җәй айлары.

**Тәрбияче:** Безне урманга кем кунакка чакырды искә төшерик әле? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Дөрес, безне урманга урманчы чакырды. *(Тәрбияче рәсемен күрсәтә).* Ул урмандагы җәнлекләр белән сезне таныштыракчы була.

**Тәрбияче:** Балалар, әйтегез әле, урманда безнең нинди җәнлекләр яши? *(Балаларның җаваплары)* Урманчы безгә җәнлекләр турында табышмаклар әзерләгән.

Асрамый да умарта,
Балны бик-бик ярата.
Кышын сөя йокыны,
Язгача тормый ята. *(Аю)*

Әдәпле генә кодача
Тавыкларны ярата. *(Төлке)*

Әйтим бер йомак:
Җәен соры, кышын ак,
Төймә койрык, шеш колак. *(Куян)*

Кош түгел, оча,
Ябалактан курка,
Чикләвекне ярата,
Сызгырса, урманны яңгырата. *(Тиен)*

*(Тәрбияче балаларга җәйге урман рәсеменә җәнлекләрне беркетергә тәкъдим итә)*

**Тәрбияче:** Балалар, мин сезгә урманда күргән җәнлекләрне урманчыга эвәләп ясарга тәкъдим итәм. Зур эшкә керешер алдыннаң, сезнең белән әзрәк ял итеп алабыз.

**Ял минуты**

Без әле бераз ардык,
Ял итәргә уйладык:
Башны иябез алга,
Ә аннары- артка.

Уңга- сулга борабыз,
Аннан карап торабыз.
Иң өстен сикертәбез,
Кулларны биетәбез.
Бер алга, бер артка сузып
Күңелле ял итәбез.

*(Тәрбияче аю, куян, төлке, тиен җәнлекләрен яхшылап карарга тәкъдим итә, аларның гәүдә төзелешенә игътибар итә. Сораулар бирелә, шәхси эш эшләнелә. Балаларга өстәлдә куелган материалларга игътибар ителә, урыннар алырга тәкъдим ителә. Тәрбияче эш барышын аңлата һәм үзе дә балалар белән бергә ясый)*

**Тәрбияче:** Бу җәнлекләрнең тышкы кыяфәтләрендә уртак яклар бармы? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Дөрес, аларның башы, тәпиләре, койрыйгы, колаклары бар; гәүдә төзелешендә уртак яклары бар.

**Тәрбияче:** Аермалары нәрсәдә икән? (*Балаларның җаваплары)* Бик дөрес, балалар. Төсләре, зурлыклары, колак, койрык формалары белән аерылалар.

**Тәрбияче:** Сез ничек уйлыйсыз, эшне кайсы өлештән башларга кирәк? *(Балаларның җаваплары).* Без гәүдә һәм тәпиләрен бер кисәк пластилиннан ясыйбыз, ә башын һәм койрыгын аерым кисәктән ясарга кирәк. *(Тәрбияче гәүдә ясаганда, кулларның хәрәкәтен күрсәтергә өнди)*

**Тәрбияче:** Алга таба без нинди өлеш ясаячакбыз? *(Балаларның җаваплары)* Нинди формада ул? Шарны ничек алырбыз?

*(Тәрбияче баш ясаганда, кулларның хәрәкәтен күрсәтергә өнди)*

**Тәрбияче:** Аннары башны һәм гәүдәне тоташтырабыз. Без алга таба нишләрбез? *(Балаларның җаваплары)*. Аяклар, колаклар, койрыклар - дөрес.

**Тәрбияче:** Без ничек күзләр ясыйбыз? *(Балаларның җаваплары).* Күзләр стек ярдәмендә ясала. Ә хәзер эшкә керешәбез. Өстәлләрдә такта, пластилиннар, сыгылмалы таякчык куелган. Хәзер сез үзегез теләгән җәнлекләрне әвәләп ясарсыз.

*(Мөстәкыйль эшчәнлек вакытында балаларга киңәш бирелә, кирәк булса, ярдәм күрсәтелә)*

**Эш барышы:**

-пластилинны йомарламын зур һәм кечерәк ике кисәккә бүләбез;

-зур кисәкне юан багана итеп тәгәрәтәбез;

-багананың очларын сыгылмалы таякчык белән кисеп алып, шулардан җәнлек тәпиләрен ясыйбыз;

-юан багананы бөгеп, гәүдәсен һәм тәпиләрен ясыйбыз;

-кечерәк кисәкне зур һәм кечкенә тагын ике кисәккә бүләбез, шул ук кисәктән башын ясыйбыз; йөзен уеп куябыз, өстә, чеметеп һәм очлайтып, колакларын ясыйбыз;

-башын гәүдәсе белән тоташтырып, шомартып куябыз;

-өслекне тигезләп чыгабыз;

-калган пластилин кисәген тәгәрәтеп, бер башын очлайтып, койрыгын ясыйбыз. *(Балалар үзләре теләгән җәнлекләрне әвәләп ясыйлар, тәрбияче эш барышының үтәлешен күзәтә)*

**Тәрбияче:** Афәрин балалар, булдырдыгыз. *(Тәрбияче балаларның эшләренә игътибар итә).* Урманчыга сез әвәләп ясалган җәнлекләрегез бик ошады ахры. Ул безгә бүләк әзерләде *(Урман җәнлекләре буягычлары таратыла).* Безгә дә балалар, үзебезнең төркемгә кайтырга вакыт җитте.

**Тәрбияче:** Әйдәгез, автобустагы урыннарны алыгыз. *(Балалар тезелеп куелган урындыкларга утыралар. Җыр көе куела яңгырый)*

3.**Йомгаклау өлеше.**

**Тәрбияче:** Балалар, бүген сез нәрсәгә өйрәндегез? Безнең урманда нинди хайваннар яши? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Без сезнең белән кунакта булдык, урманга автобуска утырып бардык. Безнең урманда яшәүче җәнлекләрне әвәләп күрсәттек.

**Тәрбияче:** Балалар бер-берегезгә елмаеп, кочаклашып алыгыз.

*Оригинальность- <u>100%,</u> ссылка https://users.antiplagiat.ru*

**Оештырылган белем бирү эшчәнлеге: "Яңа елга әзерләнү"**

***Шакирова Айзилә Георгий кызы - 1 кв.категория,***

*МАМББУ №113 нче "Тиктормаслар" балалар бакчасы тәрбиячесе,*

*Яр Чаллы шәһәре Татарстан Республикасы*

**Яшь үзенчәлекләре:** зурлар төркеме (5-6 яшь).

**Максат:** балаларны атнаның һәр көне санап үтәүдә һәм тәртип саннарын атауда белемнәрен ныгыту.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы:**

•логик һәм образлы фикерләүне үстерү;

•бәйләнешле сөйләм телен үстерү;

•хәтердә калдыру сәләтен, күзаллауларны киңәйтү.

**Тәрбия бурычы:**

•бәйрәмнәргә кызыксынуны тәрбияләү;

•вакыт белән бәйле рәвештә үз эшчәнлегеңне оештырырга омтылуны тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:**

•атна көннәре турындагы белемнәрне ныгыту, эзлеклелегенә төгәлләкне ныгыту;

•"ничә", "нинди" сорауларга балаларның белемнәрен гомумиләштерү;

•7 чикләрендә тәртип буенча санау күнекмәләрен камилләштерү.

**Фаразланган нәтиҗә:** балалар атна көннәренең эзлеклелеген атый ала, кәгазь яссылыгында ориентлашуны беркеттеләр, алган белемнәрен ирекле эшчәнлектә куллана беләләр.

**Балалар эшчәнлегенең төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү, рәсем ясау.

**Шәхси эш:** пассив балаларны әңгәмә барышында активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү, 7 чикләрендә тәртип буенча санау.

**Сүзлек өстендә эш:** актив сүзләр: дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе, беренче, икенче, өченче, дүртенче, бишенче, алтынчы, җиденче; пассив сүзләр: бер, ике,өч, дүрт, биш, алты, җиде, сул, уң, өс, ас, атна көннәре.

**Алдан эшләнелгән эш:** 7-гә кадәр санау, атна көннәре белән таныштыру, "Винни Пух әсәрен уку", кирәкле рәсемнәрне әзерләү.

**Демонстрацион материаллар һәм җиһазлар:** интерактив такта, мольберт, **"**Винни Пух" уенчыгы, "Винни Пух"ның яңа елга эзерләнүе" темасына иллюстрацияләр, "Яңа ел" җырының аудиоязмасы.

**Тарату материалы:** саннар, кәгазь битләре, һәр бала өчен төсле каләмнәр.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы "Туганнан алып мәктәпкәчә", Мозаика – Синтез/Москва, 2015/ ХӘТЕР Казан, 2016;

2.З.Г.Шәрәфетдинова, И.Җ.Хәбибуллина, Ф.В.Хәзрәтова "Математикага өйрәнәбез.

**Эшчәнлек барышы**

**1. Кереш өлеш**

**Тәрбияче:** Исәнмесез. Хәерле көн, балалар. Хәлләрегез, кәефләрегез ничек? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Балалар, кәефләребезне тагын да күтәреп, бер-беребезне сөендереп алыйк. *(Әкрен генә җыр тавышына, хәрәкәтләр ясыйлар)*

Йомшак суны алабыз,
Күзләребезне йомабыз,
Рәхәтләнеп уйный-уйный
Яна ел бәйрәменә әзерләнәбез.

**Тәрбияче:** Әйдәгез, бер-беребезне кочаклап, көнебезне башлап җибәрәбез. Көнегез күңелле үтсен! *(Балалар берсен берсе сәламли һәм теләкләрен әйтәләр)*

**2.Төп өлеш.**

**Тәрбияче:** Карагыз әле, безгә бүген кунак килгән? Таныдыгызмы бу кунакны? Кем икән ул? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Бик дөрес. Бу бит безнең Винни Пух. Исегезгә төшерегез әле, балалар, Винни Пухның дуслары кемнәр әле? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Винни Пухның дуслары төймә борын, куян, ишәк һәм ябалак икән шул.

**Тәрбияче:** Ә хәзер, мин сезгә табышмак әйтәм, игътибар белән тыңлагыз. Бер өердә җидешәр кош төркем-төркем очалар, әмма кире кайтмыйлар. Нәрсә дип уйлыйсыз, балалар? (*Балаларның җаваплары.)*

**Тәрбияче:** Әйе, дөрес бу атна көннәре. Балалар, атнада ничә көн? Санап бирегез әле. (*Балаларның җаваплар бирүе, аларны активлаштыру)*

**Тәрбияче:** Эйе, атнада җиде көн: дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе.

**Хәрәкәтле уен**

Дүшәмбе көнне мин су коендым, (йөзүне сурәтлибез)
Ә сишәмбе көнне рәсем ясадым. (рәсем ясыйбыз)
Чәршәмбе көнне озак юындым, (юынабыз)
Ә пәнҗешәмбе көнне футбол уйнадым. (урында йөгерү)
Җомга көнне мин сикердем, йөгердем (урында сикерүләр)
Бик озак биеде. (урында әйләнеп йөрибез)
Ә шимбә, якшәмбе (кул чабабыз)
Көне буе ял иттем. (чүгәләп йоклап китәбез).

**“Винни Пух Яңа елга әзерләнә” дидактик күнегүе.**

**Тәрбияче:** Беркөнне иртән торгач Винни Пух, календарга карады. Ул гаҗәпләнеп куйды, нибары яңа елга бер атна вакыт калганын күреп алды. Яңа елга ул үзенең якын дусларын төймә борынны, куянны, ишәкне, ябалакны өенә чакырган булган. Яңа ел атнаның якшәмбе көненә туры килә икән.

**Тәрбияче:** Винни Пух һәр көнне нәрсә эшлиячәген дәфтәренә язып чыккан. Балалар, әйтегез әле, атнаның беренче көне ничек атала? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Дөрес, атнаның беренче көне - дүшәмбе. Дүшәмбе көнне Винни Пух үзенең йортын җыештырды. *(Тәрбияче рәсем күрсәтә һәм аны “бер”саны астына беркетә)*

**Тәрбияче:** Дүшәмбе көненнәң соң нинди көн килә? *(Балаларның җаваплары.)*

**Тәрбияче:** Сишәмбе көнне Винни Пух үзенең якын дусларына яңа ел бүләкләре әзерләргә кирәклеген исенә төшерде. Ул бүләксез яңа ел бәйрәме күңелле үтмиячәген уйлады да, тиз генә велосипедына утырып кибеткә ашыга-ашыга китте. *(Тәрбияче Винни Пухның велосипедка утырып барган рәсемен күрсәтә һәм аны “ике”саны астына беркетә. Рәсемне беркетү балаларга тапшырырга мөмкин)*

**Тәрбияче:** Сишәмбе көненнән соң нинди көн килә? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Бик дөрес, чәршәмбе – атнаның өченче көне. Винни Пухның яңа ел бәйрәмендә дуслары янында бик матур итеп күренәсе килде һәм ул гүзәллек салонына барырга уйлады. Балалар, ничек уйлыйсыз, Винни Пух гүзәллек салонында нишләде икән? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Хәзер ул бик-бик матур күренә. *(Тәрбияче рәсем күрсәтә һәм аны “өч”саны астына беркетә)*

**Тәрбияче:** Чәршәмбе көненнән соң нинди көн килә балалар? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Пәнҗешәмбе – атнаның дүртенче көне. Винни Пух бүген йортында чыршы куйды һәм ул аны бизәде. Балалар, әйтегез әле, Винни Пух чыршыны нәрсә белән бизәде икән? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Чыршыга ул чыршы алкалары, мәрҗәннәр, брошкалар, шарлар элеп чыкты. Яңа ел бәйрәме чыршысыз булмый дип уйлады. *(Тәрбияче рәсемнәрне күрсәтә һәм аны "дүрт"саны астына беркетә)*

**Тәрбияче:** Балалар, пәнҗешәмбе көненнән соң, нинди атна көне килә? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Бишенче көн безнең җомга көне, дөрес җавап бирдегез. Җомга көнне Винни Пух меню төзи башлады. Бәйрәмгә нинди тәмле әйберләр әзерләвен дәфтәренә язып алды. Азык-төлек исемлеген алып, ул кибеткә ашыкты. *(Тәрбияче рәсемнәр күрсәтә һәм аны "биш"саны астына беркетә)*

**Тәрбияче:** Ничек уйлыйсыз балалар, Винни Пух кибеттән нинди азык-төлекләр алды икән? (*Балаларның җаваплары)*. Бик дөрес, яңа ел өстәлендә бик күп тәмле ризыклар булырга тиеш.

**Тәрбияче:** Атнаның алтынчы көне ничек атала икән? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Алтынчы көн ул шимбә дөрес әйттегез. Винни Пух бу көнне кием кибетенә барырга уйлады. Аның дуслары янында матур күренәсе килде. Балалар, ничек уйлыйсыз кием кибетеннән нәрсәләр алды икән Винни Пух? *(Тәрбияче рәсемнәр күрсәтә һәм аны "алты"саны астына беркетә. Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Атнаның соңгы көнен әйтегез әле? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Дөрес әйттегез, якшәмбе – атнаның җиденче көне. Бер атна безнең сизелмичә дә үтеп бара. Яңа ел бәйрәме килеп тә җитте. Винни Пух бик тырышты, нык әзерләнде. Ә хәзер инде чакырган кунакларны көтергә һәм аларга бүләк бирергә генә калды. *(Тәрбияче рәсемнәрне күрсәтә һәм аны "җиде"саны астына беркетә)*

**"Винни Пухның төшен сурәтлә" дидактик күнегү.**

**Тәрбияче:** Винни Пух бик матур төш күрә. Ул яхшы кәеф белән уяна. Күргән төшен, кәгазъ битендә ясамакчы була, Винни Пух үзенең төшен бик тә дусларына ясап, картинага күчермәкче була. Ләкин ул ничек итеп ясарга кирәклеген белми. Әйдәгез, балалар Винни Пухка булышабыз. Алдыгызда ак кәгазъ бите һәм төсле карандашлар тора. *(Тәрбияче өстәлдәге татарма әсбапларга игътибар итә)*

**Тәрбияче:** Мин сезгә Винни Пух күргән төшне әйтеп барам, ә сез кәгазъләрегезгә ясап барыгыз. Кәгазъ битенең өске сул почмагына болыт, астагы сул почмакта өч чыршы агачы ясагыз. Астагы уң почмакта өч чыршы агачы, өстәге уң почмакта болыт сурәтләгез. Кәгазъ битенең уртасына биш кар бөртеге ясагыз. *(Тәрбияче балаларның эш үтәлешен күзәтә)*

**Тәрбияче:** Менә безнең Винни Пух күргән кышкы урманны сурәтләдек. Винни Пухка сезнең ясаган рәсемнәрегез бик ошады. Ул аларны үзенең дусларына бүләк итәчәк. Аңа булышкан өчен, ул сезгә буягычлар әзерләгән. Винни Пухка китәргә вакыт инде, Яңа елга әзерләнергә кирәк. *(Балалар саубуллашалар)*

**3. Йомгаклау өлеше.**

**Тәрбияче:** Балалар сезгә күбрәк нинди биремнәр үтәргә ошады? Иң җиңеле һәм авыры нинди бирем тоелды? Тагын бер тапкыр, атна көннәрен санап үтик *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Без сезнең белән Винни Пухка булыштык, Яңа елга әзерлеген планлаштырып үттек, аның дусларын искә төшердек, атна көннәрен санап үтик, аларның атнада тәртибен искә төшердек.

**Тәрбияче:** Бер-берегезгә карап елмаегыз. Мин сезне “Яңа ел” музыкасына бипергә чакырам. *(Балалар җыр көенә биилләр)*

*Оригинальность 98,9%, https://text.ru/antiplagiat*

## «ТАБИГАТЬНЕ ЧҮП-ЧАРДАН САКЛЫЙБЫЗ»

***Шарафиева Рамиля Азатовна-югары кв.категория,***

*113санлы «Тиктормаслар» балалр бакчасы тәрбиячесе, Яр Чаллы шәһәре*

**Яшь үзенчәлекләре:** зурлар төркеме (5-6 яшь)

**Максат:** Балаларның табигать, әйләнә-тирә мохитне саклау турындагы белемнәрен ныгыту һәм системалаштыру.

**Бурычлар:**

*Белем бирү бурычы:* агач төрләре һәм урман төрләре турында белемнәрен арттыру; табигатьтә үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту; чүп-чарларны аерып җыю турында күзаллауларын киңәйтү.

*Үстерү бурычы:* зиһенне, игътибарлыкны, фикерләүне, күзаллауны үстерү.

*Тәрбия бурычы:* әйләнә-тирә дөньяга сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү; төркемдә, коллективта аралашу осталыкларын тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:** алган белемнәрне балалар мөстәкыйль уен эшчәнлегендә куллана беләләр; табигатьтә балалар үзләрен дөрес тота (җәнлекләр һәм үсемлекләр белән куркынычсыз тәэсир итешү серләрен беләләр, табигатьне саклыйлар).

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** оялчан балаларны активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек өстендә эш:**

*Актив сүзлек:* аю өне, оя, пластик, кәгазь, пыяла, ылыслы, яфраклы, кушма;

*Пассив сүзлек:* органик, контейнер.

**Алдан эшләнгән эш:** табышмак чишү, фикерләү биремнәр чишү, календарь күзәтү, кыргый хайваннар турында презентация карау, экологик һәм табигать саклау темаларына сюжетлы-ролле, дидактик уеннар; күрсәтмә һәм таратма материал әзерләү.

**Материаллар һәм җиһазлар:**

**Демонстрацион материаллар һәм җиһазлар:** интерактив экран, ноутбук, мультимедиялы презентация «Урманда», ИКТ уен «Кемнең өе?», мольберт, магнитлар.

**Таратма әсбаплар:** һәр балага аерым биттә бирем, уен өчен карточкалар, өлешләргә бүленгән кошлар рәсеме.

**Кулланган әдәбият:**

1. Туганнан алып мәктәпкәчә программасы/ Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясе, -3 нче басма.-М.:Мозайка-Синтез, 2015;
2. Региональная программа дошкольного образования , автор Р.К.Шаехова.

## Эшчәнлек барышы

**1. Кереш өлеше**

**Тәрбияче:** Балалар, каргыз әле, минем кулымда нәрсә бар? *(Тәрбияче баларның кулдагы тупка игътибар итүен тели)*

**Тәрбияче:** Бу тупның бүген кәефе нинди микән? *(Тәрбияче баларның барлык җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Туп бүген шат, күңелле.

**Тәрбияче:** Һәрберегезгә шушы тупны кулыгызда тотып карарга тәкъдим итәм, тупка елмаеп, берберебезгә яхшы көннәр, күтәренке кәефләр телик.

*(Балалар тупны бербересенә бирәләр һәм яхшы кәеф телилиәр).*

*(Аудиоязма тавышы ишетелә "Килгән хәбәр тавышы". Компьютер экранында "Урман хуҗасыннан" хат килә. Тәрбияче хатны укый: "Исәнмесез, кадерле балалар! Минем урман кайгыда, бөтен җир чүпкә баткан, җәнлекләр юкка чыкты, кошлар сайрамый башлады. Урманны җыештыруда ярдәмегезне сорыйм. Очрашуларга кадәр, "Урман хуҗасы!")*

**Тәрбияче:** Нишләргә соң безгә, балалар? *(балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әлбәттә, булышабыз. Әмма урманда без авырлыклар очрата алабыз. Сез әзерме? *(балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Урманда үзеңне тоту кагыйдәләрен исегезгә төшерүегезне сорыйм**.** *(Тәрбияче баларның җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Дөп-дөрес. Урманда кычкырып сөйләшергә, тавышланырга ярамый. Артыңнан чүп калдыру тоела. Кошлар оясын ватырга ярамый. Агачларны сындырырга , бөҗәкләрне үтерергә ярамый, кыргый хайваннарны, урман җәнлекләрен өйгә алып кайту тоела. Чәчәкләрне өзергә, кырмыска ояларын туздырырга ярамый. Кагыйдәләр бик күп…

**Тәрбияче:** Без урманга ничек булыша алабыз? *(Тәрбияче баларның җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Агач утыртырга була, кошларга җим сибә алабыз, чүпләрне җыештыра алабыз…

**2. Төп өлеш**

**Тәрбияче:** Шушы эшләрне җиңелрәк эшләр өчен, сорауларга җавап бирүегезне сорыйм:

1. Дүрт мәченең ничә койрыгы бар? *(баларның җаваплары)*
2. Ике тычканда ничә колак? *(баларның җаваплары)*
3. Буш стакан эчендә ничә чикләвек бар? *(баларның җаваплары)*
4. Нәрсә күбрәк: атна яки 7 көн? *(баларның җаваплары)*

5. Өч ак күгәрчен түбәдә утырган. Икесе очып киткән. Ничә күгәрчен утырып калган? *(баларның җаваплары)*

6. Керпе урман буйлап барганда умырзая чәчәкләрен очраткан. Икесе каен агачы астында, берсе – имән агачы астында, ничәү була барсы бергә? *(баларның җаваплары)*

7. Ике чиби басып тора, икесе кабык эчендә утыра, ничә чебие бар тавыкның? *(баларның җаваплары)*

8. Биш нәни аю баласын әниләре йокларга яткырган. Берсе хич йоклый алмый. Ә ничәсе тәмле төш күреп ята? *(баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әфәрин, балалар, мин сезнең әзер булуыгызны аңладым!

*(Экранда яфраклы урман рәсеме чыгарыла)*

**Тәрбияче:** Экранга карагыз әле, балалар. Каен, имән, миләш агачлары үсә торган урман ничек атала? *(Тәрбияче баларның җавапларын тыңлый. Сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә өнди)*

**Тәрбияче:** Мондый урман яфраклы урман дип атала, чөнки анда яфраклы агачлар һәм куаклар үсә.

*(Экранда ылыслы агачлар рәсеме чыгарыла)*

**Тәрбияче:** Нинди урман ылыслы дип атала? *(Тәрбияче баларның җавапларын тыңлый. Сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә өнди)*

**Тәрбияче:** Чыршы, нарат, ак чыршы (пихта) агачлары үскән урман ылыслы дип атала.

*(Экранда катнаш урман рәсеме чыгарыла)*

**Тәрбияче:** Имәннәр, каеннар, чыршылар, наратлар бергә үскән урман ничек атала? *(Тәрбияче баларның җавапларын тыңлый. Сорауларга тулы җөмлә белән җавап бирүләренә өнди)*

**Тәрбияче:** Яфраклы һәм ылыслы агачлар бергә үскән урман катнаш дип атала.

**Тәрбияче:** Карагыз әле балалар, без сезнең белән урманга да килеп җиттек. Урман барабызны да шат күңел белән каршы ала: кояшның кызу нурларыннан саклый, күп сорауларга җавап бирә, урман тәмнекәйләре белән сыйлый. Урман – күп төрле хайваннарның һәм кошларның яшәү урыны. Аларның өйләре.

Урман – кешегәдә зур дус. Урманда йөрү кеше организмы өчен бик файдалы. Урман – планета бизәге! *(Экранда чүп белән тулган урман рәсеме чыгарыла)*

**Тәрбияче:** Урман хуҗасының урманы куркыныч хәлдә. Ни өчен шулай булган, ничек дип уйлыйсыз? *(Тәрбияче баларның җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Кешеләр урманда йөргәндә элементар кагыйдәләрне үтәмәгәннәр, урманны сакламаганнар.

*(Экранда аю өне рәсеме чыгарыла, өстенә чүп өелгән)*

**Тәрбияче:** Карагыз әле, балалар, аю өне өстенә чүп өелгән һәм ул аннан чыга алмый. Аю өнен чистартыр өчен, кагыйдәләр үтәргә кирәк.

**Ял минуты**

| | |
|---|---|
| Үзебез яшәгән урам буйлап атлыйбыз | *Бер урында атлыйбыз* |
| Пыяла һәм кәгазьләрне җирдә яткырмыйбыз | *Идәнгә кадәр иеләбез* |
| Бер- салабыз чиләккә<br>Ике- салабыз кәрзингә | *Уңга сулга борылабыз* |
| Иеләбез һәм торабыз | *Алга иеләбез* |
| Бергә тырышабыз | *Артка иеләбез* |
| Бөтен дөньяны чистартабыз | *Кулларны суздык ике якка, уңга сулга борылдык* |

**Тәрбияче:** Карагыз балаллар, аю өне чип-чиста булды. Әфәрин!

**Тәрбияче:** Урманда күп чүп булу аркасында хайваннар өйләрен бутап бетергәннәр. *(Экранда төрле хайваннар сүрәтләре рәсеме чыгарыла, алар өйләрен бутап бетергәннәр)*

**ИКТ уен «Җәнлекләргә өйләрен табырга булыш»**

*(Тиен, Аю, Төлке, Кырмыска - Чокыр (нора), куыш (дупло), аю өне (берлога), умарта, кырмыска оясы, эт оясы, сыерчык оясы)*

*(Экранда канатлары бауга буталып беткән кош рәсеме чыгарыла)*

**Тәрбияче:** Бу кошның канатлары бауга буталып беткән. Аңа булышыр өчен без бирем эшләргә тиеш.

**Уен «Койрыгын тап»**

*(Өстәлдә койрыксыз кошлар рәсемнәре таркалган. Җитмәгән өлешләрне табып, рәсемне тулыландырырга кирәк. Балаларның күңегүне дөрес үтәлүен тәрбияче күзәтә)*

**Тәрбияче:** Әфәрин! Булдырдыгыз балалар! Кошны коткарырга булыштыгыз.

*(Экранда чүпле алан рәсеме чыгарыла)*

**Тәрбияче:** Карагыз әле, күпме чүп! Урман хуҗасының кайгыруын бик тә аңлыйм! Мондый урманнан барлык җәнлекләр качып бетәчәк, һәм кошлар да сайрамас. Нишләрбез икән, балалар? *(Тәрбияче балаларның җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Бу аланны, әлбәттә, чистартырга кирәк. Без сезнең белән чүпләрне ни өчен сортларга аерып җыярга кирәк икәне турында сөйләшкән идек. Ә хәзер аерып җыеп карыйк!

**Тәрбияче:** Мин сезгә берничә төрле контейнер әзерләдем:

Зәңгәр – пыяла

Яшел- органика

Кара - батарей

Шәмәхә - металл

Сары - кәгаз

Кызыл – пластик

**Тәрбияче:** Аланга рәхим итегез, берешәр карточка сайлап алыгыз һәм тиешле контейнерга илтеп салыгыз. Чүпләрне дөрес аерабыз!

**Уен “Чүп аеру”**

(*Чүп белән карточкалар: пыяла шешәләр, консерва банкалары, алма чүбе, банан кабыгы, целлофан пакет, кәгазь пакет, пластик шешәләр, йомырка кабыгы, кәгазь, китап, картон тартма, пластик урындык, тимер банка, ватык чашка, апельсин кабыгы, каткан ипи Һ.б. (Балар чүп ясалган карточканы алалар һәм тиешле контейнерга салалар)*

**Тәрбияче:** Алан чип-чиста булды, барлык чүпне контейнерларга җыйдык. *(Аудиоязма – кошлар сайраган тавыш. Экранда чип-чиста урман рәсеме чыгарыла).*

**Тәрбияче:** Ишетәсезме, балалар, урманга хайваннар да, кошлар да кире кайткан. Безгә урман хуҗасы бүкән астында нидер калдырган. (*«Урман сакчылары» эмблемалары таратыла).*

**3. Йомгаклау өлеш**

**Тәрбияче:** Хәзер тылсымлы сүзләр әйтеп үзебезнең балалар бакчасына кайтыйк, балалар. “Бер-ике-өч” дип әйләнәбез, бакчабызга кире кайтабыз!

**Тәрбияче:** Без “Урман хуҗасына” булыша алдыкмы? Нинди бирем иң авыр булды? Урманнар, аланнар мондый хәлгә бүтән килмәсен өчен без нишләрбез? *(Тәрбияче баларның җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Әйе, балалар. Урманны, хайваннарны, үсемлекләрне сакларга кирәк, чүптән чистартырга кирәк. Табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен истә тотарга кирәк.

**Тәрбияче:** Өегезгә кайткач, әти-әниләрегезгә бүген урманга ничек булышканыбызны сөйләп бирегез һәм киләчәктә һәрберебез нинди файда эшли алганын аңлатыгыз.

*Оригинальность 100%, https://text.ru/antiplagiat*

## «ӘКИЯТТӘ КУНАКТА»

***Шарафиева Рамиля Азатовна- югары кв.категория,***
*113санлы «Тиктормаслар» балалр бакчасы тәрбиячесе,*
*Яр Чаллы шәһәре*

**Яшь үзенчәлекләре:** Икенче кечкенәләр төркеме (3-4 яшь)

**Максат:** уен- әкият аша элементар математик күзаллауларын киңәйтү.

**Бурычлар:**

*Белем бирү бурычы:* “озын – кыска”, “шуның кадәр үк”, “бертигез”, “бер”, “күп” төшенчәләре турында белемнәрен арттыру; геометрик фигураларны аера,төсләрне истә калдыру; “көн”,”төн” төшенчәләрен аера белү; балаларның рус халык әкиятенең "Теремкәй" геройларын атый белүен ныгыту.

*Үстерү бурычы:* зиһенне, игътибарлыкны, фикерләүне, күзаллауны үстерү.

*Тәрбия бурычы:* тәрбиячене һәм башка балаларны игътибар белән тыңлый белү; әйләнә-тирә дөньяга сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү; төркемдә, коллективта аралашу осталыкларын тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:** балалар предметларның сыйфатын «озын-кыска» сүзләре белән дөрес итеп билгели алалар; “ничә?” дигән сорауларга дөрес

җавап бирәләр; геометрик фигураларны һәм “көн”-“төн” төченчеләрен аера беләләр.

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** оялчан балаларны активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек өстендә эш:**

*Актив сүзлек:* куян, төлке, бака, бүре, аю, чәчәк, күбәләк, көн, төн.

*Пассив сүзлек:* озын, кыска, бертигез, бер, күп, теремкәй, бакылдык, тасма.

**Алдан эшләнгән эш:** Теремкәй әкиятен уку, әкияткә иллюстрацияләр карау, табышмаклар чишү, әйләнә -тирәдә бер һәм күп предметлар табу, озынлык буенча тасмаларны чагыштыру, дидактик уеннар; күрсәтмә һәм таратма материал әзерләү.

**Материаллар һәм җиһазлар:**

**Демонстрацион материаллар һәм җиһазлар:** теремкәй, уенчык куян, бака, бүре, төлке, аю, рәсем “Теремкәй”

**Таратма әсбаплар:** һәр балага 5 чәчәк, күбәләк, озын һәм кыска кәгазь тасмасы, һәр балага геометрик фигуралар.

**Кулланган әдәбият:**

1.Туганнан алып мәктәпкәчә программасы/ Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясе, -3 нче басма.-М.:Мозайка-Синтез, 2015;

2.Региональная программа дошкольного образования , автор Р.К.Шаехова.

## Эшчәнлек барышы

**1. Оештыру өлеше**

**Тәрбияче:** Балалар, кәефләрегез ничек? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Ә сез әкият яратасызмы? *(Тәрбияче баларның җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Ә сез нинди әкиятләр беләсез? *(Тәрбияче баларның җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Мин сезгә бүген әкияткә кунакка барырга тәкъдим итәм. Ә нинди әкияткә икәнен, сез табышмакны тыңлагач белерсез.

Бер алан уртасында
Бик матур өй тора.
Ул биек тә түгел, тәбәнәк тә түгел. Нәрсә ул? (*Балларың җаваплары)*

**Тәрбияче:** Дөрес, балалар, бу теремкәй. Күзләрне йомабыз, өчкә кадәр саныйбыз, әкияткә юл тотабыз.

**Тәрбияче:** Ә менә теремкәебез! Ул әлегә буш, димәк без вакытында җитешкәнбез, әкият әле башлана гына! *(Тәрбияче теремкәй сүрәтен күрсәтә)*

**2. Төп өлеш**

**Тәрбияче:** Балалар, теремкәй янына җайлырак утырыгыз һәм игътибар белән тынлагыз:

“Тора икән аланда теремкәй, ул биек тә түгел, тәбәнәк тә түгел.
Шул вакытта тычкан-йөгер барган, теремкәйне күреп туктаган.
Ә теремкәй янына ике юл алып бара, берсе озын, берсе кыска.

**Тәрбияче:** Тычкан буталган, кайсы юлдан китсә тизрәк барып җитәр микән, балалар, сез ничек уйлыйсыз? *(Тәрбияче баларның җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Безгә кайсы юлның кыскарак икәнен тычканга дөрес итеп күрсәтергә кирәк.

**Тәрбияче:** Өстәлләрегездә хәрберегезнең 2 «юл», озынлык буенча алар аерыла. Аларны берсе өстенә берсен куеп чагыштырырга кирәк. *(Балалар чагыштыралар. Тәрбияче эшләрен күзәтә)*

**Тәрбияче:** Кайсы юл кыска? Кайсы юл озын? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әфәрин, балалар, сез кыска юлны дөрес күрсәттегез. Менә инде тычкан да кыска юлдан барып, теремкәйгә килеп тә җитте. Һәм җырлый-җырлый анда яши башлады.

**Тәрбияче:** Ничә җәнлек яши теремкәйдә? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Тора икән аланда теремкәй , ул биек тә түгел, тәбәнәк тә тугел.

Шул вакытта, теремкәйне бака-бакылдык күргән. Ә теремкәй янында аланда чәчәкләр үсеп утыра һәм күбәләкләр оча. Бака сикереп килгәч, кубәләкләр куркып очканнар. Әйдәгез әле күбәләкләргә чәчәкләренә кире кайтыра булышыйк.

**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле, өстәлләрегездә сезнең чәчәкләр. Ничә? *(Балаларның җаваплары)* Менә күбәләкләр очып килгән. Әйдәгез һәр күбәләкне берешәр чәчәккә урнаштырыйк.

**Тәрбияче:** Күбәләкләр ничәү? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Нәрсә күбрәк? ни өчен? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Һәр чәчәктә күбәләк бармы? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Күбәләкләр һәм чәчәкләр бертигез булсынга нишләргә кирәк? *(Тәрбияче балаларның җавапларын тыңлый. Сорауларга җавап бирүләренә ирешү)*

**Тәрбияче:** Менә тагын бер күбәләк очып килә, хәзер күбәләкләр һәм чәчәкләр турында нәрсә әйтеп була? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче**: Әйе, күбәләкләр бертигез һәм чәчәкләр бертигез.

**Тәрбияче:** Хәзер бака-бакылдык бик шат һәм теремкәйдә алар тычкан белән бергәләп яши.

**Тәрбияче:** Көннәр үткән, теремкәйгә яңа кунак килгән. Бу куян-куянкай. Ул көн белән төнне бутаган. Әйдәгез әле куянкайга булышыйк. Кайчан көн, ә кайчан төн булганын аңлатыйк.

*(Рәсемнәр буенча балалар тәүлекнең кайсы вакыты булганын әйтәләр: көн, төн, иртә, кич)*

**Ял минуты "Көн-төн"**

**Тәрбияче:** Мин кыңгырауга шалтыраткач – бу көн, сез уйныйсыз, йөрисез, биисез, ә кыңгарау тавышы туктагач - төн җитә, сез чүгәлисез һәм йоклыйсыз *(Уен үткәрелә).*

**Тәрбияче:** Менә куянкай да көн белән төннең аермасын аңлады һәм ул да теремкәйдә яши.

**Тәрбияче:** Карагыз әле, балалар, җылый-җылый төлке килә теремкәй янына.Урманда йөгереп йөргәндә төймәсе өзелеп чәчелгән аның, шуңа кәефе юк икән. Яңа төймә ясарга булышабызмы төлкекәйгә? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Сезнең өстәлләрдә геометрик фигуралар ята. Мине игътибар белән тыңлагыз. Мин нинди фигура әйтәм, сез шул фигураны табып куясыз. *(Тәрбияче укый һәм балаларның күңегүне дөрес тиеп үтәлүен күзәтә: сары өчпочмак, яшел түгәрәк, кызык шакмак, ак түгәрәк, зәңгәр тупыпочмак)*

**Тәрбияче:** Менә нинди матур төймәләр барлыкка килде, төлке бик шат!

**Тәрбияче:** Урман буйлап бүре чаба, бүләккә теремкәйгә рәсем алып килә *(Теремкәй рәсеме күрсәтелә).* Менә инде бүре дә теремкәйдә яши башлаган.

**Тәрбияче:** Менә урман буйлап аю бара, аныңда теремкәйдә яшисе килә. Сез ничек уйлыйсыз, җәнлекләр аюны теремкәйгә кертәләрме? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әлбәттә, кертәләр! Безнең теремкәй зур һәм иркен, анда урын җитәрлек. Шулай алар бергәләшеп дус булып яши башлаганнар.

**3. Йомгаклау өлеше**

**Тәрбияче:** Балалар, башта теремкәйдә ничә җәнлек булган? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, берәүдә булмаган.

**Тәрбияче:** Теремкәйдә ничә җәнлек хәзер бар?*(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Дөрес, бер төлке, бер тычкан, бер бүре.... Бөтенесе бергә алар күп.

**Тәрбияче:** Рәхмәт сезгә, балалар, әкият геройларына булыштыгыз, әфәрин! Ә безгә инде балалар бакчасына кайтырга вакыт. Күзләрне йомабыз, өчкә кадәр саныйбыз һәм балалар бакчасына юл тотабыз.

*Оригинальность 100%, https://text.ru/antiplagiat/unauthorized*

## «ӘБИДӘ КУНАКТА»

***Шарафиева Рамиля Азатовна-югары кв.категория,***
*113санлы «Тиктормаслар» балалар бакчасы тәрбиячесе,*
*Яр Чаллы шәһәре*

**Яшь үзенчәлекләре:** Икенче кечкенәләр төркеме (3-4 яшь)

**Максат:** «Йорт хайваны», «кыргый хайван» төшенчәләрен ныгыту; хайваннарны яшәү тирәлеге буенча классификацияләргә өйрәтүне дәвам итү.

**Бурычлар:**

**Белем бирү бурычы:** транспорт төрләрен искә төшерү; йорт хайваннарын кыргый хайваннардан аеру, аларны дөрес атау күнекмәләренә өйрәтү; чыпчык һәм карганы тышкы кыяфәтләре буенча аера белү; өстә – аста төшенчәләрен кулланырга өйрәтү; пышылдап, тыныч тавыш белән һәм  кычкырып әйтә белүне ныгыту; балаларга гади һәм катлаулы сорауларга җавап бирү күнекмәләрен ныгыту;

**Үстерү бурычы:** зиһенне, игътибарлыкны, фикерләүне, күзаллауны үстерү; балалар сүзлеген уенчыкларның атамаларын аңлатучы гамәлдәге сүзләр белән баету.

**Тәрбия бурычы:** әйләнә-тирә дөньяга сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү; төркемдә, коллективта аралашу осталыкларын тәрбияләү; уңай эмоциональ кәеф формалаштыру; хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:** алган белемнәрне балалар мөстәкыйль уен эшчәнлегендә куллана белә;

**Балалар эшчәнлеге төрләре:** уен, коммуникатив, хәрәкәтләнү.

**Шәхси эш:** оялчан балаларны активлаштыру, сөйләмдәге хаталарны төзәтү, сорауларга җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек өстендә эш:**

**Актив сүзлек:** эт, песи, сыер, куян, карга, чыпчык.

**Пассив сүзлек:** йорт хайваны, кыргый хайван, песием, песикәем, этем, эткәем, сыеркаем, сыерым, куянкаем, куяным.

**Алдан эшләнгән эш:** шалкан әкиятен уку, әкияткә иллюстрацияләр карау; табышмаклар чишү; кыргый һәм йорт хайваннары рәсемнәрен карау, ИКТ –уен “Нәрсә артык?”, капма – каршы сүзләр табу, дидактик уеннар.

**Материаллар һәм җиһазлар, таратма әсбаплар:** уенчык куян, сыер, эт, песи, яшелчә һәм җиләк-җимеш муляжлары, агач макеты, кәрзин, туп; карга һәм чыпчык рәсеме яки уенчыклары, буяугычлар.

**Кулланган әдәбият:**

1. Туган телдә сөйләшәбез. Методик кулланма. 2016 ел

2. Балалар бакчасы. Уку китабы. 2003 ел

## Эшчәнлек барышы

**1. Оештыру өлеше**

**Тәрбияче:** Хәерле иртә, балалар! Кәефләрегез ничек? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Карагыз әле, балалар, нәрсә бу? *(Тәрбияче балаларның игътибарын өстәлдәге хатка юнәлтә)*

**Тәрбияче:** Әйдәгез хатны укып карыйк әле, нәрсә язылган микән анда һәм кем язды микән бу хатны? *(Укый)*

**Тәрбияче:** Бу хатны шалкан әкиятендәге әби язган.

”Балалар, мин сезне кунакка чакырам!” дип язган икән.

**Тәрбияче:** Балалар, сез әбигә кунакка барырга телисезме? *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Алай булгач, әйдәгез, кунакка барыйк. Ә ничек без анда барып җитә алабыз? *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, балалар, сез дөрес әйтәсез, автомобиль, поезд, автобус, самолет белән барырга була.

**2. Төп өлеш**

**Тәрбияче:** Мин сезгә поезда барырга тәкъдим итәм. Мин поезд булам, ә сез аның вагоннары булырсыз.

**Тәрбияче:** Вагоннарның чиратын уен аша табарьбыз. Кемнең кулында туп, шул сорауга җавап бирә һәм вагоннар булып тезелешеп басабыз.

**Уен “Киресен әйт (капма-каршы сүзләр)”**

**Тәрбияче:** Фил зур, ә тычкан...*(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, фил зур, ә тычкан кечкенә

**Тәрбияче:** Арыслан кыю, ә куян... *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, арыслан кыю, ә куян куркак

**Тәрбияче:** Суган ачы, ә торт... *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, суган ачы, ә торт баллы

**Тәрбияче:** Мендәр йомшак, ә таш... *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, мендәр йомшак, ә таш каты

**Тәрбияче:** Бөҗәк корты кыска, ә елан... *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, бөҗәк корты кыска, ә елан озын

**Тәрбияче:** Кышын салкын, ә җәен... *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, кышын салкын, ә җәен җылы

**Тәрбияче:** Көндез якты, ә төннә... *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, көндез якты, ә төннә караңгы

**Тәрбияче:** Кар ак, ә җир... *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, кар ак, ә җир кара

**Тәрбияче:** Чәй кайнар, ә туңдырма... *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, чәй кайнар, ә туңдырма салкын

*(Балалар чиратлашып вагон артыннан паровозик булып баса)*

**Тәрбияче:** Балалар, нинди озын булды безнең поезд!

**Тәрбияче:** Кузгалабыз. Шшш *(Балалар тәрбияче артыннан кабатлый)*

Тизәябез ччч *(Балалар тәрбияче артыннан кабатлый)*

Пар чыгарабыз ссс *(Балалар тәрбияче артыннан кабатлый)*

Туктыйбыз ззз *(Балалар тәрбияче артыннан кабатлый)*

**Тәрбияче:** Менә без аланга килеп җиттек. Ничек күп монда чәчәкләр! Әйдәгез, аларны иснәп карыйк.

**Сулыш алу гимнастикасы.**

**Тәрбияче:** Борын аша тын алабыз, сулыш алуны тоткарлыйбыз һәм әкрен генә тын чыгарабыз “а-ах”. *(Балалар тәрбияче артыннан кабатлый)*

*(Агач янына барып утыралар)*

**Тәрбияче:** Карагыз әле, балалар, агач ботагында кем утыра микән? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Чыннаң да, чыпчык утыра. Ул өстә яки аста утыра? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Ул өстә, агач ботагында утыра.

**Тәрбияче:** Нинди тавыш чыгара чыпчык? *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Чыпчык “чик-чирик” дигән тавыш чыгара.

**Тәрбияче:** Ә бу кем микән? *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Карга да бар шул монда. Карга өстә яки аста утыра? *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Карга каен агачы астында утыра. Ә карга нинди тавыш чыгара? *(Баларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Карга “кар-кар” дип эндәшә.

**Ял минуты “Канат кагу”**

**Тәрбияче:** Карагыз әле, балалар, карга белән чыпчык дулкынлана, канатлары белән кагалар. Кошлар уйнап алырга чакыралар безне.

*(Балалар кулларын өскә – аска күтәрә, як – якка борыла)*

**Уен “Нәрсә артык?”**

**Тәрбияче:** Игътибар итегез әле, балалар, агач янында күп төрле хайваннар җыелган, алар адашканнар, өйләрен таба алмыйлар. *(Агач астында уенчыклар төзелгән).* Аларга өйләрен табырга булышып карыйк.

**Тәрбияче:** Бу йорт хайваны, аның койрыгы йомшак, ул тычкан тота. Кем бу? *(Тәрбияче балаларның барлык җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Әйе, бу песи *(Песи уенчыгы күрсәтелә).* Песи нинди тавыш чыгара? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, песи “мия- мияу” дип эндәшә.

**Тәрбияче:** Без песигә иркәләп, йомшак итеп ничек эндәшә алабыз? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Песием, песикәем дип песигә иркәләп, йомшак итеп эндәшә алабыз. Песи нәрсә эшләргә ярата? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Песи тычкан тотырга, сөт эчәргә, мырларга, тырнашырга, уйнарга бик тә ярата.

**Тәрбияче:** Песи нинди? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Песи йомшак, йонлы, иркә.

**Тәрбияче:** Бу зур йорт хайваны. Аның озын койрыгы һәм мөгезләре бар. Кем бу? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, бу сыер.

**Тәрбияче:** Сыер ничек эндәшә? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Дөрес, сыер “муууу” дип эндәшә. Без сыерга икрәләп, йомшак итеп ничек эндәшә алабыз? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Сыерым, сыеркаем дип иркәләп, йомшак итеп эндәшә алабыз..

**Тәрбияче:** Бу йорт хайваны, ул өйне саклый. *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, бу эт. Без euткә икрәләп, йомшак итеп ничек эндәшә алабыз? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Этем, эткәем дип дип иркәләп, йомшак итеп эндәшә алабыз... Эт нишли? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Эт өрә, йортны саклый, ырылдый, сөяк кимерә, чаба, койрыгын селкетә. Эт ничек итеп өрә? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Эт “ау – ау” дип өрә. Балалар, шушы хайваннарны бер сүз белән ничек әйтеп була? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Бер сүз белән әйткәндә, бу йорт хайваннары. Алар авылда, кеше янында яши. Монда тагын бер җәнлек калды бит әле? Бу кем? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйе, бу куян. Әйтегез, шушы хайваннарның кайсысы артык? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Дөрес, куян артык, чөнки куян – ул кыргый хайван, ул урманда яши. Ә куян нишли? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Куян сикерә, кишер кимерә.

**Тәрбияче:** Әфәрин, балалар! Ә хәзер әйдәгез җәнлекләргә әби янына кайтырга булышыйк әле *(Уенчык хайваннарны алып өстәлгә әби янына куялар, куян кала).*

**Тәрбияче:** Әби, исәнмесез! *(Балар исәнләшә)*

**Тәрбияче:** Әби җәнлекләрен кайтарганыгыз өчен сезгә бик рәхмәтле. Ул сезгә күчтәнәчкә җиләк-җимешләр һәм яшелчәләр әзерләгән.

**Тәрбияче:** Балалар, сез әбигә булыштыгыз, әфәрин! Әби сезгә рәхмәт әйтә һәм кәрзин белән күчтәнәч бирә *(Буягычлар таратыла).*

**3. Йомгаклау өлеше**

**Тәрбияче:** Хәзер инде бакчабызга кайтырга вакыт, поездагы вагоннарга утырыгыз. Поезд кузгала. “Тү-түүүүүт” кабатлыйбыз. *(Балалар тәрбияче артыннан кабатлый)*

**Тәрбияче:** Менә без төркемебезгә кайтып та җиттек. Без кайда булдык? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Без әбидә кунакта булдык. Без анда нәрсә эшләдек, әбигә ничек итеп булыша алдык? *(Тәрбияче балаларның барлык җавапларын тыңлый)*

**Тәрбияче:** Без йорт хайваннарына өйләрен табырга булыштык, агч өстендә чыпчыкны, ә агач астында карганы күрдек.

**Тәрбияче:** Әйдәгез, түгәрәккә басыйк та, кулга-кул тотынышып “Без бик яхшылар!” дип әйтик. Башта пышылдап әйтик, аннан тыныч тавыш белән, аннан кычкырып әйтәбез.